КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 24
29 декабрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

ГАСЫРНЫҢ СОҢГЫ БИШЬЕЛЛЫГЫНА КЕРӘБЕЗ.
ТӘРӘККЫЙ ИЛЛӘР ЮЛЫНА ЧЫГАРБЫЗМЫ?..

Без, без, без идек, без унике кыз идек,
Без, унике ай булып, сезгә кунакка килдек...

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең

Яңа ел котлавы

Кадерле ватандашлар! Кадерле дуслар!

Тарихи үзгәрешләр чорының тагын бер елы — 1995 ел тәмамланып килә. Ул безнең икътисадыбызны һәм бөтен иҗтимагый тормышыбызны үзгәртеп коруны дәвам итү елы булды. Дөрес, 1995 ел каршылыкларсыз һәм борчуларсыз гына үтмәде. Ә шулай да кеше хәтерендә, гадәттә, шатлыклы-куанычлы вакыйгалар күбрәк кала.

Узган ел барыбыз өчен дә, беренче чиратта, Бөек Җиңүнең 50 еллыгын, туган республикабызның бишьеллык юбилеен зурлап бәйрәм итү белән аеруча истәлекле булды. Бәйрәм көннәрендә без шушы җаваплы чор эчендә башкарган эшләребезгә йомгак та ясадык. Бу еллар сәяси юлыбызның, икътисади реформаларны гамәлгә ашыруның тормышчанлыгына җитди имтихан булды.

Минемчә, узган ел безнең күңелләрдә зур үзгәрешләр ясады. Без үзебезне республикабызның чын хуҗалары итеп тойдык. Һичшиксез, 9 май һәм 30 август көннәре барыбызның да хәтерендә тирән хисләр калдырды. Ул чакта күпмилләтле Татарстан халкы дуслык һәм татулык шартларында мәйданнарда һәм урамнарда гөр килеп бәйрәм итте. Чыннан да, бездә үзебезне бердәм, бербөтен халык итеп тою хисе тагын да ныгыды, чөнки безнең тарихыбыз һәм язмышыбыз уртак, иҗади хезмәткә омтылышыбыз зур. Ә кешеләр кыенлыкларны җиңәргә бердәм әзер торганда, эшләребезнең уң булачагына мин һич тә шикләнмим.

1995 ел — Русия тормышында гаять мөһим вакыйга — Дәүләт Думасына сайлау белән дә истәлекле булды. Аның нәтиҗәләре Татарстан халкының реформалар курсын яклавын күрсәтте. Безнең сайлаучылар идеологик схемаларны яки популистик вәгъдәләрне түгел, ө республикабыз мәнфәгатьләрен яклап тавыш бирде. Хәзерге Русия хөкүмәтенең мәнфәгатьләрен яклаучы хәрәкәтнең Татарстанда күпчелек тавыш җыюы нәрсә белән аңлатыла соң? Бу блок иң элек Федерацияне һәм җәмгыятебез тормышын демократияләштерү принцибын, сәясәттә эзлеклелек, эчке сәяси низагларны хәл иткәндә көч кулланудан баш тарту кебек, халкыбыз өчен гаять мөһим юнәлешләрне яклап чыкты. Татарстандагы сайлау нәтиҗәләре безне озак вакытлар буена искелеккә ябышып ятуда гаепләргә маташкан кайберәүләрне соңгы дәлилләреннән дә мәхрүм итте.

Сүз дә юк, һәр яңа елны каршы алганда без барыбыз да матур хыялларыбызның һәм өметләребезнең тормышка ашуын телибез. Шулардан чыгып, 1996 елда дәүләт хакимияте органнары нинди проблемалар хәл итәчәк соң? Беренче чиратта безгә халыкның төрле катлауларын адреслы социаль яклауны тагын да көчәйтергә кирәк булачак. Шуның нәтиҗәсендә мохтаҗ кешеләрнең саны артуга чик куелырга тиеш. Мин моны иң мөһим бурычларның берсе дип саныйм. Чөнки базар икътисадына керә барган саен кешеләр арасында матди тигезсезлек тирәнәя төшә.

Моңа бәйле рәвештә безгә халыкның аз керемле катлауларына кагылган проблемаларны тирәннән өйрәнүне көчәйтергә кирәк. Бу җәһәттән, күптән түгел узган Татарстан хатын-кызлары корылтае да уйлану һәм тиешле сәясәт эшләү өчен хөкүмәткә бай материал бирде.

Безгә 1995 елның икенче яртысында икътисад өлкәсендә башланган уңай борылышны ныгыту бик мөһим. Без акрынлап икътисади кризистан чыгу юлларын табып килә без. Нефть чыгару, аны эшкәртүдә, төзелештә берникадәр үсеш башланды. Машина төзелеше өлкәсендә дә өмет чаткылары күренә.

Элеккә кебек үк авыл хуҗалыгына булышлык итү нигезендә халыкны үзебездә җитештерелгән азык-төлек белән тәэмин итүгә зур игътибар биреләчәк. Хәрби промышленность комплексы предприятиеләрендә әлегә хәл шактый кыен, чөнки алар эшчәнлеге оборона заказларына бәйле. Ләкин монда да безнең тырышлыгыбыз нәтиҗәле булыр дип ышанабыз. Республиканың интеллектуаль куәтен һәм чит ил инвесторларын эшкә тартып, безгә конверсия мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнергә кирәк. Шуның белән бергә, без алга таба да кече һәм урта кәсабәчелекне үстерүгә җитди әһәмият бирергә тиешбез. Бу эшсез калу куркынычы алдында торган шактый күп кешене эш белән тәэмин итәргә мөмкинлек тудырачак.

Киләсе Яңа ел — социаль мәсьәләләрне хәл итүдә үзенчәлекле ел булачак. Дистәләрчә еллар буена, бигрәк тә башкалабыз Казанда, бөтен республиканың күз көеге булып торган җимерек торак мәсьәләсен ныклап хәл итүгә тотынабыз.

Бу зур күләмле программаны тормышка ашыру нигезендә киләсе елның бу сәгатьләрендә меңнәрчә гаиләләрнең өй туйлары уздырачагына ышанычым зур.

Күчеш чорының икътисади кыенлыкларына карамастан, 1996 ел Татарстан товарларының конкуренция сәләте үсү, яңа базар киңлекләре яулау елы булыр. Социаль-сәяси планда ул өхлагыбыз ныгу, кешеләрнең иминлеге, халкыбызның милләтара татулыгының тагын да ныгу елы булыр. Киләсе елның мартында без Татарстан Президентын сайлаячакбыз. Шуңа күрә 1996 ел республика җитәкчелегенең бу елларда тоткан сәясәтенә бәя бирү елы да булачак.

Кадерле дуслар!

Мин сезне чын күңелдән Яңа ел белән котлыйм! Ул һәр йортка, һәрбарчабызга тынычлык һәм муллык, бәхет һәм шатлык китерсен иде!

Исәнлек-саулык, уңышлар телим сезгә, кадерле ватандашлар!

Сезне бусагадан атлап керүче Яңа ел белән!



Габдулла ТУКАЙ

Сөткә төшкән тычкан

Ничектер, белмимен, бер көн идән асты кошы — тычкан
Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән.

Йөзеп карый табакта арлы-бирле — һич чыгып булмый!
Сыек сөт бит, — бата, һич тә табактан ычкынып булмый.

Йөри тычкан, йөзәдер, тик торып булмый, йөрәк түзми.
Йөзәдер аркылы, буйга, — котылмактан өмид өзми.

Тырышмак бушка китми бит, бераздан соң була уңгай:
Бу тычкан шулкадәр йөзгән, куерган сөт тә — булган май.

Хәзер бит батмый, — тычкан киерелеп майга аяк баскан;
Сикергән дә табактан ул, чыгып, үз урнына качкан.

* * *

И карендәш! син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, собат!*

* Ит собат — ныклык күрсәт.

АДӘМ баласының табигате шундыйдыр инде: Яңа ел таңын каршы алганда һәркем киләчәк хакында үзенчә уйланып фараз кыла, күңелдә төрледән-төрле теләкләр уйна, киләсе елның элгәрләреннән уңышлырак булачагына өметләнә. Ил-көнгә иминлек һәм яхшылыклар гына юрый. Менә бу юлы да шулай. Гуяки, без эчтән генә дога укыйбыз: үтеп бара торган Дуңгыз елы җәмгыятебезне күпмедер алга илтсә дә, багланган ышанычны тулысынча аклап бетерә алмады... Иншалла, яңа 1996 ел безгә миһербанлырак булыр, бәлки, яхшырак та яши башларбыз... Теләкләребез фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килсен иде, йа раббы...

Бу җәһәттән безне астрологлар да өметләндереп тора әле: алдагы Тычкан елы муллык, яңа мөмкинлекләр, күңелле вакыйгалар, сыйфатка күчү елы булачак. Безгә хәзер нәкъ менә шулар кирәк бит. Әмма муллык белән иминлек, әкияттәгечә, үзеннән-үзе генә килмәс. Хәзрәти Тукаебызның мәгълүм шигырендә, әнә, сөтле табакка төшкән Тычкан да, чыдамлык һәм ныклык күрсәтеп, хәвеф белән янаучы кабаладан котылуга ирешә. Киләсе Тычкан елында 110 яшен тутырачак даһи шагыйребез, әйтерсең, шушы әсәре белән безне ишарәләп искәртә, күбрәк үз-үзеңә ышанырга чакыра...

И Тычкан елы! Вакыт бусагасын уң аягың белән атлап, «бисмилла»ңны әйтеп кер. Биниһая зур тетрәнүләр аркасында икътисади һәм рухи чоңгылга юлыккан илне дөньядагы тәрәккый дәүләтләр юлына чыгарып бастырырга булыш. Үзгәртеп кору мәхшәренә дучар булган Русия, әйе, мәкерле чоңгылдан чыга алмыйча интегә. Шигырь башка да, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка, дигәндәй, мондый кабалага эләгү сөтле табакка төшү ише генә түгел. Гомумән, соңгы гасырда хисап дәфтәренә сыймаслык гөнаһлар кылган Русияне сөттә коенган хәлдә күз алдына китереп булмый. Кая инде ул сөттә коену! Үз халкы белән көрәшүдән туймаган «явызлык империясе»нең варисы чынлыкта һаман да әле кан исеннән айный алмый иза чигә. Пычрак сәясәттән килеп чыккан авантюралар чистарыну вакытын һаман саен кичектереп тора. Их, инде тәүбәгә килеп, сөттәй сафланасы, коргаксыган күңелләрне иман-ышаныч белән сугарасы иде. Чыгасы иде чоңгылдан...

Тычкан елы! Ничә еллар буе билгесезлек дәрьясында «арлы-бирле йөзгән» сабыр халыкка үзеңә бирелгән вакыт аралыгында аз гына булса да җиңеллек китерсәң икән. Хәләл хезмәтнең әҗерен кайтарыш. Булыш безгә, Тычкан елы! Бергәләп иҗтиһат иткән чакта, шигырьдәгечә, сөт тә куера төшәр. Дөрес, аннан тиз генә май барлыкка килмәс, табакка төшкән Тычкан кебек, киләсе елда гына май язылып, өскә чыга алмабыз. Әмма өметебез, омтылышыбыз зурдан, гайрәт-дәрманыбыз да җитәрлек, сабырлыгыбыз исә хәттин ашкан. Башка җөмһүрият һәм өлкәләр белән чагыштырганда, тормыш дәрәҗәсе югарырак һәм тотрыклырак, җитәкчеләренең абруе зуррак булган Татарстаныбызга киләчәктә тагын да күбрәк бәрәкәт иңдер, хезмәт сөючән тырыш халкыбызның теләк-хыялларына хәерхаһ бул, Утлы Тычкан елы! Син бит Шәрыктә Зодиакның иң яхшы елы булып саналасың. Шулай була күр, сөткә төшкән Тычкандай, үзеңә дә, безләргә дә игелек кыл!..

ҖИДЕГӘН
ВАКЫЙГАЛАР
ХӘБӘРЛӘР
ЯҢАЛЫКЛАР
5 6 7 1 2 3 4

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Президенты Указы белән музыка сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен композитор **Шамил Харис улы Тимербулатов «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татарстан Президенты Указы белән мәгариф өлкәсендә, һәм яшьләрне тәрбияләүдәге казанышлары өчен **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Ростем Шәйхулла улы Мәрданов — В.Куйбышев исемендәге Казан дәүләт финанс-икътисад институтының математика һәм икътисади информатика кафедрасы мөдире;

Хәйдәр Фәсхи улы Хисанов — Саба районының Саба мәктәп-гимназиясе директоры

Бер авызың пешкәч...

«МММ», «Русская недвижимость», «Хопер», «Татарстан-Москва-2» һәм башка шундый финанс компанияләренең бөлүе, алар китергән зыян Татарстанны да читләтеп үтмәде. Бүгенге көнгә 50 меңнән артык татарстанлы 36 миллиард сумлык зыян күрде өлеге аферистлардан

Безгә мәгълүм булганча, хөкүмәт республикада эшләүче һәм оештырылачак инвестиция фондларына халыкның ышанычын ныгыту өчен вкладчыларның компенсацион фондын оештырырга ниятли икән. Шулай шул, бер авызың пешкәч, салкын суны да өреп кабасың.

Сыналмаган фәрештәләр

«Коры җирнең алтыдан бер өлешен тәшкил итүче» Русиядә эшләмичә көн күрергә тырышучыларның күп булуын яхшы беләбез. Һәм анда, баксаң, ил президенты булырга атлыгып торучылар да байтак икән. Һәрхәлдә, инде бүгенге көндә 46 кандидат булуы мәгълүм. Алар арасында нинди генә дәгъвачылар юк: уңнары да, суллары да, кызыллары да, аклары да дигәндәй... Шуларның властька ыргылулары турында уйлыйсың да, эчтән генә борынгылар сүзен кабатлап куясың: сыналмаган фәрештәдән сыналган шайтан артык.

Шунысы да мәгълүм: президентлык бәйгесендә безгә яхшы таныш булган Аман Тулеев та катнашырга ниятли. Ай-һай, тамырында татар каны аккан бу сәясәтчегә Илбаш тәхетенә менү тәтер микән?! Мәһдиевчә әйткәндә, едва ли...



«Мәдинә»ле булыйк дисәк...

1996 елны без, Казанның Танкодром мәхәлләсе халкы, зур шатлык һәм күңелле мәшәкать — «Мәдинә» мәчетенә нигез салу белән башлап җибәрергә ниятлибез. Шушы мәчет башкалабызга нур өстәсә иде.

Мөхтәрәм туганнарым, ватандашларым! Эшмәкәрләр, хуҗалык җитәкчеләре! «Мәдинә» мәчетен төзүдә барыбыз да өлешебезне кертсәк иде.

Акча күчерү өчен счет: Р/С 701908, МФО 265771 в Советском отделении Агропромбанка. Адресыбыз: 420089, Татарстан, Казан шәһәре, Курчатов урамы, «Мәдинә» мәчете мөтәвәллияте.

«Мәдинә» мәчетенең идарә рәисе, имам-хатиб ГЫЙЛЬМУЛЛА хаҗи.

Көн дә бәйрәм, көн дә туй...

Татарстан һәм Русия законнары буенча Татарстанда 1995 елның 30 һәм 31 декабре, 1996 елның 1, 2, 3, 6, 7, 8 гыйнвары бәйрәм һәм ял көннәре булып исәпләнә.

Сезне музейлар дәшә

Кадерле балалар, хөрмәтле өлкәннәр!

Кышкы каникул вакытында башкалабызда төрле кызыклы чаралар була, күңелегезгә хуш килгәнен үзегез сайлап алыгыз.

Берләштерелгән дәүләт музее

2 гыйнвар, 11.30. Агачтан ясалган декоратив-гамәли сәнгать һәйкәлләре.

5 гыйнвар, 11.30. Халык иҗаты җәүһәрләре. Халык һөнәрләре турында видеокассеталар күрсәтү, уенчыклар ясау серләре.

6 гыйнвар; 11.30. «Корал тарихыннан».

9 гыйнвар, 11.30. Идел буе Болгарстаны.

Музейның эш сәгатьләре 10нан 17гә хәтле, тел.. 32-09-84.

Максим Горький музее

5 гыйнвар, 10.00. Максим Горький Казанда.

8 гыйнвар, 10.00. Федор Шаляпин Казанда.

9 гыйнвар, 10.00. Көмеш гасыр шигърияте.

Шәриф Камал музее

5 гыйнвар, 16.00. 9 нчы балалар китапханәсенең уку залында (Островский урамы, 15) II-Y сыйныф укучыларына кинофильмнар күрсәтү.

9 гыйнвар, 15.00. 9 нчы балалар китапханәсе белән берлектә Y-YII сыйныф укучылары өчен Ф.Тютчев, А.Фет, А.Плещеевлар иҗатына багышланган шигърият кичәсе (Островский урамы, 15).

Муса Җәлил музее

3 гыйнвар. Экскурсия..

4 гыйнвар, 11.00. Коллекцияләр (маркалар, значоклар) җыючы М.Черепанов белән очрашу.

6 гыйнвар. Экскурсия.

7 гыйнвар. Экскурсия.

8 гыйнвар. Экскурсия.

9 гыйнвар, 11.00. «Хат» исемле әдәби-музыкаль композиция.

10 гыйнвар. Экскурсия.

SOS: каникулга куркыныч яный!

Чаллы мәктәпләре каһәр суккан грипп аркасында карантинга ябылган иде. Инде шәһәрдә ата-аналар арасында шундый хәбәр таралган: имеш, кышкы каникулның булмавы да мөмкин, чөнки грипп аркасында балалар укуда болай да артта калдылар. Без бу уңайдан Мәгариф министрлыгына шалтыраттык, шундый хәл булуы мөмкинме, дип сорадык. Уңай да, тискәре дә җавап ала алмадык, чөнки барысын да мәктәп директорлары хәл итә икән. Шулай итеп, гриппның балаларны каникулсыз да калдыруы мөмкин.

КАРАШ

ЭТ ХОКУКЫ

Моннан егерме еллар элек Мәскәүнең Внуково аэропортына төшеп утырган самолетларны каршы алып, үзенең хуҗасын эзләп йөргән бер эт бөтен советлар илен борчуга салган иде. Халык бу маэмай белән шул кадәр мавыкты ки, күпләр телевизион тапшыруларны карау өчен тизрәк эштән таю ягын карый башлады. Эштә дә, өйдә дә гел шуның хакында гына сөйләштеләр. Аның вөҗдансыз хуҗасын хурладылар. Ә бөтен гавам өлеге сәламәт һәм тук эт хакында кайгырткан бервакытта, илдә мыскылланган, кыерсытылган, кочләнгән, рухи яктан гариплэндерелгән кешеләр дә бар иде бит. Тик алар хакында сөйләргә, язарга гына ярамады.

Әйтелгәннәрдән чыгып, чичән җире этләр республикасы булса, без Русия гаскәрләрен катырак сүккән булыр идек, дигән уй туа башлый. Бу очракта, мөгаен, барлык рәсәйлеләр дә андагы этләрне кырган генералларны җинаятьчеләр дип атап, аларны халыкара судка тартуны таләп итәрләр иде. Ә монда бөтенләй киресенчә килеп чыга. Генераллар чичән авылларын һәм шәһәрләрен җир белән тигезләгән көннәрдә, аерым намуслы сәясәтчеләрне искә алмаганда, урыслар чичәннәрне башкисәрләр дип атыйлар.

Безнең маэмай мисалында Буденновски шәһәрендә булган фаҗигале хәлнең сәбәбен дә аңлап була инде. Әгәр сезнең арадан кем дә булса берәр этне котыртса һәм ул бичара маэмай сезне ботыгыздан тешләп алса, аны теләсә кайсы казый аклаган булыр иде. Чөнки ул сәбәбе булганга күрә тешләгән. Тик Буденновски шәһәре хастаханәсен басып алган Шамил Басаевны никтер барысы да сүгәләр, аны атып үтерүне таләп итәләр. Моны бигрәк тә сабый балалар белән картларны да бомбага тоткан сугышчан урыс генераллары таләп итә. Ә Басаев — милли каһарман Шамил токымыннан. Русия гаскәрләре аның балаларын, туганнарын һәм якыннарын юк итте, аны йортсыз-җирсез калдырды. Буденновски фаҗигасенә килсәк, монда Шамил Басаев рәнҗетелгән һәм шул сәбәпле, явыз адәмне тешләп алган маэмай хәлендә калды инде. Гаҗәп, бик гаҗәп. Этләрне яклап була, ә чичәннәрне — юк. Мәскәү бу халыкның хокукын эт хокукыннан да түбәнрәк куя шул.

Локман ЗАКИР.

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Мәскәүдә актерларның А.Яблочкина исемендәге үзәк йортында Татарстанның халык артисты Вера Уликны искә алу кичәсе булды.

Киләсе елның 20-27 гыйнварында М.Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында Ф.Шаляпин исемендәге опера фестивале үткәреләчәк.

Түбән Камада психотерапевт Фарис Галләм белән бергә дәвалау сеанслары биргән күрәзәче, керәшен хатыны Мария Иванова Ислам диненә күчкән.

Инде 3 августтан бирле Әфганстанда әсирлектә интегүче якташларыбызны «Талибан» әһелләре 30 декабрьдә азат итәргә җыена икән.

Бер елдан артык дәвам итүче чичән сугышында Татарстаннан 36 солдат һәм офицер һәлак булды, икесе хәбәрсез югалды.

Мәшһүр җырчыларыбыз Хәйдәр Бигичев белән Зөһрә Сәхабиева утырган «Вольво» автомобиле Нижгар янында авариягә очрап, алар икесе дә хастаханәгә озатылган иде. Без аларның савыгып, тизрәк сәхнә түренә менүләрен көтеп калабыз.

Узып баручы елның мизгелләре



Кешенең кем икәнен белергә теләсәң, аның шоферына кара (рульдә — Русия Федерациясе Премьер-министры Виктор Черномырдин, янәшәсендә — Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев. Мәскәү, ноябрь, 1995 ел).

Михаил КОЗЛОВСКИЙ фотосы.

Кызыл тычкан вәгъдә итә

Көнчыгыш астрологиясе буенча, Дуңгыз елы тәмамланып килә, ә Кызыл тычкан елы (Шәрык календарендә аны икенче төрле Кызыл күсе елы дип тә йөртәләр) туарга маташа. Шулай итеп, Көнчыгышта үзенең активлыгы, хәйләкәрлеге, яшәүчәнлеге өчен хөрмәт ителә торган шушы җанвардан яңа, унике еллык цикл башлана. Хезмәт сөючән, эшлекле, тәҗрибәле һәм булдыклы кешеләр өчен Яңа ел тулаем алганда бәхетле ел булыр, чөнки ул тотрыклырак һәм аны анализларга мөмкин. Шулай ук, борынгылар күзәтүенчә, бу елда сугышлар, һәртөрле һәлакәтләр, түнтәрелешләр Юлбарыс һәм Аждаһа елындагыга караганда, мәсәлән, азрак булган. Вәхаләнки, бу елда да аерым кешеләр язмышында һәм иҗтимагый тормышта да күп кенә көтелмәгән борылышлар булуын көтәргә кирәк. Абруйлы астролог профессор А.Зараев фикеренчә, Тычкан елы муллык елы, яңа мөмкинлекләр һәм күңелле вакыйгалар елы булып исәпләнә. Бу вакытта күп кенә кешеләрдә санның сыйфатка әйләнү перспективасы барлыкка килә. Мәгәр, дип искәртә профессор, бу елның эре спекуляцияләр, товарларга бәяләрнең һәм акцияләр курсларының кискен тирбәлүе белән характерлы булачагын әйтергә кирәк. Икътисад дөньясы туздырылган корт оясы сыман гөжләп торачак, җәмгыятьнең сәяси тормышында исә мөһим үзгәрешләр булачак. Кече бизнесның Тычкан елында бик төшемле булуы мөмкин һәм шуннан акча күп җыелып, башлангыч капитал туплануы ихтимал. Шәхси тормышта да үзеңнең бәхетеңне дауларга, яңа партнерлар табып, мәхәббәтеңне эзләргә кирәк. Бу елда үзеңә төпле нигез салу мөһим, чөнки авыр һәм кайчакта язмыш та хәл ителә торган мәлләрдә шул нигезнең таяныч булып китүе бар.

Тычкан елы, кышның салкын энергиясе һәм төн караңгысы тарафыннан идарә ителгәнлектән (бу исә Көнбатыш астрологиясендә җитдилек һәм оешканлык таләп итә торган Кәҗәмөгез һәм аның идарәче планетасы Сатурн тәэсиренә бәрабәр), талымсыз спекуляциянең, бик көчле мавыгуның яисә комсызлыкның сезне соңы күңелсез тәмамланырдай килешүгә китерергә мөмкин.

Киләсе Тычкан елы табигате белән бик каршылыклы, ул әхлакый һәм матди зарар китерердәй, еш кына белгечлегеңне һәм язмышыңны үзгәртердәй бик күп вак-төяк низаглар, сәүдәви һәм эмоциональ бәхәсләр китереп чыгара. Шулай да бу — эшчәнлегеңнең төрен үзгәртү, иҗади бәйләнешләреңне киңәйтү, яңа офыклар ачу өчен уңайлы чор. Моның өчен шәхси тырышлык һәм талант белән бергә, партнерларның, химаячеләрнең, туганнарның, башлыкларның үз вакытында ярдәм итүе кирәк. Шуңа күрә Тычкан елында уңышка ирешү өчен аларның ризалыгын, вәгъдәсен алып куярга кирәк.

Җиңүчеләрнең урыннары гына үзгәрә

Моннан өч ел элгәре — «Идел» журналы тарихи хикәяләргә конкурс игълан иткән иде. Аңа ел саен йомгак ясала. Р.Даутов, М.Хуҗин, М.Галиев, Ф.Латыйфи, Р.Юныс кебек язучылардан торган абруйлы жюри, ниһаять, 1995 елда да җиңүчеләрне билгеләде. 1 нче урынга Ркаил Зәйдулланың «Тимер Буга» дигән хикәясе лаек дип табылды. 2 нче урында — Ләис Зөлкарнәйнең «Сафа» хикәясе, 3 нче урында — Туфан Миңнуллинның «Мәлгунь» хикәясе. Без җиңүчеләрне ихластан котлыйбыз һәм киләчәктә дә аларда җиңүгә омтылышның сүнмәвен-сүрелмәвен теләп калабыз. Иң гаҗәбе шунда: конкурс игълан ителгәннән бирле беренчелекне өлеге дә баягы шушы өч язучы дәгъвалый. Кызык, әллә бездә тарихи хикәяләр язарлык башка язучылар юк та микән?

Иске елның соңгы хәбәрләре

Яңа ел алдыннан җырчыбыз Гөлзадә совет-алман сугышында катнашкан каһарманнар өчен хәйрия концертлары куйды. Ике концерт та Тинчурин театры бинасында зур уңыш белән узды.

Гөлзадә ханымның башка концерт программаларыннан аермалы буларак, бу концертның беренче өлеше театральләштерелгән иде; монда Гөлзадә ханым сугышка сөекле ирен, улын, абыйсын, атасын озаткан Фатыйма образында иде. Программа тулысы белән сугыш, тылда калган фидакарь кешеләр, һәлак булган һәм исән кайткан каһарманнарыбызга багышланган иде. Бу тамашада мәшһүрләребездән Айрат Арслан, әдип Батулла һәм Гөлзадә ханым җитәкли торган «Мирас» җәмгыяте музыкантлары, һәвәскәр артистлар да катнашты.

Ләкин программаның чамадан тыш озын булуы гына кайбер тамашачыларның кәефен җибәрде бугай. Юк, җырларның күп булуыннан түгел, ә бәлки концерт бетмәстән иртәрәк кайтып китәргә мәҗбүр булуы өчен уфтанды тамашачы. Кичке сәгать унбердән соң өйгә кайтулары бик кыен һәм урам мохите дә хәвефсез түгел бит. Бу Гөлзадә концертына гына кагылмый, башка мәшһүрләребезнең дә концертлары еш кына бик соң тәмамлана. Алда әйтелгәннәрне искә алып, концертантлар программаларын 2-3 сәгатьтән арттырмасын иде.

Үткән атнада Балык Бистәсе төбәгендә һәр елны уза торган җыен булды. Бу җыенга шушы төбәкнең утыздан артык дин әһеле, муллалар, имам-хатиблары килгән иде. Җыенга шулай ук район хакимияте башлыгы Хатип Газизов та чакырулы иде. Мәҗлесне Казан мөхтәсибе Габделхак хәзрәт ачып җибәрде. Җыенда дин әһелләре район хакименә моң-зарларын сөйләделәр, мәчет-дин мәсьәләләрендә хакимнән ярдәм итүен сорадылар.

Иншаллаһ! Аларның үтенече бушка булмас. Хакимият башлыгы дин әһелләренең һәр гозерен игътибар белән тыңлады һәм язып алды.

Чаллыда 1969 елда йөк машиналары заводы төзелә башласа да, еллар арты еллар узса да, шәһәрдә татар театры ачылмады. «Мин КамАЗ төзедем, фәлән иттем», дип күкрәк кагучы кайбер җитәкчеләр татар матбагасы, татар театры турында уйлап та бакмады. Ниһаять, 1990 елда гына Чаллыда театр оешты. Ләкин биш ел гөрләп эшләүче бу театрның әле дә булса заманча шартларга туры килә торган бинасы юк. Театрның бишьеллык бәйрәменә җаваплы кешеләрнең килмәве исә бүгенге башлыкларның да татар мәдәниятенә үгисетеп каравын раслый торган мисал. Ни Мәдәният министрлыгыннан, ни театр әһелләре җәмгыятеннән вәкилләр булмады. Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы Р.Алтынбаев та бәйрәмдә катнашмады.

Кызганыч, Чаллы театры, талантлы коллектив булуына карамастан, һаман да ятим хәлендә яши.

Танылган тәнкыйтьчебез Фәрваз Миңнуллинның вафатына бер ел тулды.

Шул уңайдан Фәрваз Миңнуллинның дуслары, каләмдәшләре Аяз Гыйләҗев, Тәлгат Галиуллин, Рафаэль Мостафин, Гариф Ахунов, Батулла мәрхүмнең ел табынына җыелды. Гыйльмулла хәзрәт мәрхүмнең рухына атап Коръән Кәримнән сүрәләр укыды. Туганнары һәм язучылар Фәрваз Миңнуллин турында истәлекләр, матур хатирәләр сөйләде. Авыр туфрагы җиңел булсын! Урынын җәннәттән әйләсен! Амин!

Табындашлар, шушы хатирәләр, истәлекләр якын киләчәктә Фәрваз Миңнуллин турындагы китапка нигез булып ятсын иде, дигән изге теләк тә белдерделәр.

«Казан» милли мәдәният үзәгендә язучы Миргазиян Юныс ясаган агач сыннар күргәзмәсе ачылды. Очучы, ерак илләргә йөрүче кораб штурманы-диңгезче, язучы Миргазиян әфәнденең талантлы рәссам-сынчы икәнен күпләр белми дә торгандыр. Бу күргәзмәгә куелган сыннар, имәннән, зиректән, артыштан, чит икълимнәрдә үсә торган ят агачлардан ясалган сыннар тамашачыларны гына түгел, сәнгать белгечләрен дә хәйран калдырды. Әдипнең «Нашир алдындагы язучы», «Икетеллелек», «Әхлаксызлык» кебек һәм башка әсәрләре дә символикага, читләтеп әйтү вә образлылыкка нигезләнгән.

Очучы, диңгезче, язучы Миргазиян Юныс бу күргәзмәсе илә үзенең әле гаҗәеп талантлы рәссам-сынчы икәнен дә исбат итте.

Чыршы бәйрәмнәре кайларда була?

Башкалабызның төрле урыннарында быел 32 чыршы куелды. Болар арасында 11е төп чыршы булып санала. Алар — Вахитов районында — Үзәк ял паркы каршында һәм «Черек күл» паркында. Мәскәү районында — Химиклар мәдәният сарае паркында. Киров районында — Петров исемендәге паркта, Авиатөзүчеләр районында — «Крылья Советов» паркында куелган чыршылар. Яңа Савиново районында исә Яңа ел чыршысы өченче дамба күпере янынарак куелды. Идел буе районында яшәүчеләрне Җиңү проспектындагы «Чулпан» кинотеатры каршындагы һәм Киров исемендәге мәдәният сарае янындагы чыршылар үзенә дәшә. Совет районы халкына бигрәк тә мач килде: алар өчен артиллерия училищесы стадионында, «Комсомолец» кинотеатры янында (Карбышев урамы), Азино-2 микрорайонындагы «Универсам» каршында һәм Дәрвишләр бистәсенең Сәет-Галиев исемендәге мәдәният сарае янында — берьюлы дүрт җиргә Яңа ел чыршысы куелды!

Бу чыршыларның уты 27-28 декабрьләрдә 16 сәгатьтә кабынды.

Аннары, мәскәүләрдән күрмәкче, бездә дә парламент һәм Президент чыршысы куелды. Парламент чыршысының театрлаштырылган тамашасы Дәүләт Советы бинасында 23 декабрьдә көндезге сәгать 11дә булды. Президент чыршысы исә балаларны Камал театры бинасына 6 гыйнвар көнне чакыра.

Заһид МӘХМҮДИ

Фәтхулла хәзрәтне уятмагыз

Була язган хәлләр

Шомлы XX гасыр башы иде. «Фәтхулла хәзрәт» дигән әсәрен тогәлләргә утыргач, Фатих Әмирхан, кинәт күңеле төшеп, каләмен идәнгә томырды.

— Хыялый нәрсә булса да, дөреслеккә туры килә бу, — диде ул. Мулла кешене 1950 елда терелтү чып-чын ахмаклык булыр. КГБда харап итәчәкләр аны. Бүген мәчет манараларын аудара, дин әһелләрен эзәрлекли башлаган бу большевиклар иртәгә дә шундый ук каһсыз булачаклар. Озакка килделәр алар, бик озакка.

Олуг әдипнең авызыннан шундый гыйбарә чыккач, кыйсса каһарманы — Фәтхулла хәзрәтнең улы, доктор Әхмәт Мөслимов шундук ФЗУда укып йөргән улы Зыяны үз бүлмәсенә дәшеп алды.

— Әти, бүген безнең гимназиядә бәйрәм булачак! — дип йөгереп керде ундүрт яшьлек Зыя.

Аның йөзеннән, күзләреннән чын бәхет нуры ташып тора иде.

— Бүген бернинди дә бәйрәм булмый, улым, — диде әти кеше кәефсез тавыш белән.

— Нигә шулай дисең, әти?

— Язучы ялгышкан. Син бит ФЗУда укыйсың.

— Ничек?

— Сорама, берни дә сорама. Язучы хыялына гына буйсынмый тормыш дигәннәре.

— Әти, безнең гимназия укучылары вакыт машинасы уйлап тапканнар. Алар...

— Бусы да матур хыял гына.

— Берни дә аңламыйм.

— Улым, бабаңны оныт. Гимназияне дә оныт. Алар барысы да хыял гына. Син ФЗУда токарь һөнәренә өйрәнәсең. Чөнки чынбарлык шундый.

Ул арада бүлмәгә Нәфисә йөгереп керде.

— Әти, сиңа хат бар! — диде ул, аның битеннән үбеп.

Нәфисә чыгып киткәч, әти кеше, зәңгәр тышлы конвертны ачып, тиз-тиз генә хатны укырга кереште. Аның йөзе агарынганнан-агарына барды, маңгаена бөрчек-бөрчек салкын тир бәреп чыкты.

— Шулай дип уйлаган идем мин, — диде ул, хатны йомарлап. — Язучы хаклы. Бабаңны терелткән өчен КГБга чакырталар. Сталин үтерткән меңнәрчә кешеләрне терелтеп, яңадан җәзаларга уйлыйлар. Алар шуннан тәм табалар, улым. Ярый борчылма, килер бер вакыт, заманалар үзгәрер. Аннары бер татар язучысы сине дә, синең бабаңны да үзенең каләме белән терелтер. 1995 елның ахырында булыр бу хәл. Рабит Батулла дигән язучыны эзләп табарсың. Ул сиңа ярдәм итәр.

Икенче көнне доктор Әхмәт Мөслимов КГБга китте һәм кире әйләнеп кайтмады.

... Еллар узды. Ниһаять, Җиргә 1995 елның 29 декабре килеп җитте. Менә шушы ачалак-йомалак Яңа ел алды көнендә Бауман урамындагы 19 нчы йортта урнашкан «Мәдәни җомга» гәзите редакциясенә яше алтмыштан узган ыспай гына бер карт килеп керде. Кергән уңайга ук хатлар бүлегенә төрле моң-зар белән килгән гәзит укучыларны кабул итеп утырган хатлар бүлеге мөдире, алыштыргысыз адвокат Назим Сафиннан Рабит Батулланы сорады. Ул аңа өченче каттагы бер бүлмәне күрсәтте.

Ә бу вакытта Рабит әфәнде, кулына калын бияләй киеп, бер усал ханымның илле дә чәнечкеле хаты белән танышып маташа иде. Анда балаларга Кыш бабай бүләкләрен матур пакетларга тутыручы Рафис Гыйззәтуллин да күренә.

— Бәйрәм алдыннан кәефне бозмасалар да ярый иде, — дип сөйләнә-сөйләнә Батулла ияге белән кулына таянды.

— Бусына гына түзәргә була, — диде Рафис. — Акмалга алимент кәгазе дә килгән әле. Тагын ел буе тәмәке сорап интектермәгәе. Аннары бит, Рабит абый, дөнья хәлләре белән чагыштырганда, бу мәктүб бернәрсә дә түгел. Япуниядә әнә тагын җир тетрәгән, диләр.

— Хабаровскида самолет кадәр самолет та югалган әле, — дип мыгырдады Батулла. — Ничә көн эзлиләр инде, һаман таба алмыйлар. Чит илдән махсус кечкенә вертолет та кайтарткан булдылар инде. Бер экстрасенс әйтеп биргән бугай самолетның кайда икәнен. Башта ук Рафикъ Миңнекәевкә әйткән булсалар... Карале, Рафис, без югалсак, эзләүчеләр булыр микән?

— И Рабит абый, татар язучысы кемгә кирәк? Кадеребез булса, акчаны вакытында түләрләр, гонорарны арттырырлар иде. Америкада бер битлек мәкалә язып ике атна тамак туйдырырга була, ди. Их, нигә генә Америкада тумадым икән мин?!

— Инглиз телен белмәгәнгә күрә... — Батулланың күзләре яшьләнде. — Карале, чыннан да эзләмәсләр микәнни?

— Эзләсәләр, шул баш мөхәррир Зиннур Мансуров белән аның урынбасары Газинур Морат эзләр инде. Синнән башка гәзит чыкмау куркынычы туа бит. Ә менә Миншәех абый Зәбировны көне-төне эзләячәкләр, чөнки авторларга гонорарны ул яза. Шуңа күрә дә самолетлар югала башлагач, бүлмәсеннән кеше өзелеп тормый аның. Саклыйлар, димәк. Штаб кебек кайнап тора Миншәех абыйның бүлмәсе.

— Әссәламегаләйкем, әфәнделәр! Керергә рөхсәтме?

Батулла белән Рафис, сискәнеп, бусагада басып торган картка таба борылдылар.

— Әйдүк, түргә узыгыз! — диде Батулла. — Нинди йомыш?

— Доктор Әхмәт Мөслимовның улы Зыя абыегыз булам мин. «Фәтхулла хәзрәт»не укыганыгыз бардыр инде, шаять?

— Бар, көнишне, бала чакта ук укып чыктым мин аны. — диде Батулла.

— Ярый, сез сөйләшегез, ә мин Шәех абый янына төшеп мении, — дип Рафис үзалдына сөйләнде дә өстәлендә яткан бер көлтә кәгазьне күтәреп аскы катка төшеп китте.

(Дәвамы 6 нчы биттә).

Театрга барган идем...

Марат ИСХАКОВ, рәссам (Казан):

— Сәнгать союченең гүзәллеккә, театрга, яңа спектакль премьерасына омтылышы гадәти хәл.

«Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Тормыш җыры» һәм башка күренекле сәхнә әсәрләре уйналган, тамашачыны сокландырган, үзенә тартып торган әлеге сәнгать бинасына — хәзерге Кәрим Тинчурин театрына олы мәхәббәтем яши. Армиягә киткәнче, 1954 елда ук, биредә халкыбызның сүнмәс һәм сүрелмәс «Зәңгәр шәл»ен караган идем.

Яшьлек елларыннан шушы театрга булган ихтирам әле дә йөрәкне канатландыра, бирегә китерә. Шушы көннәрдә генә тормыш иптәшем Роза белән «Гашыйклар тавы» спектаклен карап киткән идек. Без тамаша залыннан яшьле күзләр белән чыктык. Әсәрнең эчтәлеге дә, артистларның уены да тирән мәгънәгә ия.

Яңа спектакль премьерасына да килдек әле. Биредә игълан буенча ничек өйләнәләр икән, дигән уй безне кабат театрга тартты. Гаҗәп кызык өйләнеп күрсәттеләр бит... Татарстанның халык, Русия Федерациясенең атказанган артисткасы Исламия Мәхмүтова — Фәүзия Кыямовна килеп керү белән сәхнә-фатир балкып, җанланып, дөрләп, янып китте. Чү, янгын түгел инде, ә мәхәббәт ялкыны кабынды. Дистә еллар буена үз бәхетеннән ваз кичеп яшәгән табибә Дилбәр Илдаровнага — Татарстанның халык артисткасы Хәҗәр Шәкүровага ярату, сөю килә. Бу бәхетне кайтаруда Ислам Фоатович — Татарстанның атказанган артисты Нуретдин Нәҗми һәм Әсфән Фатыйхович — Татарстанның атказанган артисты Әнәс Галиуллин нинди генә хәлләргә төшеп бетмәделәр.

Мәхәббәт — ул бик борынгы тема. Аны һәр буын үзенчә яңарта торгандыр. Менә безгә тәкъдим ителгәне — игълан буенча танышу һәм кавышу. Алай да була икән. Шуны бик табигый итеп, ихластан уйнап күрсәттеләр.

Фирадия САБИТОВА, хисапчы (Әтнә районы, Кышлау авылы):

— Мин авылдашларым, савымчылар Таһирә Шәйхиева, Гөлназ Хәкимуллина, Илсөяр Гарипова, бозау карауччылар Рузалия Зарипова, Нәкыя Вәлиева — барлыгы 30 кеше Кәрим Тинчурин театрына «Игълан буенча өйләнү» дигән яңа спектакль карарга килдек. Иске Өҗемнән дә бер төркем колхозчылар шушы спектакльгә килде. Колхоз рәисе Рәшит Хисмәтуллинга рәхмәт инде. Сәнгать йортына сәяхәтне бушлай оештырды ул. Рәисебез яшь булса да, адәм баласына ял, сәнгать кирәклеген аңлый. Ул узган ел да шулай театрга, колхоз автобусына утыртып, сәфәр чыгарткан иде. Җыйнаулашып «Хөйләсез дөнья файдасыз» дигән спектакль караган идек.

Менә бүгенге спектакль дә күңелләребезгә хуш килде. Ул шәһәрдәге ялгызаклар мәсьәләсен хәл итүгә багышланган. Артистларның халыкчан, тамашачыны ышандырырлык итеп уйнавы безне сөендерде.

Без, гади авыл кешеләре, Казан театрына бәйрәмгә килгән кебек киләбез һәм, тамашаны күреп, артистларга рәхмәт укып, өметләребезнең аклануына шатланып кайтабыз. Без, чынлап та, олы сәнгать бәйрәмендә булдык бит. Аны тамашачыга яраткан артистларыбыз Исламия Мәхмүтова, Хәҗәр Шәкүрова, Әнәс Галиуллин, Нуретдин Нәҗми бүләк итте.

Розалия КӘРИМУЛЛИНА, укытучы (Казан):

— Театрга тәрбия үрнәге, гыйбрәт алырга киләм һәм шуны хезмәтемдә файдаланам. Гомумән, студент елларымнан театрга йөрергә яратам. Стипендия алгач та, премьераларга бара идек. Хәзер дә яңа спектакльләрне калдырмаска тырышам. Һәр тамаша яңалык китерә.

Безнең татар театры спектакльләренә хәрәкәтчәнлек, йөз-бит, куллар, аяклар, гәүдә торышы белән аңлатып бирү, рольне ачу хас. Аны урыста пантомима диләр. «Игълан буенча өйләнү» комедиясе дә хәрәкәтләргә бай. Моны коллективның, баш режиссер Рәшит Заһидуллинның зур казанышы дип саныйм. Әсәрнең музыка, җыр белән тулыландырылуы да бик күркәм. Композитор Мәсгуд Имашев дулкынландырырлык бизәлеш иҗат иткән. Артистлар Хәҗәр Шәкүрова белән Исламия Мәхмүтова җырны оста итеп башкаралар.

Әсәрнең төп каһарманы Фәүзия — Исламия Мәхмүтова сәхнә бизәге булып тора. Аның чибәрлеге, осталыгы, килешле киемнәре сокландыра. Бу роль артистка өчен махсус язылгандай тоела. Хәер, артистканың башка уеннары да нәкъ шулай, сәнгать кануннары таләп иткәнчә, тулы көчкә, тамашачыны гашыйк булырлык итеп башкарыла. Үз эшенең бөек остасы ул.

● «Игълан буенча өйләнү» спектаклендә Татарстанның халык артистлары Исламия Мәхмүтова һәм Наил Шәйхетдинов.

Әкрам ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

Тычкан тишегенә сыймаса, койрыгына тубал тага, имеш.

Фәтхулла хәзрәтне уятмагыз

(Дәвамы. Башы 5 нче биттә).

Батулла янә кунак кешегә мөрәҗәгать итте:

— Шәп әйбер язган Фатих ага. Ахырын гына бетермәгән.

Ун-унбиш минуттан чәй кайнап чыкты. Батулла белән Зыя ага тирләп-пешеп чәй эчәргә керештеләр. Фатих Әмирханны, шулай ук Батулланың үзен дә үтереп мактадылар, аларның кайбер әсәрләрен искә төшерделәр.

Зыя ага йомышын әйтүгә, бүлмәдә тынлык урнашты.

— Ленинны да терелтеп караган идем мин, — диде Батулла. — Тик ул үзенең мәсләкләрә челпәрәмә килгәнен, һәйкәлләрен төсле металл итеп Кытайга озатканнарын күреп, хәсрәтеннән серкә эчеп үлде. Йөз елга мавзолейга бикләп куйгач, пенсия дә билгеләргә кирәк иде. Шулай иткәндә, ул юньлерәк нәрсә эчкән булыр иде. Хәер, юлбашчы гына түгел, үзебез дә өчәр ай акчасыз утырабыз. Бу юлы да Яңа елны бәрәңге ашап каршы аласы булыр, ахры. — Батулла өстәлдә яткан утыз битлек хатны читкә этеп куйды. — Менә, бер ханым эт итеп сүккән үземне. Укый-укый күзләрем чекерәеп бетте... Какуй-такуй Ленин серкә эчсен, революция ясап йөреп, Надюшасы белән юньләп-рәтләп чәй эчәргә дә вакыты булмаган аның, дигән. Кем кушкан соң аңа серкә эчәргә? Эчсен иде шунда чәен. Бик каты бәйләнгән үзе. Әйтерсең, Ленин белән бергә йөргән. Чәй генә эчмәгән инде ул, анысы хак. Революционерлар бар чорда да бертөсле булганнар. Син, әнә, Егор Гайдарның чыраена кара. Бер дә ач торган кешегә охшамаган. Халыкның саклык кассаларына салган акчасын талап алды да, рәхәтләнеп яши бирә. Намусым борчый дип серкә дә эчми, асылынмый да. Бер сорау бирер идем мин аңа: шок терапиясе алдыннан үзенең һәм туган-тумачасының акчасын нишләтте икән ул? Нишләтсен инде, валютага әйләндергән, кәнишне. Ельцины да бик арык күренми. Гәүдәле, русский медведь, кем әйтмешли. Анысының инде чыннан да хәләл җефете белән чәйләп утырырлык вакыты юк. Ичкериядә сугыш алып барырга кирәк. Балкан ярымутравын да болгатмыйча ярамый. Бер йомышы төште исә, Билл Клинтон белән кәеф-сафа корырга Америкага оча. Әллә рәхәтлектән, әллә кайгыдан эчә — белмәссең. Хәзер бу таланган, хәерчеләнгән, зверьләнгән Русиягә аек башлай карау бик куркыныч. Сыразу инфаркт алырга була. Күптән түгел, бичара, гөнаһларын юу өчен галәмгә төре белән бизәлгән спутник менгерде. Бера ра вакыт караңгы күккә карарга да курка идем. Узган төнне тулган ай калыккач, күңелем күтәрелеп китте тагын. Дөрес әйткән бит Нияз Акмал, күпме генә биек әйсәләр дә, чиркәүдән дә өстә ай тора, дип. Хәер, дөньядагы бөтен тәреләрне космоска чыгарып боргысалар да зыян юк. Җирдән күренмәячәк алар. Ә Ай күренә!

Син менә, Зыя ага, Фәтхулла хәзрәтне терелтик, дисең. Бүгенге әхлаксызлыкны күреп йөрергә ярылмагае аның. Аннан соң хәзрәтнең тамагын кем туйдырыр? Син менә күпме пенсия аласың?

— Ямаулыкка җитә инде, — диде карт, уңайсызланып. — Анысын да вакытында бирмиләр.

Батулла аңа кырын гына карап куйды.

— Терелтә калсак, миннән акча сорыйсы булма. Хәерчә мин, чын хәерче! Язганнарым өчен юньле-рәтле акча түләсәләр, гәзиттә эшләп йөрер идеммени? Язучылар берлегенә мөрәҗәгать итәр идең, анда да рәт калмады. Элек, ичмасам, аз-маз матди ярдәм күрсәтәләр иде, язучы турында кайгырта торган әдәбият фонды бар иде. Хәзер анысы да исәпкә — бар, санга — юк. Бирсәләр, бәйрәмгә бер шешә «Петровский» да, ярты таяк колбаса. Кулыңа тоттыргач, эчәсең инде. Хәсрәттән эчәсең, агайне. Разве язучы шушы көнгә калырга тиеш? Язучылар берлегенә дә үпкәләп булмый, ул да үзенең бүлмәләрен төрле оешмаларга арендага биреп кенә тамак туйдыра. Китап чыгара торган матур заманнар узды. Чит илдән кергән порнографик әдәбият, ужаслар модада хәзер. Шулай булгач, татар китабы нигә кирәк, татар язучысы нигә кирәк? Яшьләрне кызганам мин. Алар авыр кичерә бит бу хәлне. Без, өлкән язучылар, кем әйтмешли, инде ашасын ашадык, язасын яздык. Ә яшьләргә нәрсә язарга, нәрсә ашарга? Алар турында кайгыртасы иде башта.

Бабаң бик акыллы кеше синең, Зыя ага. Ильминский эшләргә тырышкан эшләрнең һәммәсен үзегез эшләп бетергәнсез инде, дигән бит.

Батулла сүзен әйтеп бетерде генә, өстәл артында муенына тәре аскан бер урыс карты пәйда булды. Йөзен иләмсез озын сакал-мыек баскан.

— Нәрсә? Ничек? — дип мыгырданды ул, йокыдан уянгандай тирә-юньгә каранып. — Минем хыялым тормышка ашты, дисезме?

— Башланды бал-маскарад! — Батулла күзләрен чекерәйтеп аңа текәлде. — Син кем? «Вечерняя Казань» гәзитенең чыршы бәйрәме монда узмый бит.

— Танымаган булып кылана тагын, — диде урыс, тәкәббер кыяфәт белән бармакларын өстәлдә биетеп. — Яхшылап кара!

Батулла әле аңарга, әле күзләре акайган Зыя агага карап алды.

— Ничек дип әйтергә икән, — диде язучы каһкаһә белән. — Василий атакай дисәң, ул синнән бераз чистарак күренә бугай.

— Исеңдә калдыр, Ильминский булырмын мин! Миссионер Ильминский!

— Сине монда чакыручы булмады ич.

— Соң, исемемне телгә алдыгыз лабаса. Шатлыгымнан тәмугтан сикереп чыктым. Тукта, нигә татарча сөйләшәсең әле? Большевиклар татар мәктәпләрен ябып бетермәделәрмени?

— Артта калгансың, Ильминский әфәнде, — диде Батулла. — Бәйсез дәүләттә яшибез без хәзер.

(Ахыры 8 нче биттә).

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?

Җирне сыйдырган рәсем

Гади генә рәсем бит, югыйсә. Сабый баланың төсле каләмнәр белән ясаган рәсеме. Әмма шул кадәр тәэсир көченә ия иде ул. Аңа карагач, янә күктән ыжгырып төшкән бомбалар шартлавын, баш очыннан сызгырышып узган ядрәләр тавышын ишеткәндәй буласың. Күз алдында хәрабәгә әйләнгән йортлар, ут чолгап алган авыллар җанлана. Яшьли үлгән балалар, чәчләре чаларган япь-яшь аналарның илереп елавы йөрәкне сулкылдата. Казан каласының 102 нче мәктәбендә укучы Андрей Вафин иҗат иткән «Сугыш» исемле рәсем каршында тамашачыларның тын калып озаклап басып торуы да, мөгаен, тикмәгә түгелдер. Сугыш афәте күпмә җан тетрәнүләре китереп чыгара. Әле дә, инде 50 еллап вакыт узса да, үткән сугыш бүгенге буыннарга үзенең хикмәтләрен күрсәтә тора. Зәгыйфь, гарип туучы балаларның әле дә кимемәве шул сугышның тәэсиреннән түгелдер дип кем кистереп әйтә ала? Ә кешеләр әле дә булса шулардан гыйбрәт ала алмыйлар, бүген канкоеш тугандаш чичәннәр җирендә дәвам итә.

Җөмһүриятебездә инвалидлар һәм гарип балалар мәнфәгатен кайгырту уңае белән үткәрелгән ункөнлек кысасында оештырылган бу күргәзмә «Без — җир балалары» дип атала һәм ул Казан шәһәренең Совет районы балалар үзәгенә тупланган иде.

Ни аяныч, елдан-ел гарип балалар туу арта бара. Аларның күбесе урын өстенә береккән, аяк-куллары хәрәкәтсез: Кояшны күрүдән, яңгыр шыбырдавын, кошлар тавышын ишетүдән мәхрүм.

Заманалар ни кадәр генә авыр, болгавыр булмасын, язмыш тарафыннан рәнҗетелгән, тумыштан гарип балалар җөмһүриятебездә игътибардан читтә калмый. Татарстанда, Русиядә беренчеләрдән булып, инвалидлар ассоциациясе төзелү, инвалидлар өчен махсус гәзит нәшер ителү — шуның ачык чагылышы. Узган ункөнлекнең дә эчтәлеге бай иде. Инвалидлар мәдәният сарайларында сәнгать осталары белән очраштылар, эшкуарлардан затлы бүләкләр алдылар.



Киләчәктә ничек яшәргә, дип сөйләштеләр, планнар кордылар.

Табигать, физик яктан кемнәрнедер рәнҗетсә дә, талант дигән илаһи көчне кызганмаган. Җөмһүриятебездә эшләп килүче төрле иҗат мәктәпләрендә физик яктан зәгыйфь балалар да рәсем сәнгате серләрен өйрәнәләр. Әйтергә кирәк, бу эшкә бик җитди карыйлар. Совет районы балалар үзәгендә бу көннәрдә барган рәсем күргәзмәсе дә шуны раслады. Анда барлыгы ике йөзгә якын баланың өч йөздән артык рәсеме куелган иде. Күргәзмәгә яшь рәссамнар үзләре дә килгәннәр. Һәркайсы дулкынлана. Дулкынланырсың да, аларның иҗаты белән танышырга дип Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе Абрек Абзгилдин үзе килгән ич. Ә ул рәсемнәр белән танышкач, бик җитди генә:

— Шушы балалар шундый рәсемнәр иҗат итә икән инде, һич икеләнмичә әйтергә була: бездә сәнгать бервакытта да үлмәячәк.

Талантлы рәссамыбызның фикере белән килешмичә мөмкин түгел. Казан шәһәренең Авиатөзелеш районы балалар һәм яшүсмерләр үзәге җитәкчесе Алсу Шәрәфетдинова алып килгән балалар иҗат иткән рәсемнәрне, 121 нче мәктәп укучысы Игорь Кузовков үргән кәрзиннәрне, Совет районы балалар үзәгенә йөрүче Денис Буровның пластилиннан ясаган сыннарын күреп сокланган тамашачылар моның шулай булачагына төгәен ышандылар.

Рафис ӘХӘТОВ.

● Күргәзмәдән күренешләр.

Әкрам ШӘФИГУЛЛИН фотолары.

Илсөяр ИКСАНОВА

* * *

Тагын яңгыр,
Таңгы яңгыр ява.
Шыбыр-шыбыр тора җирләр, күкләр.
Еракларга киткән гөрелтесен
Сагыначак әле,
Сагыначак күпләр.

Ә өлегә шыбыр бу яңгырның
Сокланалар бары сафлыгына.
Юкса, гомер дә бит
Шундый кыска,
Күкрәп үткән яңгыр чаклы гына...

Июнь, 1994 ел.

Аерма

Кояш Тимбиковага

Кояш яна,
Син дә — Кояш,
Янасың.
Хисләреңне ялкын итеп ягасың.
Кояш көлә,
Син дә — Кояш,
Көлесең.
Ул җылыта,
Син дә җылы бирәсең.

Кояш яна,
Син дә — Кояш,
Янасың.
Кояш язмый,
Ә син, Кояш, язасың!

1988 ел.

Нахактан сакла!

Нәкый Исәнбәткә

Юлларны буран каплаган
Бер тарихи кич иде.
Яраларны күмәргәме,
Караларны күмәргәме,
Ап-ак карлар ишелде.

Ак бабай булып каршымда
Гали тарих утыра.
Тырыштым —
Ерак үткәнгә
Төбәлеп тынган караштан
Хакыйкатьне укырга.

Заманалар ярлык тага:
Кемгә ак,
Кемгә кара.
Караны ак кар күмсә дә,
Акны карага төрсәң дә
Барыбер хаклык кала.

Тик нахактан арынганчы
Күпме киселә өмет!
Юлларны кар күмгән төндә,
Күзләрне кан баскан көндә
Нахактан сакла, берүк!

Декабрь, 1989 ел.

Сыңар канат

Фәрваз Миңнуллинга

Таңгы яңгыр ява ярсып-ярсып,
Җанны кыйнап,
Таң йокысын талап.
Сискәндереп аңны, тамчы булып
Бер гыйбарә тамды:
«Сыңар канат!»

Әллә таңгы яңгыр тамчысы ул,
Әллә гомер кичкән ир яше.
Шул тамчыдан тетрәп куйды йөрәк:
Сынык, сыңар канат дигәнче...

Таңгы яңгыр булып явасы бар,
Таралганчы болыт карасы;
Тимгел-тимгел шушы дөньялыкның
Туксан халәтенә тарасы.

Һәм әзлисе шашып үз ярыңны,
Яман ярлыклардан янасы;
Адашасы,
Кинәт таңда айнып,
Сыңар канат булып каласы.

Коя гына яңгыр ярсып-ярсып,
Таңгы шул ул,
Белми чамасын —
Таң сүнгәндә ир-ат керфегеннән
Сыңар тамчы булып тамасын...

Июнь, 1990 ел.

Шигырь сагыну

Умырзая төсе кырларда,
Моңсу,
Кемдер ярын югалткан...
Рәшит Әхмәтҗан.

Умырзая төсе кырларда...
Моңсу,
Йөрәк шигырь югалткан.
«Уянгызз!» дигән тавышың
Яңгырап-яңгырап китә колакта.

Умырзая төсе кырларда,
Уяныплар килә язларым.
Каурый-каурый моңы коела
Кояш эзләп киткән казларның.

Умырзая исе кырларда,
Дулкын-дулкын җанга кагыла.
Шигърият тулы бу язлар
Өзелеп-өзелеп шигырь сагына...

Апрель, 1995 ел.

Рифма

Лена Шагыйрьҗанга

Рифмалашмый калган
Шагыйрь үзе генә...
(Көндәлектән).

...Шагыйрь рифмалашмый
Кала аламыни?
Бу кышларның кары
Җиргә явамыни?

Җирдә эримени
Ул кышларның кары,
Шуңа түземени
Шагыйрәнең җаны?

Ява, эри карлар
Бары җанда гына.
Рифмалаша шагыйрь
Ап-ак карга гына.

Рифмалаша шагыйрь
Язгы гөрләвеккә,
Йөрәк шәүләләре
Төшкән күлдәвеккә.

Рифмалаша шагыйрь
Җәйнең чәлләсенә,
Бәгырьләргә утлы
Чәчәк чигәсенә.

Рифмалаша шагыйрь
Көзнең алтынына.
Түзеп кара җанның
Шундый ялкынына!

Рифмалаша шагыйрь
Дөнья күзенә дә,
Рифмалаша ала
Җирнең үзенә дә.

Мондый каурый карлар
Җиргә ятамыни?
Бу дөньядан безнең
Күңел кайтамыни?

Әрни-әрни сөю
Шагыйрь каләмендә.
Рифмалашсын Сезгә
Минем гамәлем дә.

Яшьлек хаталарым
Кичерерсез, беләм.
Күңел түрегезгә
Шигыремне әләм!

Октябрь, 1995 ел.

Шагыйрь

Мөдәррис Әгъләмгә

Гади иде,
Аң җитмәслек иде
Һәм беркатлы иде сурәте.
Дәреслекләр безгә шагыйрьләрне
Чын фәрештә итеп өйрәтте.

Шигырь язу өчен тумыштан ук
Булу кирәктер шул илаһи.
Хатын-кызга күз дә салмый торган,
Авызына хәмер алмый торган
Даһи кеше булса, билләһи,
Булыр иде шагыйрь...

Кая инде безгә, гадиләргә,
Шигырь язып йөрү, оялмый...
Тик күңелгә килә, килә шигырь,
Хис ташкынын акыл тыялмый!

Илаһилык һәм даһилык дигән
Төшенчәне күпме каерма,
Шигырь язу белән гөнаһ кылу
арасында юк ул аерма.

Шигырьчеләр белән бергә яшим,
Борынгыдан хәмер кабалар.
Сөйләшкәндә кайчак өстән торып
Сөйләшәләр,
Ерак аралар...

Шагыйрь шул икән дип уйладым мин:
Кул җитмәслек биек, югары.
Тик ни хикмәт,
Өстән караучылар
Ялгышып та...
шагыйрь булмады!

Ә ул артык гади,
Сәер бераз —
Астан өскә карый — төбәнәк.
Әгәр дә ул шулай карамаса,
Кояш төшәр иде тәгәрәп!

1988 ел.

Үз оясы алдында
тычкан да арыслан.

Фәтхулла хәзрәтне уятмагыз

(Ахыры. Башы 5, 6 нчы битләрдә).

— Яшисез, пычагым. Татар телен дәүләт теле дип игълан итеп кенә ерак китеп булмый. Син, брагишка, әйләнә-тирәңә күз сал. Министрлар Кабинеты кәнсәләрендә утырган кызыл тырнаклы хатыннар да татарча белмәгәч, нинди дәүләт теле булсын ул? Фәндә дә, производствода да шул ук хәл. Танылган язучы булсаң да, сине монда бар дип белүче дә юк. Кемгә кирәк син, җә? Әбәт ашарга акчаң юк, эшеңә көн саен банка белән аш, каткан сохари ташыйсың, әле анысын да ашарга вакытың калмыйдыр. Хатын колак итен кимермәсен, баламның тамагы тук булсын, дип көне-төне чәрәшеп язасың да язасың. Татарга үз Казанында да рәт юк аңа. Мисалга, Кремльдәге Благовещение чиркәвен генә ал. Тиздән православиелеләр анда гыйбадәт кылачаклар. Казан бавырында һәр якшәмбе носарилар чаң кагачак. Сезнең бәйсез хөкүмәт биргән рөхсәт белән, кәнишне.

Миссионер комга сеңгән су кебек юк булгач, Батулла башын кашып куйды.

— Хаклык бар бу базар бакасының сүзләрендә, — дип көрсенде ул. — Бердәмлек юк татарда. Крылов мәсәләндәге кебек без — йөкне төрлебез төрле якка тарта.

Менә берзаман тәрәзәдә хәрби вертолет күренде. Берәү кулларын болгый-болгый тәрәзәне ачарга куша. Гел булып тормый бит инде мондый хәл, салкын булса да, Батулла тәрәзәне төбенә кадәр ачып җибәрде.

— Син кем? — дип кычкырды ул. — Грачев Татарстанга да гаскәрләр кертергә уйламыйдыр ич?

— Керткәннәрен дә чыгарып булмый әле, — ди тегe. — Чечнядан кайтып килеш безнең.

— Анда сайлаулар узарга тиеш иде. Сайладылармы соң?

— Сайламаган кая, бик шәп сайладылар. Миндә берничә капчык баш ята. Мәскәүгә алып кайтырга иде дә бит, тагын чакыралар, каһәр. Сезнең «Мәдәни җомга» редакциясендә бик салкын, диләр. Бу башларны берара вакыт сездә калдырып торып булмасмы?

— Салкынын салкын да, бүлмәләр таррак шул, — дип җавап бирде Батулла. — Ичкерияга гаскәр керткәнче, Грачевка күбрәк суыткычлар җитештерергә кирәк булган. Аныкын инде хәзер үк суыткычка тыгып куйсагыз да ярый. Чөнки исе Казанга кадәр килә.

Батулла шап итеп тәрәзәне ябып куйды.

— Хәлләр бар безнең калада, — дип көрсенде Зыя ага, өши башлаган колакларын уып. — Мең ел ятсаң да бозылмыйсың монда.

Батулла да тун якасын күтәреп куйды.

— Аңламассың бу урысларны, еле самолетларын югалталар, әле башларын кайдадыр онытып калдыралар.

— Аптырәш инде, — диде Зыя ага. — Бер көнне телевизордан ике урысны күрсәттеләр. Космоска менеп, Русия шәһәрләрен барлап йөргән булалар. Берсе, менә бу — Самара, ди. Икенчесе, менә бусы — Санкт-Петербург, ди. Кайберләренең хәтта исемнәрен дә бутап җибәрәләр. Гаҗәп түгел, үз шәһәр-авыллары да отыры хәрабә хәленә төшә бара бит. Ә үзләре һаман санау белән шөгыльләнәләр. Югалтудан куркалар булса кирәк шәһәрләрен. Чикләре һаман саен тарая бара Русиянең. Космоска менгән теге ике урыстан соң экранда комбайннар пәйда була. Комбайнчылар исә куян тоту белән генә шөгыльләнәләр. Яшенле яңгыр башланганчы уңышны җыеп алырга өлгерербезме, дип сорый бригадир. Җыярсың, куян куып йөргәч. Кеше куян куа дип...

— Булыр, булыр, — дип елмайды Батулла. — Мәскәүдә, әнә, троллейбуска да утырмый башлаганнар. Чөнки халыкның талон сатып алырлык та акчасы юк. Кичке якта телевизордан гел бер буш троллейбус күрсәтәләр. Йөри шунда шәһәр буйлап. Дөрес, бер пассажир бар-барын, тик анысы да троллейбус артына зонтигының көкре тоткычы белән ябышып шуып йөри. Ә троллейбус йөртүче елмая, бер әләктерәм әле мин сине, кызый, дип уйлый, ахры.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Ул күпмегә сузылган булыр иде, белмим, әмма ишектә кулына матур пакет тоткан Рафис күренде.

— Рабит абый, мин бүлеп бетердем, менә малаеңа Кыш бабай бүләге, киләсе елның көзендә алачак зарплатыңнан түләрсең. Ә мин киттем, чыршы артыннан лесхозга барырга кирәк.

Рафис чыгып китте. Батулла, арык кына пакетны өстәлгә куеп, тәрәзә янына килеп басты. Ул уйлый иде.

— Беләсеңме нәрсә, Зыя ага, — диде язучы, бераз маңгаен уып торгач: — Әсәрнең дәвамы безнең гасырда барырга тиеш түгел. Фәтхулла хәзрәт кебек карт кешене кайгыга салу ярамас. Без аны утызынчы гасырга күчерик. Бәлки, ул чакта тормыш аз гына булса да яхшырак булыр.

Батулла үзенең кара түбәтәен киеп, янә киң өстәл артына барып утырды. Һәм йөгерек каләм чиста кәгазь битенә беренче җөмләне сызды:

«3000 ел, зөлһиҗҗә аеның гарвия көне иде...»



Музейханә

Якутлар вакыт

Моннан өч ел элек «Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән татар мәдәнияте музее ачылган иде. Бу зур вакыйга булды, чөнки моңарчы мәдәниятебез тарихына караган бик күп кыйммәтле ядкарьләребез кеше күзеннән читтә ятарга мәҗбүр иде. Билгеле, аларның кайберләре, илдәге сәясәткә бәйле рәвештә, югалгалады яки юкка чыгарылды. Мәдәниятебез тарихын чагылдырган махсус мәдәният музее булдыру элек-электән зыялыларыбызның хыялы иде. Бу идея XX гасыр башында — 1912 елларда ук туа. Казан университеты профессоры Б.Адлер шул чакта ук, татар мәдәниятенә караган экспонатларны җыеп, күргәзмә оештырган, аны йөзләгән казанлылар караган, музей оештыру кирәклеге хакында мәсьәлә дә күтәрелгән, әмма шәһәр администрациясе аны кире каккан.

Ниһаять, 1992 елның көзендә татар зыялыларының күптәнге хыялы тормышка ашты: «Казан» милли мәдәният үзәгендә милли мәдәният музее ачылды. Анда әдәбият, сәнгать һәм тарих бүлеге оештырылып, фәнни хезмәткәрләр мәшәкатьле һәм изге эшкә керештеләр. Безнең бүгенге язмабыз шушы музейның зур өлеше — татар әдәбияты музееның эшен яктыртуга бер омтылыш. Әдәбият музееның үз эшләренә гашыйк дүрт хезмәткәре, армый-талмый, тарихи ядкарьләрне туплау, тулыландыру, булганнарын классификацияләп, тәртипкә салу, яңаларын эзләү белән мәшгуль.

Әле арабызда яшәүче язучылар, сәнгать әһелләре, зыялы затларыбыздан, яисә бакый дөньяга күчкәннәрнең балалары, оныклары, туганнары кулыннан аларның архивларын, нәсел шәҗәрәләрен, тормыш-көнкүреш әйберләрен, хатларын, кулъязмаларын музейга алдыру — әдәбият музееның изге гамәле. Халкыбыз тарихында якты эз калдырган шәхесләрнең иҗатына, тәрҗемәи хәленә бу, бер яктан, яңа сәхифәләр өстәү булса, икенчедән, әлеге шөгыль — музей хезмәткәрләренең үзләре өчен дә кызыклы, романтика белән тулы һәм җанга канәгатьләнү тойгысы сала торган хезмәт.

Шушы өч ел эчендә әдәбият музее фондына биш меңгә якын музей берәмлеге саклауга алынган һәм каталогларга теркәлгән. Алар арасында төрледән-төрле документлар, фотосурәтләр, басма һәм кулъязма китаплар, көнкүреш һәм бизәнү әйберләре, эш кораллары бар. Аларны эзләү, якын һәм ерак җирләрдән алып кайту, музейга кайткач, өйрәнү-реставрацияләү, берничә нөсхәдә фәнни сыйфатнамәләр язу, инвентарь тамгалары салып, картотекага кертү кебек вакыт һәм үҗәтлек таләп итә торган мотлака кирәк эшләре дә бихисап.

Соңгы елларда гына арабыздан киткән әдипләребездән С.Хәким, Х.Вахит, Б.Гыйззәт, Н.Дәүли, Н.Арслан, С.Баттал, И.Туктар һ.б.ларның шәхси архивлары музейга алынды. Халык өчен, тарих өчен һәр талант иясе кызыклы, аларның тормышлары бүгенге һәм киләчәк заманнар өчен гыйбрәтле.

Шуны тирән аңлаган музей хезмәткәрләре гел эзләнүдә, архивларда, музейларда, китапханәләрдә, юлларда... Алар Татарстан районнары, авыллары белән генә чикләнеп калмыйлар — татарлар гомер иткән ерак һәм якын төбәкләргә барып чыгалар. Күп кенә тарихи һәм мәдәни ядкарьләребез әлегә түгелеп-чәчелеп ята. Бу җәүһәрләрне барлау, туплау эшенә әле дә бик соңгарып тотындык, бу юлда иҗтиһат итү бик зарур — бөтенләй соңга калып кую куркынычы да бар...

Бу җәһәттән төрле тарафларга оештырылган фәнни экспедицияләр әйбәт нәтиҗә бирә. Мәдәният музее оешкач, аның әдәбият бүлеге беренче сәфәрен Әлмәт ягыннан башлады. Әлмәт төбәгендә халкыбызның мәдәни, рухи мирасына караган ядкарьләрнең күплеге мәгълүм иде. Чынлап та, «җәтмәгә» шактый кыйммәтле нәрсәләр эләкте. Шулардан иң әһәмиятлесе — Ш.Мәрҗани һәм аның варислары, укучылары тарафыннан язылган «Җиһаннамә» җыентыгыдыр. Китапта география, тарих, астрономия, математика һәм башка фәнни мәгълүматларны эченә алган язмалар тупланган. Ул 1732 елда Константинополь шәһәрендә Кятиб Чәләби тарафыннан языла һәм XIX гасыр урталарында Казанда күчереп алынган дип уйланыла. Мондый сирәк очрый торган җәүһәрләрне «раритет» дип йөртәләр. Әлмәттән шулай ук шагыйрә С.Сөләйманованың архивы да музейга кайтты. Аны шагыйрьнең ире — язучы Әдип Маликов, музей таләпләренә туры китереп, зур осталык белән тәртипкә салып куйган. Әйтергә кирәк, күп кенә язучыларыбызның архивлары түгелеп-чәчелеп ята. Бу яктан Әдип Маликов башкаларга үрнәк булырлык зур эш башкарган, һәм, аның үрнәгендә, язучыларыбыз, үз мирасларына җаваплылык хисе белән карап, соңга калмыйча архивларын тәртипкә китерү турында уйлансыннар иде диясе килә...

Тугандаш Башкортстан җирендә миллион ярым милләттәшебез яши. Бу якта халык кулында сакланган этнографик һәм башка төр тарихи ядкарьләребез моңа кадәр кул да тимәгән килеш ята иде.

Икмәк әйләнәсенә
тычкан да җыела.

Тычкан, казына торгач, мәчене китереп чыгарган.

табыладыр белән...

Әдәбият музее Башкортстанга фәнни экспедиция оештырып яхшы итте. Яңавыл районындагы мәдәни мирасыбызны барлау, җыюга багышланган бу сәфәр нәтиҗәле булды: музейга бик күп бизәнү әйберләре, тукыма сугу станоклары, каба, чигүле намазлыклар, түрләмәләр, сөлге-тастымаллар, кубыз, курайише халык музыка уен кораллары кайтты. Шуңа өстәп, әби-бабайлардан төрле чорларга караган бәет, мөнәҗәт, җырлар, әкиятләрнең кассеталарга язып алынганын да әйтик. Мондый кыйммәтле җәүһәрләр Башкортстандагы милләттәшләр кулында әле дә бик күп. Димәк, бу төбәктәге татар авылларына яңадан берничә экспедиция оештырып, рухи, матди һәм мәдәни мирасыбызга караган байлыкны, соңга калмыйча, җыю зарурлыгы алга килеп баса...

Шулай ук Касыйм шәһәренә бару да музей фондларын тулыландыруга зур өлеш кертте. Өлкән буын кулында иске кулъязмалар, бәет-мөнәҗәтләр, борынгы көнкүреш әйберләре кадерләп саклана әле. Милләттәшләр арасында үзенең нәсел агачын — шәҗәрәсен белүчеләр шактый. Шундыйлардан Вергазовлар, Костровлар, Ерзиннар һәм башкалар. Мәскәүдә күренекле тарихчыбыз Газиз Гобәйдуллинның улы Сәлмән яши. Ул әтисенең бай архивын тулысы белән диярлек әдәбият музеена тапшырды. Бу архивта туганлык җепләре белән бәйләнгән зыялыларыбыз Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим һәм Айтугановларга кагылышлы документлар саклана. Тарих һәм әдәбият галимнәре өчен әлеге әйберләр — бәһаләп бетергесез гыйлем чыганагы...

Кайчагында көтелмәгән кызыклы очрашуларга тап буласың. Музей хезмәткәрләре дә Мәскәүдә татар скульпторларының беренчеләреннән булган Садри Ахунның гаиләсендә булып, аның хатыны Юлия Павловна белән танышалар. Аның кулында татар мәдәниятенә кагылышлы зур байлык



саклана икән. Юлия ханым музейга Г.Тукайның һәм М.Җәлилнең С.Ахун иҗат иткән бюстларын бүләк иткән. Бу экспедиция вакытында да тарихи реликвиягә юлыгалар: дворяннар нәселеннән чыккан Гөлнар ханым Мамишева архивында 1812 елгы Ватан сугышында татар-башкорт полкы командиры буларак катнашкан Гәрәй Кайбишевның алтын ука белән чигеп эшләнгән билбавы — кушагын «кулга төшерәләр». XYIII гасыр азагында эшләнгән билбау белән бергә, Гөлнар ханым музей өчен кулъязма китаплар, нәсел шәҗәрәләре, мөнәҗәтләр, шигырьләр бүләк итә. Бу сәфәрдән әдәбият бүлеге мөдире Индусә Минһаҗева һәм музейның фонд бүлеге мөдире Галия Саттарова мул «табыш» белән кайталар. Музей бу юлы «Шура» журналының 1913 елгы төпләмәсе, шагыйрә З.Бурнашева хатлары белән тулылана. Онытылмас истәлекләр, кызыклы очрашулар, күзәтүләр дә бар бит әле. Урыс мохитендә гомер иткән татарларның урыслаша баруын күреп бер көенсәләр, шул йогынтыга бирешмичә, иманнарын саклаган милләтпәрвәр кешеләрнең очравына куанып та кайталар. Шунысы да гыйбрәтле: соңгы елларда татарлар яшәгән төбәкләрдә уянуга, берләшүгә, мәчетләр төзүгә, ана телен, йолаларны, го-

реф-гадәтләрне торгызуга омтылыш нык сизелә.

Әдәбият музееның фәнни хезмәткәрләре Ләйсән Гыйниятуллина һәм Рәмзия Хәлиуллина да Ырынбур ягына оештырылган экспедициядән шундый ук тәэсирләр алып кайттылар. Элек-электән мәдәниятебез учагы булган Ырынбур төбәге мәдәни ядкарьләргә аеруча бай.

Ырынбурдан кайткан хәзинә арасында ниләр генә юк! Кулъязма һәм басма китаплар, төрледән-төрле фоторәсемнәр, бәетләр, мөнәҗәтләр, гасыр башында нәшер ителгән гәзит һәм журналларның төпләмәләре, 20ләп пластинкасы белән патефон, ике пар сафьян читек, кулдан бәйләнгән, ындыр табагы кадәр чын дебет шәл... Кызыклы очрашулардан иң әһәмиятлесе — дистә еллар буена тарихыбызны, мәдәниятебезне өйрәнүгә, актыртуга зур өлеш керткән олпат шәхесебез — Мәдинә ханым Рәхимкулова өендә булу. Бу милләтпәрвәр галимә, талантлы журналист, төбәкне өйрәнүче олы шәхеснең исемен белмәгән кеше сирәктер. Ул — татарның мәгърифәтчеләре, галимнәре, сүз осталары, әдипләре, артистлары турында тулы бер образлар галереясе иҗат иткән абруйлы шәхес. Мәдинә ханым Р.Фәхретдинов, Дәрдмәнд, Тукай, Ф.Кәрим, С.Сүнчәләй, Т.Ченәкәй, Ш.Мөхәммәдев, К.Тәфкилев, М.Җәлил һ.б. турында искиткеч бай мәгълүмат туплаган. Ырынбур татар драма театры һәм аның артистлары, «Хөсәения» мәдрәсәсе һәм аның мөгаллимнәренә багышланган альбомнары да игътибарны җәлеп итә. Узган ел «Казан утлары» журналының октябрь санында галимебез Р.Әмирхан Мәдинә ханым эшчәнлеге турында тәфсилләп язып чыккан иде. Шуңа күрә аның эшчәнлегенә артык тукталмыйча, мәдәният музеена тапшырган кыйммәтле хезмәтләре турында әйтеп үтик. Ике бүлмәле кысан фатирын музей хезмәткәрләре Әбугалисина белем туплап яткан әкияти мәгарәгә охшатканнар. Кая карама, китаплар, гәзит-журнал төпләмәләре, фотосурәтләр, кулъязмалар... Җентекләп системага салынган, тиешенчә тәртипкә китерелгән гаҗәеп бай архивы да хәйран калырлык икән. Мәдинә ханым Казан кунакларын өниләре кебек ачык йөз белән каршы алып, кулындагы байлыктан музей өчен юмарт өлеш чыгарган. Дәрдмәнд, Ш.Мөхәммәдев, Г.Исхакый, М.Бигиев, Тукай һ.б.ларга багышланган истәлекләр, кулъязмалар. зур шәхесләребезнең шәҗәрәләре — бихисап күп материаллар биреп җибәргән. Ләйсән һәм Рәмзия ханымнарны Ырынбур гәзит-журнал нәшрияты фотохәбәрчесе А.Мирзаханов озатып йөргән һәм фотосурәтләр белән ярдәм иткән. Бүген музейга алып кайтып тапшырылган бу хәзинәне тәртипкә салып, фондка урнаштыру эше бара.

Күргәнегезчә, мондый фәнни экспедицияләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур һәм аларны ешрак оештыру зарур. Татарстанның үзендә дә эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк. Екатеринбург, Башкортстан, Үзбәкстан, Чиләбе, Курган кебек татарлар тупланып яши торган төбәкләрдә милләттәшләребез кулында яткан тарихи һәм мәдәни истәлекләрне эзләү, халыкка кайтару турында әйтәсе дә юк... Мәдәният музееның татар әдәбияты бүлеге фәнни хезмәткәрләре бу эшне бик теләп, яратып, көч һәм тырышлык куеп башкаралар. Алай гына да түгел, фондка кергән ядкарьләрне тизрәк халыкка күрсәтү, галимнәргә җиткерү буенча да эшлиләр. Үзәктә оештырылган «Җиде бабаңны беләсеңме?» дигән шәҗәрәләр күргәзмәсе — шуның ачык мисалы. Шәҗәрәләр күргәзмәсе анда байтак вакыт эшли инде. Аның максаты — тарихыбызны, бай рухи мира-

сыбызны җентекләп өйрәнү, милли хәтеребезне яңарту, тарихи шәхесләребезне барлау.

Гомумән, «Казан» милли мәдәният үзәгендә урнашкан татар мәдәнияте музее һәм аның әдәбият бүлеге фондларында бәяләп бетергесез рухи мирас саклана. Аның белән якыннан танышу, кирәгенчә файдалану өчен музей ишекләре һәрвакыт ачык. Рәхим итегез!

Салисә ГӘРӘЕВА.

● Кәрвансарай (Ырынбур).
● Касыйм хан дәвереннән сакланып калган мәчет.
● Касыйм татарлары чиккән калфаклар.

А.МИРЗАХАНОВ фотолары.



Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Гыйнвар аенда булачак спектакльләр

2, 3, 4, 5, 6, 7, 8 — Рәдиф СӘГЪДИ **БАҺАДУРНЫҢ ЯҢА ДУСЛАРЫ**

9 (сишәмбе) — Наил ГӘЕТБАЙ **ӘСТӘГЪФИРУЛЛА...**

10 (чәршәмбе) — Илдар ЮЗЕЕВ **ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ**

11 (пәнҗешәмбе) — Наил ГӘЕТБАЙ **АТЫ БАРНЫҢ — ДӘРТЕ БАР**

12 (җомга), 21 (якшәмбе, көндез һәм кич) — Шамил ФӘРХЕТДИН **ЙОЛДЫЗЛЫ ЯҢГЫР!!!**

14 (якшәмбе, көндез) — Шамил ФӘРХЕТДИН **ӘКИЯТ ТУРЫНДА ӘКИЯТ**

14 (якшәмбе, кич) 25 (пәнҗешәмбе) — Эсфир ЯҺУДИН **МӘХӘББӘТКӘ МӘДХИЯ**

16 (сишәмбе) — Шакир МӘҖИТОВ, Илдар ЮЗЕЕВ поэмасы буенча **РЕЗИДӘКӘЙ**

17 (чәршәмбе), 27 (шимбә, кич) — И.ГРЕКОВА, Фәһим СИТДЫЙКОВ инсценировкасы **ТОЛ ХАТЫННАР КӨЙМӘСЕ**

18 (пәнҗешәмбе), 28 (якшәмбе, кич) — Нуретдин НӘҖМИ инсценировкасы **ИГЪЛАН БУЕНЧА ӨЙЛӘНҮ**

19 (җомга) — Нурихан ФӘТТАХ, Фәһим СИТДЫЙКОВ инсценировкасы **ИТЕЛ СУЫ АКА ТОРУР**

20 (шимбә, көндез) — П.О.БОМАРШЕ, Г.ШАМУКОВ тәрҗемәсе **ШАУ-ШУЛЫ КӨН, ЯКИ ФИГАРОНЫҢ ӨЙЛӘНҮЕ!**

23 (сишәмбе) — Разил ВӘЛИЕВ **ӘЙДӘ БАРЫЙК, КЫЗЛАР КАРЫЙК!**

24 (чәршәмбе) — Кәрим ТИНЧУРИН **ХӘЙЛӘСЕЗ — ДӨНЬЯ ФАЙДАСЫЗ**

26 (җомга), 27 (шимбә, көндез) — Хәй ВАХИТ **КИЯҮЛӘР**

28 (якшәмбе, көндез) — Ризван ХӘМИД **ИСӘНЛЕККӘ-САУЛЫККА**

31 (чәршәмбе) — **КОНЦЕРТ-ТАМАША** Узган һәм киләчәк сезоннарга багышлана

Театрның баш режиссеры — Рәшид ЗАҺИДУЛЛИН.

Спектакльләр көндез 12, кич 19 сәгатьтә башлана.

Хәтер кайтавазы

Рөстәм КУТУЙ

Күкрәкләргә калдык Комсызланып, ныграк

(Эссе)

Дөшмә инде, уята күрмә минс,
Һай, артыктыр яшәмәвең
бу гонаһлы,
Бу өшәке гасырларда
берни тоймый...
Йоклау — ярый, бер таш булсаң,
бигрәк яхшы.

Микеланджело Буанаротти.

Бу дөньяда гомер итүләре беркайчан да җиңел булмаган. Озын-озак тарихның энә буе гына бер өзегендә без дә иза чигеп маташабыз инде, дип уфтанып, яңа кием алырга хәлдән килмәгәч, сандыклардан былтыргы бишмәтләрне тартып чыгарабыз. Шулай инде: асрауларыбыз да, хезмәтчеләребез дә юк — андый рәхәтлекләр безгә язмаган инде. Аларын, әнә, патша сарайлары сыман күп-күп тәрәзәле пулат ияләре күрсен. Балаларын өйдә генә укытырга гувернер да, маэмайларын карарга эт үстерү осталары ялларга да хәлләреннән килә аларның. Әйе, яңа гасырга аяк басар алдыннан без аның теге очында булып үткән гүзәл Рәсәй чынбарлыгыннан бик әллә кайларга китә алмаганбыз икән шул. Ул заманнарда да бит «күпчелек» газап чиккән, ә «азчылык» бизәнеп-төзәнеп, типтереп яшәгән, диләр. Нәфрәт кайнаган, имеш, буталышканнар... Ә коймакның кайнары безгә дә килеп эләкте менә. Ничәмә-ничә буыннар аны каба-каба авыз пешергәннәр инде, югыйсә...

Юаныр өчен генә әйтмим мин боларны.

Рәхәтлекләр турында сөйләнгән сүзләрнең бөтенесен бергә җыйсаң, бик тә мул бер хәйрия ашы пешеп чыгар иде, дөрес, тәмгә бик тәмле булмас иде ул. Күрдек инде, күрдек. Булды барысы да. Туйганчы ашадык та, йөреп тә күрсәттек. Ә аннары инде Василий Розановча китә:

Шалтыр-шолтыр килеп, сыкрап, чинап,
Тимер пәрдә төшә Россиягә.
Көмит тәмам. Кайда тун, өй? Кара!
Тун юк чөйдә, әллә кайда өй дә...

Василий Розановка ул пәрдәнең әле тагын ничә тапкыр төшеп, ничә тапкыр күтәрелә язуын, чыдам тормыш сәхнәсендә булачак гаҗәптән гаҗәп тамашаларны күрергә насыйп булмады. Аның каравы безнең үзебездә дә тәҗрибәсе дә, хыялы да җитәрлек Чиксез дисәң дә була хәтта. Әлбәттә инде, безнең анда «роль башкаручы» да, тамашачы да буласыбыз килеп тормый.килүен.

«Ямьсез тәэсирләр җеназасын алып чыгу беравыкка кичектерелә!» — Киләчәккә өмет баглаган берәр кемсә, бәлкем, шулай дип сөрән салыр иде.

Кучереп язучы хаттабларның берәр оятсызы тарихны бозып язадыр дип уйлыйсы килә дә бит... Нишлисең, хаталарын килер буыннарга төзәтергә туры килә:

Сезгә әйтәм, мәгълүм өшәкелек
Кылып даны чыккан аталарның
Каберләрне пычрак аяк белән
Таптап узган сансыз балалары!
Азатлыкның, Зурлык һәм Шөһрәтнең
Җәллады сез тәхет янындагы,
Ач күзләр сез, ни ул сезгә хаклык! —
Сезнең кулда — Хөкем кануннары.

М.Лермонтов.

«Менә мине дә тыңлап кара әле син», — дип әйтә сыман М.Лермонтов монда В.Розановка.

Ә без, шул «тимер пәрдә»не сүгә-сүгә арып беткән адәм балалары, аның шакшы кашагасы аркылы нәрсә генә күрә алдык соң? Ике меңенче елга аяк басар алдыннан нәрсә күрәбез? Бу тамашаны, әйдә, «вакханалия» дип атап торыйк инде.

Кеше гомеренең бәясе хисапсыз, монда тиеннәрне санап кына котыла алмыйсың.

Рәхәтлеге белән «дөньяны коткарачак» Матурлык әлегә күп хәсрәтләр иясе булган Ф.Достоевскийның бер матур әкияте булып кына кала бирә. Әмма шундый да төшкә генә керерлек әкиятме соң бу? Адәм баласы гел-гел хыял белән генә хушланып яшәгән микәнни?

Алай түгел икәнлеге көн кебек ачык моның. Матурлык һәрвакыт булган да, бар да ул, аны бернәрсә дә каплап тора алмый. Кайгыларың да, җитешмәүчелекләрең дә. Аның һәркем өлешенә тиярлеге бик билгеле һәм аны сатып аласы да юктыр. Федор Достоевскийдан өч сүзне суырып алганнардыр да, шул бер уңышсыз символга әверелеп киткән инде. Аныс шулаен шулай да, бик үк алай да түгел бугай шул әле... Матурлык кешелекне атабыз Адәм белән анабыз Хәва заманаларыннан бирле коткара килгән. Аны тарихи порцияләргә, мөхтәрәм кешеләр өчен генә әзерләнгән аерым «меню»га да бүлгәләп булмый. Шул аш кайнату юлларына һич катнашы булмаганга күрә дә Матурлык дип атала торгандыр инде ул.

Ул чәчәкләр, төклетура, чирәм,
Ул башаклар, рәшә, зәңгәр күкләр!...
Килер бер көн. сорар Ходай бездән:
«Йә, таптыңмы бәхетләр, — дип, — җирдә?»
Башларымны куеп тезләренә,
Әйталмамын берни, яшькә буылып,
Өндә булыр бары чирәмнәрне,
Башакларны ерган басу юлы.

Иван Бунин, 1918.

Шулай, эш башкада шул! Союдә эш. Тирәндәге киңлекләргә карарга, колакларыңны ныграк торгызырга кирәк. Эчеңә сеңдерергә!

Шагыйрьләрне «исәр» дип күпме генә тиргәмәсеннәр, алар барыбер бик тә җитди «халык». Алар — сөя, алар — рух өрә. Аларның сүзе дә берәгәйле: «Сөям Ватанымны, тик бик сөер сөю белән сөям». Кадаклый да куя: бернинди мөнбәрдән дә фаш итә алмыйсың моны, әллә нинди чоңгылларга чумып та, андый «исәр», «сөер сөю»ләрне учыңа тотып чыга алмыйсың.

Иллюзия ачыкканнарга гына аш ул, ә барыбер эчәсе килгәнне басарлык көче юк аның. Һәм Аллага шөкер! Сусаганны ни баса соң?

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы...» дип ерак-ераклардан өн сала Тукай.

Җан әрни, җан өзгәләнә.

Дөнья болдыры

Станциянең бер-ике чарпылышкан уты күзне кисеп кала да, аннары караңгы чоңгылга чумгандай буласың Аннан ары битләрне яндырып алган кышкы салкын төш. Кар шыгырдый, шау-шу. Аркага асылган капчыклар, бер-берсен каплап китә торган кычкырулар. Әнием белән без, чуен юлга басканбыз да, аптырашта калганбыз. Кайда без, кайсы вакыт бу һәм нигә без монда? Бу мәгънәсез, котың очарлык төнне кысан булса да әле җылы вагоннан артына тибеп тышка очырганнар диярсең. Кайнар паровоз мышнап куя, борын тишекләреннән ак тынын көпчәк асларына өрә, «туктап торып өшеп китмим тагы» дигәндәй, бөтен тимер буыннарын шалтыратып кузгала да, үз юлыннан ашык-пошык китә башлый. Пар елан кебек елтырап торган рельслар ыслап ята сыман, әллә колак чыңлый шунда. Һәм бик каты йокы килә. Их, йоклыйсы калган икән бераз җылы вагонда...

Ул да булмый, безнең янга алагаем толыплар кигән ике өрәк килеп баса, яныбызда кайнаша башлыйлар болар, төенчекләрне алалар, ә мин һавага очам. Һавада йөзеп барам. Төштә йөзеп баргандай... Чанага җигелгән ат кырын карый, колагын шомырайта. Борынга печән арасыннан җиләк исләре килеп керә, аста чана табаннары сызгырып-сызгырып куя. Толып астында рәхәт — күз кырые белән генә басуны карап барам — бигрәк киң инде: кара кантарлары ак көмешне төртеп-төртеп чыккан.

Һәм тагын җылы юрган асты, чип-чиста ап-ак җәймәләр, йомшак түшәк, яңа мамыклары шыгырдап-шыгырдап куя торган рәхәт мендәр. Бүлмә тактасы артында шыпырт кына нәрсәдер сөйләшәләр, чыра да яна сыман. Сап-сары идәнгә тәрәзәләрдән ап-ак нур бөркелә. Аяк-кулларым җылы юрган астында оеп ята, теге якта әнием тавышы, мичтән җылы бәрә — аннан тәмле-тәмле аш исләре килә. Сыйланабыз болай булгач. Әй, дөньяның бу рәхәтлекләре!

Аннары инде мин өстәл янына менеп кунаклыйм. Өстәл — мич дигән җанвар янында. Җанварның кайнар тамагында ялкын ургый, үзе тыныч кына ыңгырашып куйгандай итә. Алдымда — куе каймак, май диярсең. Кулымда — ипи телеме, калын итеп теленгән, авызга көчкә-көчкә сыя. Янымда әбиләр, апалар йөри, ак яулыклары гына җилпенеп-җилпенеп киткәли Баштан сыйпап-сыйпап алалар: тамагы ачкан лабаса бу баланың. Үзләре нәрсәдер көтә сыман, кычкырып сөйләшү юк, көтү тынлыгын бозасы килмәүләредер, мөгаен Бөтен җирдә — пакьлек. Соң, әлбәттә, көтәләр инде! Сизәм бит, баш очымда авазлар пәрәвезе шулай дип тирбәлә ләбаса.

Тагын башымнан сыйпыйлар, алдыма ашъяулыкка бозланып каткан бер уч кып-кызыл җиләкләр сибелеп төшә Рәхмәт әйтергә дип башымны күтәрәм. Күзләрем дымланган олы күзләр белән очраша. Ул күзләр нәрсәдәндер сагаеп калганнар, аларда — караңгылык нуры Дулкынланып китәм, шул күзләргә керәсе килә. Әмма тирә-яктагы тынлык аптырата. Нәрсә көтәләр? Кемне? Әллә берәрсе кайта микән? Әнием дә минем монда икәнемне оныткан сыман: шыпырт кына һаман сөйләшәләр дә сөйләшәләр, миңа күз кырые белән генә булса да карап алу исләрендә дә юк. Кулларын тезләренә чүмеч кебек иттереп куйганнар да, һаман сөйләшәләр. Үзләре бөтенесе дә хатын-кыз: берсе керә гора, берсе чыга тора. Ак җәймәләр элгәннәр, алар ак көрсәнү сыман җилфердәп-җилфердәп куялар. Һәм һәр тәрәзәдән, ишек ярыгыннан сөттән ак имин яктылык иңеп тора. Мин бармы соң монда, юкмы? Алай дисәң, менә бит инде мин, телсез калганмын, көннең башын бер аваз белән дә борчымаска кирәк дип курыкбрак торамын. Алар көткәч, мин дә көтәм инде.

Болдырдан мин ялкын капкан ак кар өстенә төшәм. Кояш саламны алтын суына манган, аның нурлары атның кыңгыр күзендә дә уйный. Ат сыртыннан аз гына пар күтәрелә. Кар җеби, ойый.

Борылып карасам, болдырда теге миңа кызыл җиләк керткән апа басып тора. Иңнәренә тун салган. Туны астыннан зур корсагы бүлтәеп тора. Ап-ак алсу битләре теге бозлы җиләкләре сымаграк. Чүмәләмә җиләк тутырган табак каршына иелгәндер дә, шул җиләкнең алсу пары йөзенә иңәдер кебек. Парны җил алып-алып китә дә, ул кабат аның битләренә килеп куна.Көтү тынлыгы, ак яулыклар, дөньяның иртәнге уяну өне нишләптер шул апаның олы корсагы белән, җепшек карда уйнаган кояш нурлары, зәңгәрсу аяк эзеннән калкып чыккан салам бөртеге белән бергә кушыла.

Мартның шушы бөтенесен дә үз эченә тутырган яктысын, балан салган авыл каймагын, атның шәмәхә кыңгыр карашын һәм теге чибәр яшь татар хатынын мәңге оныта алмамындыр инде. Сугыш бетәргә таба борылган көннәр иде шикелле бу...

Җиде-сигез яшьтә нәрсә аңлаганмындыр инде мин?

Ә җаным аңлаган бит, күңелем сизенгән.

Шул чаклардан бирле минем күз алдымда март ае кар астыннан баш калкыткан салам бөртегедәй җилферди сыман, нидер көтеп колагын шомрайткан сыман. Ни көтеп? Анысын кем белгән инде...

Һәм дөнья болдырында теге олы күзле чибәр апа тәрәзәләр нурында һаман да шул иртәнге алсу парларны сулап торадыр шикелле.

Үр иңендәге чишмә

Безнең өйдән чыгып, бер биш минутлап бардың исә, үрләр башланып китә. Баштарак мин әле шундый рәхәтлекләр кочагында торганымны белмәгәнмен. Аның якынлыгы тоелмаган, бар да кил

Тычканнан курыккан иген икмәгән, бүредән курыккан көтү көтмәгән.

Тычканның үләсе килсә, мәче белән уйный.

тойгыларны кысабыз

гена булгач, шулайдыр инде ул, бернинди транспортыңның да кирәге юк. Күңелең тошкән вакытларда күңел күтәрүләр, ялгызың гына, йә этеңне җитәкләп рәхәт чигүләр шунда булган икән. Битләреңне анда киңлекләр иркәли, күзләреңә бозлардан арчылган тыңгысыз сулар килеп тула. Шунда инде син тар да, озын да урамнардан «кесә тулы борчаклы» малай чакларның ап-ак келәмнәр җәеп куйган, һичбер зынҗыры булмаган киңлекләренә килеп чыгасың. Анда инде син үзеңнең бөтен дөньясына берденбер икәнлегеңне тоя башлыйсың.

Шәһәрдәге үрләр, ташу сулары, җир өстендәге тәтемсә томаннар, шул томаннар астыннан баш төрткән сап-сары чебеш көтүедәй тузганак чәчәкләре, йөгерек аккаеннар, картлык исе сеңеп өлгергән, ачып күперә башлаган озын кыштан котылу галәмәте шуларда түгелме соң инде! Таллыклар кипшерә башлый, аста ермак үз көен көйләп маташа, ә син иң өстә бер җиңүче кебек басып торасың. Кемне, нәрсәне җиңгәнсеңдер инде, Ходаем! Җиңел аяклы бер малай түгел ләбаса инде. Малайлар йөрәге генә ул күңелләре тулы мәңгелек кебек тоелган шатлыклардан җиңүче була, кайнар кавышулар көтеп дымланган яшь егетләр генә җиңүче була.

Бик карт кеше дә түгел инде мин, үземә калса. Әмма үр башында син күрекле инде, анда син тормыш вак-төякләреннән азатсың. Сине зәңгәр күкләр күрә, бичара каеннар, чия куаклары. Үрләр үзләре дә күрә сине. Син монда дөнья кешесе, киңлек әһеле буласың. Һәм галәмнең шушы булмас карашлары астында күңелгә тәшвиш тә килеп куна: ә син үзең әле — сугыш чукмары — йөрәкләрең бик кызып китеп, бик артык кыйланып җибәрмәдеңме икән? Юк шикелле, кеше битенә чапканың булмады бугай. Ә сүз белән? Менә шул шул: булган бит, булган. Бар булган көчем белән хәлсез куәтемә бәргәнмен. Немец иде ул кеше! Булганмы? Булган анысы да... Һәм үрләрем тетрәп киткәндәй булды...

Бу хәл хәзерге Самар каласы кырыенда булган иде. Без килеп чыккан җирдә кешегә бернинди зыяны тими торган немецлар тора иде. Үз мәктәпләре, фатирлары бар, балалары йөгерешә-йөгерешә уйнап йөриләр. Әүвәлге немецлар түгел инде, «һейнкел-дринкелләр». Без аларны шулай үртәп йөри торган идек. Болар Идел буе немецлары түгел, белгечләр иде, ахрысы. 55 нче ел китте. Әй ул яшәүләре, ул тормыш матурлыклары. «Кадерле юлбашчыбыз» үлгәч, дөньялары да үзгәреп киткәндәй булды. Минем дә, унны бетереп, тизрәк Казанга таясы килә башлады. Тик миңа әйтеп куйдылар: немецлар белән аралашсаң, йә булмаса алар белән бер-бер хәл китереп чыгарсаң, 24 сәгать эчендә эзең суынган булыр, диделәр. Их, Красная Глинка — Кызыл Балчыгым!.. Ә биергә дип килгән немец кызлары көзен бик тә моңсу булалар. Безнең исә уңга-сулга карамыйча яратасы-яратыласы килә. Яшьлекнең бу зырлап әйләнүен һич тә туктатырмын димә. «Дукат» сигаретлары тутырган челтәр биштәрен тотып шунда каршыга бәләкәй этен җитәкләп бер немец килеп чыкмасынмы! Күз алдында шул немец та, әтинең үлеме турындагы кәгазь. Әйе, әйе. Менә яз көне комсомол җыелышыннан соң без бер дус малай белән, ишекне эчтән тартып, кызларны клубка кертми торабыз, курыкмыйбыз, шаярабыз, көләбез. Фрейлинын култыклап яшьрәк бер немец килә бит. Без аңа:

— Хәзер кертәбез, — дибез.

Ә ул бармакларын бөгә-бөгә:

— Бер!.. Ике!.. Өч!...— дип санады да минем дусның яңагына чабып та җибәрде. Чөнки дустым миннән калкурак иде. Елмаеп торган авыздан кан китте. Шуннан башланды инде... Сызгырабыз, селтәнәбез, шаулыйбыз. Немец аркасын терәгән, мин аның каршысына басканмын. Шунда гына милиционерлары котыртып тора, паника китте.

— Менә монысы әтием өчен! — дип бирәм моңа. — Монысы әнием өчен! — дип кабаланам. — Монысы үзем өчен.

Һәм мәтәлчекләп кар көртенә сикерәм. Тыным кысыла — малайлар янына чабам. Шундый апрель иде, югыйсә. Үрләр! Мин шуларның берсенә менәм дә кайгыга сабышам.

Владислав Артамонов дигән дустым соңрак хәрби очучы булып киткән иде. Шул янган самолетыннан парашют белән сикереп котылган. Ә җиргә төшкәч: «Кая штурманың? Нигә аны ташлап үзең сикердең?» — дип бәйләнә башлаганнар. Дөньяда бөтенесен дә аңлатып буламыни? Дускай каты итеп эчә башлады. Гаиләсе дә таркалды. Беравыктан үлеп тә китте. Йөрәгендә каны укмашкан булган. Белгеч немецлар китеп бардылар, безгә үч итеп, утыннарын да калдырмадылар. Безнең мәктәптә соңгы апрель иде, немецларга кул да болгап калмадык. Юкса, болай үзләре тыныч халык иде инде. Шунда без дус малай белән ерактагы үрләргә тын гына карап торган идек.

Син эчтән үзгәреп торган һәр җирдә үрләр була.

Без үзебез дә бик тигез генә түгел бит. Болыннарда чәчәкләр җыеп кына йөрмәдек ләбаса. Үргә йөгереп менгән чаклар да, аска тәгәрәгәннәр дә булмады түгел. Төрлечә инде без — тау итәгендә бер төсле, өстә — башкача.

Миңа рәхәт, йөгереп төшү дә, йөгереп менү дә үз иркеңдә. Хәрәкәтнең үзгәреше үзе дөньяңны яктыртып җибәрә, язлар белән язлар алышынган саен шулай итә. Үрләрнең гел янда гына булуы ул Төңренең бер бүләге сыман, әйтерсең, мин шәһәр тәзеклегеннән читтә, җир белән күк тоташкан бер җирдә торам.

Кая инде миңа җиңүче булулар, Аллам сакласын, шушы үр түбәсендә мин — үз юлымның тыныч бер мосафиры, үз өем-учагымның, үз хәтеремнең бер бәндәсе. Беркемгә кызыкмыйм, беркемнән йөз чөермим.

Караталларны яратам, үр итәгендәге иясез чияләрне. Бер өрүгә өннәрем таралып югалыр сыман. Тузганак кебегрәк.

Чишмә янына төшәм. Ул ерактан яктырып күренеп тора. Аның янында төрле савытлар тоткан халык. Саф суын эчәргә чират торам. Ә өстә — үрләр китә.

Эльс ГАДЕЛ тәрҗемәсе.

Рәссам остаханәсе

Авангардчы — димәк, алдан баручы

Кеше акылы эзләнүләр аша гаҗәп хәлләргә юлыга һәм төрледән-төрле иҗат нәтиҗәләре бирә. Әнә рәссам Наталья Бенинг хезмәтенә карап та шуны әйтергә мөмкин. Ул табигатьне, кеше холкын һәм аның халәтен үзенчә ача. Тормышның чынбарлыгы төштәгечә чагылыш таба, балаларга хас беркатлылык һәм гадилек күренеп тора аның эшләрендә. Ул егерменче гасыр башындагы беренче дулкын авангардчыларга тартым юлдан бара. Ләкин яшь рәссам дөньяны үзенчә таный, үзенчә күрә һәм үзенчә иҗат итә.

Күптән түгел «Ренессанс» арт-галереясында Наталья Бенинг, Олег Иванов, Вадим Харисов иҗатына багышланган күргәзмә булып узды.



Рауза СОЛТАНОВА,
«Казан» милли мәдәният үзәге фәнни хезмәткәре.

«Казан» милли мәдәният үзәге

Гыйнвар

2 — 10 (көндез). Татар мәктәп-гимназияләрендә укучы балалар өчен «Кар калада Яңа ел» дигән әкият-спектакль

2 — 10 Татар мәктәп-гимназияләрендә укучы югары сыйныф укучылары өчен «Яңа ел балкышы» дигән кичә-дискотека

26 «Таныш исемнәр» кичәсе. Зилә Сөнгатуллина белән очрашу.

13, 14, 20, 21, 27, 28. «Могҗизалар дөньясында» (киноклуб) 15.00 сәгатьтә.

Ай дәвамында «Тылсымлы дөнья» (мультклуб)

4, 11, 18, 25. «Аулак өй» — яшьләр өчен кичә-дискотека.

6, 13, 20, 27. «Культур клуб» урыс телендә алып барыла торган дискотека

23 декабрь — 10 гыйнвар. Миргазиян Юныс һәм Илдар Зарипов әсәрләре күргәзмәсе.

Ай дәвамында рәссам Илгизәр Хәсәнов картиналары күргәзмәсе

Тычканга йон чыккан саен катырак чиный.

Халык хадимнәре ничек киенә?



Яңа ел кичендә без яңа-матур киемнәребезне киеп, мулдан табын әзерләп, туасы елны каршы алабыз. Хәзер өнә йолдызнамә белән шөгыльләнүчеләр-күрәзәчеләр кайсы елны нинди төстәге кием белән Яңа ел табынына утырырга кирәклеген алдан ук әйтеп бирәләр. Аларның әлеге фаразлары хактырмы-юктырмы, әздереп кенә әйтүе кыен. Дөрес булса, гади халыкның эшләре хәрти бит әле. Инде ничә еллар дәвамында көч-хәл белән генә очын-очка ялгап яшәгән гаиләңне ничекләр итеп затлыдан киендермәк кирәк?! Торгынлык елларында сатып алынган кием-салым инде тәмам эштән чыгып бара. Яңасын алыр идең... Хәер, әйдәгез, башта искеләрне бераз хәтердә яңартып алыйк әле. Монда безгә «Аргументы и факты» газите ярдәмгә килер.

...Бервакыт Үзәк Комитет пленумында шау-шу куба. Сәбәбе — Леонид Ильич Брежнев олы җыенга зәңгәр көчтүм-чалбардан килә. Моны күргәч, Үзәк Комитет әгъзалары аптырашып бер-берсенә карашалар. Чөнки ул заманнарда политбюро әгъзасының үз белдеге белән кием алыштыруы Советлар Союзы Маршалы мундирын соры төскә манып кию белән тиң санала. Леонид Ильичның кием алыштыруын янәшәдәгеләр тиздән кадрлар алмаштыру башланачак дип юрыйлар. Димәк, Сусловның йогынтысы кимегән.

Ул заманнарда совет сәясәтчеләре соры төсне хуп күрәләр. Соры төс аларны киендереп торучы SUSLOFF модельләр йортының фирма билгесе булып та санала. Воротников-Слюньков иптәшләр дә шушыннан киенә. Дөрес, болары эшләпәнең фасонына, пәлтәнең озынлыгына әллә ни дикъкать бирмиләр. «Яңа тарихи җәмгыять хуҗалары» асылда сексуаль кыяфәтне ассызыклап күрсәтүче киемгә күбрәк игътибар итәләр, ачык төсле тукымалардан тегелгән кием-салымга мөкиббәннәр. SUSLOFF модельләр йортының соры тукымаларга «мәхәббәт»е, чынлыкта, аның үз клиентларына ярарга тырышуыннан килә. Чөнки тегеләре үзләреңӊ «күренмәс җаннар», «футлярдагы кеше» итеп тоялар, аларның үз йөзләре дә юк, сөйләгән сүзләре дә стенага борчак ату кебек кенә тәэсир калдыра. Леонид Ильичка кире әйләнеп кайтсак, ул да башка совет чиновниклары кебек үк, кием-салымның нинди булуына әллә ни игътибар итми. Аңа хәләл җефете Виктория пешергән борщ һәм ул үтүкләп биргән күлмәк кенә булсын. Чынында Леонид Ильич үзебез үк озак еллар хуплаган җәмгыять җимеше иде һәм аның тормышы, кием-салымы турында, нигездә, янәшәсендәге яраннары кайгыртты, бу исә аның рухи ярлылануына, балыкның башыннан черүенә китерде. Ә теге мәсьәләгә килгәндә — аның яңа фасон белән тегелгән көчтүм кия башлавына модельер Александр Игманд сәбәпче булган икән. Ул Бөтенсоюз модельләр йортының складында Англиядә эшләнгән тукымага юлыга һәм Леонид Ильичка капиталистик дөньяда эшләнгән «авангард» формада тегелгән көчтүмне киеп йөрергә тәкъдим ясый... һәм менә шул көнне, ягъни Брежнев «зәңгәрләнгән» көнне — тарихи көн дип санарга була. Яңа зәңгәр көчтүмне иң элек Горбачев күреп ала. Илдә үзгәртеп кору башлана.

Михаил Горбачев властька килгән көннән үк дөнья гизәргә кереште. Хәтерегездәдер, сәяхәтләргә ул хәләл җефете Раиса Максимовна белән бергә йөри торган иде. Шуларның берсендә, дөресрәге, Англиягә баргач, шау-шу тудырган бер фоторәсем җирле газит-журнал битләрен йөреп чыкты. Анда Англия королевасы белән Раиса Максимовна аяклары янәшә сурәтләнә. Королева очрашу хөрмәтенә күзгә әллә ни бәрелеп тормый торган оек кигән, аякларына классик стильдәге кара башмаклар элгән. Горбачева ханым исә, совет иленең дәрәҗәсен төшерәсе килмичәдер инде, ялык-йолык килеп торучы оектан һәм алтынланган башмаклардан басып тора.

Бу хәлне Раиса Максимовна тиз төзәтә һәм башка шундый олы очрашуларга болай ук затлыдан киенеп бармый башлый, «яңа политик фикерләү»нең кием элгеченнән үк башлануын тиз төшенә. Ирле-хатынлы Горбачевлар моннан соң үзләренең тышкы кыяфәтләренә аеруча игътибар итәләр, тора-бара алар моңа кадәр партаппаратчыларның язылмаган законнарын бозалар — совет илендә тегелгән кием-салымнардан баш тартып, чит илдә тегелгән киемнәрдән йөрүне хуп күрәләр. Сүз уңаеннан әйтик, инде менә хәзер Зюгановның да «Большевичка» фабрикасы теккән кием-салымнан баш тартуы билгеле булды.

Михаил Горбачев Аурупага тәрәзә уйды, ул киясе киемнәр Италиядә тегелә иде. Әмма барыбер ул халык арасында көчтүменең төймәсен чишеп җибәрергә, күзгә артык бәрелеп торган галстук бәйләргә өйрәнә алмады. Горбачевның затлы киеме үк аның гади халыктан бик ерак торуын күрсәтте һәм ул, шул ук вакытта, яңа барлыкка килгән аристократиягә дә якыная алмады. Ни дисәң дә, ничә еллар дәвамында коммунистлар партиясендә тәрбияләнгән кеше иде ич ул.

Бүгенге көн демократларының киемнәре төрледән-төрле, чуар. Мәсәлән, Көнбатышка мөкиббән киткән Гайдар халык алдына рәсмилек төсмере бирә торган киемнән чыкмас. Тышкы кыяфәте белән ул, сәяси лидер булудан да бигрәк, бизнесменга тартым.

Явлинский исә илне һәлакәттән бары икътисадны җайга салып кына коткарып булачак дип кабатларга ярата. Ул чиновниклар кия торган кара көчтүмнән йөри. Шахрай исә алтын урталыкны хуп күрә. Аның ачык төстәге киемнәре Ельцин яратып кия торган көмеш төсен сеңдергән «фирменный» көчтүмнән һәм президент яраннарының соры төстәге киемнәреннән күпкә аерылып тора. Премьер-министр Черномырдин кебек үзенең тышкы кыяфәтен алай ук кайгырткан кеше бүгенге көндә юк дисәк тә хата булмас. Ул салмак классик стильне хуп күрә. Тик... сәясәтчеләребез үз-үзләрен никадәр генә карарга тырышмасыннар, аларның омтылышлары безнең карашка очрап чәлпәрәмә килә тора. Чөнки Русиядә мода артыннан куучыларны яратмыйлар, кем гади итеп киенә, шул халыкта абруй казана.

Борис Федоровның гадилеге халыкта нинди мәхәббәт уятканын хәтерлисезме? Хәтта аның чыгышларындагы фикерләргә игътибар да итми башладылар. Сайлаучылар аңа карап: «Менә бу — эш кешесе, ичмасам. Күлмәген үтүкләргә дә вакыты юк», — дип тел шартлаттылар, сокландылар. Шушы ук алымнан Мәскәүнең үзгәртеп кору каһарманы Юрий Лужков та оста файдалана. Бу өлкәдә аңа киеп алгач, йөзен ачып җибәрүче, мөлаем итүче фуражкасы зур ярдәм итә.

Әйе, без шундый инде: җиңнәре сызганулы, муенын кысып торган галстугын бушатып, күлмәгенең өске төймәсен ычкындырып җибәргән сәясәтчеләрне үз итәргә гадәтләнгәнбез. Шуңамы, Борис Ельцин телевизордан беренче тапкыр чыгыш ясаган көннәреннән үк миллионлаган тамашачының күңелен яулап алды. Кем кем, ул үзенең тышкы кыяфәте, кием-салымы белән үзенең көндәшләрен бик күпкә узып китә. Ул беренчеләрдән булып үзенең яраткан свитеры һәм теннис уйнаганда кия торган кыска ыштаны белән телевизордан күренде. Тирләгән йөзен тастымал белән сөртеп алуны да гадәти бер хәл дип санады. Борис Николаевич, Себер ягында туып-үскән кеше буларак, салкын, кышкы төсләрне хәтерләтүче көчтүмнәргә өстенлек бирә. Шулай да икеләнмичә әйтергә була, халыкка ул үзенең спорт киемнәреннән күбрәк ошый.

Дөрес, бу өлкәдә Борис Николаевичның көндәше дә бар. Ул да булса — Жириновский. Чөнки анысы Борис Николаевичны да уздырып җибәрде. Ул парлы мунчада да, уйнашчылар клубында да сурәткә төшүдән тартынып тормады.

Русиядә янә президент сайлаулары булачак. Һәм, әлбәттә, шул урынга дәгъва кылучы тузган джинси чалбардан халык алдына чыкса, өстәмә тавыш җыячагына шикләнмәскә мөмкин. Имеш-мимешләргә караганда, Билл Клинтон президент булып сайланганда халыкның нечкә күңеленә өнә шулайрак тәэсир иткән, имеш.

Кызганыч, кичә коммунист булган, ә бүген демократка әверелгән үзебезнең җитәкчеләребезнең нинди киемнәрне яратып киюләре турында әлегә тулы мәгълүматлар юк. Хәер, Татарстан халык депутаты, язучы Разил Вәлиев бу мәсьәләгә олы җыеннарның берсендә ачыклык кертергә омтылды омтылуын. Аның менә болайрак чыгыш ясаганы хәтердә калган:

— Безнең халыкта түрәләргә хөрмәт, башлыкларга охшарга тырышу бик борынгы заманнардан килә.

Әле дә истә, моннан берничә ел элек, ул чактагы Премьер-министрыбыз Мөхәммәт Сабиров затлы мехтан ындыр табагы кадәр фуражка тектереп кигән иде. Бер айдан соң Министрлар Кабинетындагы утырышка хакимият башлыклары җыелды. Карасам — шаккаттым. Илле хакимият башлыгының иллесенең дә башында шул ук ындыр табагыдай фуражка. Соңрак бу фуражканы совхоз директорлары, колхоз рәисләре тектереп киде. Аларның мехы очсызрак иде, билгеле. Тора-бара республикада шундый фуражка кимәгән җитәкче үзен чалмасыз мулла кебегрәк тоя башлады.

Менә шундый-шундый хәлләр, җәмәгать... Чыннан да, кием генә димәссең...

Язманы **Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН** әзерләде.

Мөгезле мәзәкләр

* * *

Анасы кызын битәрли:
— Төне буе кайда булдың?
— Лутчы син кем белән булдың, дип сора.
— Йә, әйт алайса?
— Милли каһарман белән.
— Кем соң ул?
— Билгесез солдат.

* * *

Ятакта егет белән кыз.
Егет:
— Кадерлем, мин сиңа хәзер Хәва дип эндәшермен инде? — ди.
— Ни өчен?
— Чөнки син минем беренче мәхәббәтем булдың.
— Яхшы. Ә мин сиңа «Москвич» дип эндәшсәм, ярармы?
— Ни өчен?
— Чөнки син минем 412 нче мәхәббәтем.

* * *

Купеда үзара таныш булмаган ир белән хатын бара. Ир һич кенә дә юлдашына сүз катарга җөрьәт итми. Менә ул кәгазьгә рюмка рәсеме ясый да, сорау билгесе куя. Хатын баш кага. Ир сумкасыннан коньяк тартып чыгара. Эчәләр. Ир янә кәгазьгә сигарет рәсеме ясап, сорау билгесе куя. Хатын, ризалыгын белдереп, янә баш кага. Тарталар.

Бераздан хатын да караватрәсеме ясап, сорау билгесе куя.
— Ә сез минем мебель кибете директоры булып эшләвемне каян белдегез? — дип гаҗәпләнә ир.

* * *

Кызның атасы кияү буласы егеттән сорый:
— Сез кәрт уйныйсызмы? Хәмер эчәсезме? Тәмәке тартасызмы? Хатын-кызлар белән чуаласызмы?
— Юк.
— Алайса бернинди туй да булмаячак, чөнки хатынымның сезне миңа һәрвакыт үрнәк итеп куюын теләмим.

* * *

— Полковник, әйтегез әле, яшь вакытта сез бигрәк тә ниләр белән мавыктыгыз?
— Ау һәм хатын-кызлар белән.
— Ни ауладыгыз соң?
— Хатын-кызлар.

* * *

Ике дус гәпләшә. Яшьрәге сорый:
— Карале, дускай, иң тугры хатыннар нинди була икән — сарымы, әллә кара чәчлеме?
— Чал чәчле.

* * *

Ике ахирәт кыз сөйләшә.
— Беләсеңме, мин ни өчен табибка кияүгә чыгарга булдым? Чөнки, авырып китсәм, ул мине һичшиксез дәвалаячак.
— Ә мин руханига кияүгә барырга карар иттем. Әгәр хыянәт итсәм, ул мине гөнаһларымнан арындырачак.

УНӨЧЕНЧЕ БИТ

Шамил Маннапны без әлегә кадәр шагыйрь вә прозаик буларак яхшы белә идек. Баксаң-күрсәң, ул мыштым гына халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп, үзе дә мәзәкләр язып яткан икән. Күбесе — зыялыларыбыз турында. Ә андый кызыклы шәхесләрнең тормыш-көнкүрешен кемнең генә күбрәк беләсе килми икән?

Шушы арада безнең хәбәрчебез Шамил Маннап белән кечтеки генә әңгәмә корып алды.

— Шамил абый, халык мәзәкләрен җыю һәм язу уе Сездә кайчан бөреләнде?

— Бишектә ятканда ук. Мин балачакта елаграк булганмын. Шуңа күрә әни мине халык көйләрен җырлап юаткан, әти (сугышка киткәнче) мәзәкләр сөйләп елмайта торган булган.

— Инде бүгенге катлаулы, елаграк заманда үзегез моңлы җырларыгыз белән халкыбызны юатырга, мәзәкләрегез белән аның күңелен ачарга телисездер...

— Нәкъ шулай. Өстенә генә китереп бастыгыз.

— Бик хуп, бик изге теләк. Безнең «Мәдәни җомга» үзенең бер сәхифәсен һәрвакыт көлкеле әсәрләргә багышлый. Сез, Шамил абый, «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан» гәзитләрендә, аеруча «Чаян» журналында күп кенә мәзәкләр бастырып чыгардыгыз...

— Минем бер шөлкем мәзәкләрем сезнең могтәбәр гәзитегездә дә басылып чыкты бит инде. 17 ноябрь санында, «Казан утлары» журналына багышланган сәхифәдә дөнья күрде алар. Тик анда, нишләптер, минем исем шәрифемне куярга гына онытканнар.

— Бәлки, укучы болай да белер дигәннәрдер.

— Әмма бит мондый мәзәкләрне Батулла да, Фәнзаман Баттал да, Марсель Гали дә язып тора... Шулай да, зыялылар һәм, гомумән, халкыбыз арасында тиз арада хөрмәт казанган «Мәдәни җомга» гәзитенә мин бик теләп тагын бер шөлкем мәзәк бирәм. Шагыйрь Гәрәй Рәхим әйтмешли, иптәшләр үзебезнеке — бәлкем гаеп итмәсләр. Әле киләсе ел башында «Казан утлары» журналында да мәзәкләремне басарга вәгъдә итеп торалар.

Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтим: «Казан» журналы китапханәсе сериясендә озакламый «Шаман мәзәкләре» дигән китабым да басылып чыгарга тиеш. Мәзәк яратучылар түбәндәге адрес белән заказ биреп куя алалар: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. Шалтырату өчен телефоннар: 53-06-07, 49-36-76, 49-39-44.

— Мәгълүм җырыгыздагыча итеп әйтсәк, рәхмәт сезгә, Шамил абый, мәзәкләрегез өчен!..

Шамил Маннап кытыклары

Шәйхи ага рәхмәте

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әдипләрнең түгәрәк туган көннәрен нинди дә булса бүләк белән билгеләп үтә.

Менә бервакыт Шәйхи Маннурга 75 яшь тула. Идарә рәисе Гариф Ахунов Әдәби фонд директоры Лерон Хәмидуллин янына киңәшкә кер

— Шәйхи абзый — зур язучы, ниндирәк бүләк алыйк икән? — ди ул.

Лерон, башын кашып, уйланып торганнан соң:

— Чыннан да, аңа транзистор гына бирү килешмәс, — ди. — Әйдә, без аңа шәп бер телевизор бүләк итик! Рәхмәт әйтсен әле безгә.

Шулай килешәләр. Лерон, җиңел машинага утырып, кибеттән кибеткә чаба, ниһаять, телевизорны табып ала һәм Шәйхи аганың фатирына илтеп үк бирергә була. «Әйдә, сөендерим әле үзен!» — дип уйлый ул.

Бирнә сандыгы зурлыгындагы телевизорны көч-хәлгә күтәреп, Шәйхи аганың дүртенче каттагы фатирына күтәрелә, коридор идәненә куеп, бер кулы белән маңгаендагы тирен сөртә, икенчесе белән ишек кыңгыравын баса. Җиңел пижамадан Шәйхи Маннур килеп чыга. Эшнең нидәлеген аңлап алганнан соң ул рәхмәт ишетергә өметләнеп торган Әдәби фонд директорына әйтә:

— Ни чуртыма дип алып килдегез бу шайтан әрҗәсен? Шуңа табынып утырмасам, минем башка эшләрем беткән дип белдегезме әллә, пнимаешь?

Премия алып, акчасыз калган

Журналист-язучы Марсель Зарипов, Хөсәен Ямашев исемендәге премия алганнан соң, ике көн узгач, Язучылар берлеге идарәсенә килә.

— Миңа акчалата ярдәм итсәгез иде... — ди ул.

— Әле генә премия алдың бит, — диләр андагы иптәшләр.

Марсель Зарипов әйтә:

— Нәкъ менә шуның өчен кирәк тә инде миңа акча. Шул премияне «юа-юа» бурычка баттым. Биш тиенлек куян — ун тиенлек зыян гына булды ул премия...

«Свижигә охшаган!»

Нәшриятта бүлек мөдире булып эшләгән Наил Мостаевка бервакыт баш мөхәррир Марс Шабаевның үзе белән бер мәҗлестә булырга туры килә. Башка вакытта синнән аз гына «ис» килгәнне сизсә дә, талканы коры булган баш мөхәррир мәҗлестә нишләсен инде, башкалар белән беррәттән, Наил Мостаев белән дә чәркәсен чәкештереп эчми хәле юк. Шуңа күңеле булып микән, Наил Мостаев та баш мөхәррирне күкләргә чөеп мактый. Имеш, безнең Марс Садриевич үз кул астында эшләүчеләргә карата гаять игътибарлы, күңеле гел изгелектә... Кыскасы, мәҗлестән соң алар ахири дуслар булып, кочаклашып аерылышалар.

Икенче көнне баш мөхәррир Наил Мостаевны кабинетына чакырып ала. Башка вакытларда Наил Мостаев бүлмәдәшенең ике җилкәсеннән тотып (тегесе авып китмәсен өчендер инде), авызына «пуф-ф!» дип сулышын өрә дә: «Миннән ис килмиме?» — дип сорый, аннары исне бетерү чарасын күрә торган була. Бу юлы исә, кичәге мәҗлестән соң, бәйләнеп матамшмас дип уйлап, саклык чараларын кулланмый гына, үз нәчәлнигенең кабинетына юнәлә.

Әмма ул ялгыша. Өстәле янына килеп басуга, Марс Шабаев борынын җыергалап:

— Тагын салгансың бит, хәсис! — ди моңа.

Наил Мостаев, тәмәкедән ысланган тешләрен күрсәтеп, елмая:

— Кичәге... Үзең белән бергә булганныкы гына...

— Юк, бу свижига охшаган! — ди баш мөхәррир.

— Ну, Марс Садриевич, үзең дә... эт кебек сизгер инде, — дип кичәге мактавына нокта куя Наил Мостаев.

Бәхет өчен күп кирәкме?

«Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире, шагыйрь Рәдиф Гаташның каләмдәшләре белән очрашканда сәлам биргәннән соң: «Бәхетлеме син? Хәлләр ничек?» — дип сорап куя торган гадәте бар. Җаваплар төрлечә була, әлбәттә. Әйтик, Рөстәм Мингалим болайрак җавап бирә:

— Шундый шәп! Просто түзеп булмаслык. Тик шунысы гына начар: киләчәктә тагын да шәбрәк булуы мөмкин.

Мөгъсүм абый Хуҗин баш бармагын тырпайтып, кыска гына итеп:

— Әтәч кебек! — дип куя.

«Хәлләр ничек?» — дигәнгә Мөшәррәф Гали:

— Алкоголь инде, алкоголь! — дип җавап кайтара. Ал да гөл инде янәсе.

Шаһинур Мостафин исә әлеге сорауга, киң елмаеп, болай ди:

— Әйбәт бит, дустым. Гөлләр кебек!

Бер читтән, өз генә өстәнрәк карап торган Тәүфикъ Әйдинең йөзе җитди:

— Хы, нәрсәсе әйбәт икән? Хезмәт хакын да үз вакытында бирми башладылар...

— Кайгырма, дустым, — ди Шаһинур. — Авылда күптән бушка эшлиләр. Әле Президент аппаратында эшләүчеләр үзләре дә бер айдан бирле зарплата ала алмыйлар икән.

Инде Тәүфикъ та елмая:

— Хы! Син шуңа ышандыңмы? Хы-хых! Ай, көлдердең тәки. Син шуңа ышандыңмы?

— Ышанырга кирәк, дустым.Ышана белү — үзе зур бәхет ул, — ди Шаһинур. — Менә мин ышануым аркасында сине елмайта алуым белән икеләтә бәхетлемен!

Җанлы шигырь

Бервакыт Зөлфәткә студент кыз үзенең шигырьләрен күтәреп килә. Танылган шагыйрьдән фикер әйттерергә, мактау сүзләре ишетергә исәбе.

Зөлфәт тегенең кульязмасын игътибар белән укып чыга да күтәрелеп кызга карый. Чибәр икән, каһәр! Аннары тагын кульязмага текәлә, бераздан тагын карашын кызга юнәлтә.

— Да-а... — ди ул сузып. — Үзең шигырьләреңнән талантлырак икән. Сирәк-мирәк киресенчә дә була...Бу юлы алай түгел икән. Син, сеңлем, үзең җанлы шигырь. Шулай булгач, шигырь язып азаплануыңның кирәге бармы икән?!.

Җыен акыллы арасында... ялгыз

Язучы Марсель Галиев үзенең иҗат кичәсен уздырганнан соң, икенче көнне бер каләмдәше белән очраша. Соңгысы ниндидер сәбәпләр аркасында әлеге кичәгә баралмый калган икән.

— Язучылар күп килгән идеме соң кичәңә? — дип сорый ул Марсельдән.

— Акыллы язучылар барысы да килгәннәр иде... — ди Марсель, киная белән төрттереп. Тик тегесе дә җавабын таба:

— Һи-и, алайса җыен акыллы язучы арасында ялгызыңа гына бик кыен булгандыр инде...

Кызым Миләүшә белән. Июнь, 1987 ел.
Рөстәм МАННАПОВ төшергән фото.

«Әлтернәтиф» дәва

Ил дә сырхау, илдә мин дә сырхау,
Дару да юк, белмим нишләргә?
Шул гипнузны бик файдалы, диләр,
Ләкин
Җилләр исә кесәдә.
Шулчак (менә бәхет!)
Эфир аша
Кандидатлар миңа эндәште.
Сүзләре лә, бал-шикәрдән татлы,
Әчкән чөемә сеңә ширбәте:
«Бар да яхшы булыр... бар да яхшы...
Тавыш бирсәң миңа әгәр дә,
Бу дөньяда сиңа оҗмах булыр,
Кытлык булмас акча-сәмәнгә...»
«Әлтернәтиф», ягъни төрле алар,
Бер үк булсалар да вәгъдәләр.
Беләм инде:
Тәҗрибәле егетләр дә шулай,
Өйләнгәнче
Кызлар башын әйләндерәләр.
Әмма нишлим,
Тыңлый-тыңлый тәки ышанам.
Ит булмаган чакта — үпкә тансык,
Вәгъдәләргә күңел сусаган.
«Бар да яхшы-ы бу-лыр, миңа
рә-ә-әхәт...»
Изрәп китәм... Миңа файдалы.
Кем ничектер,
Ә мин һәр сайлауда бушлай
Алам «әлтернәтиф» дәваны.

Тычкан мөгезле булмас.

Миркасыйм ГОСМАНОВ, академик:

«Австралиядә һәр милләт үзе теләгәнчә яши»

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, Татарстан Республикасының дәүләт делегациясе рәсми визит белән Австралиядә булып кайтты. Делегация составында күренекле галимебез Миркасыйм Госманов та бар иде. Без аңардан ерак Австралиядә алган тәэсирләрен уртаклашуын үтендек.

● «Җыен» фонды исеменнән Татарстанның вәкаләтле вәкиллегенә истәлекле бүләк тапшыру.

— Миркасыйм әфәнде, иң әүвәле Австралия дигән серле ил турында беркадәр мәгълүмат бирсәгез иде?

— Австралия XYIII гасырда Британия империясе тарафыннан ачыла һәм колония рәвешендә буйсындырыла. Һәм озак еллар дәвамында ул империягә, Русиянең Себере кебек, хөкем ителгәннәрне, җинаятьчеләрне сөрү урыны булып хезмәт итә. Бары XIX гасыр башыннан алып аны нормаль кешеләр тарафыннан колонизацияләү башлана. Беренче чиратта Германия, Англия, Франция һәм башка илләрдән чыккан — эшләр өчен, нормаль тормыш өчен җир эзләгән кешеләр исәбенә колонизацияләнә. Элекке сөргендәгеләр дә һәм беренче колонизаторлар да хәзер әдәбиятта абориген дип атала торган җирле кабиләләрне кысрыклыйлар, хәтта аларны физик юк итәләр. Шуңа күрә хәзер Австралиянең җирле халкы аз, күпчелеге махсус резервациядә (территориаль автономия кебек нәрсә) яши. Австралиядә Аурупа халкы X1X гасыр ахыры һәм XX гасыр башларында күбәя, хәзер биредә 18-19 миллион кеше яши, шуларның нибары 300 мең чамасы гына — аборигеннар. XX гасырның урталарында һәм икенче яртысында анда Аурупа технологиясе бик нык үзләштерелә. Хәзерге вакытта халык санының остәмә рәвештә үсүе Көньяк-Көнчыгыш Азиядән, бигрәк тә Кытайдан килгән мөһаҗирләр исәбенә бара. Мул, иркен җирләрнең булуы, табигатьнең байлыгы, үзләштерелгән алдынгы технология һәм эшчән халыкның булуы анда бүген хөкем сөргән бай тормышны барлыкка китергән. Гомумән, Австралия кыйтгасы, минем карашымча, ул XXI гасыр кыйтгасы. Аның әле чын-чынлап чәчәк ату мөмкинлеге бик зур.



● Коньяк. Австралиянең Милли паркында.

— Татарстан делегациясенең ни сәбәпле Австралиягә барып чыгуы хакында җәмгатьчелек инде белә. Шулай да бу делегация майтарып кайткан эшләр хакында Сезнең шәхси фикерегез нинди?

— Һичшиксез, бу турыда минем фикерем уңай. Һәм аның төрле сәбәпләре бар. Беренчедән, җөмһүриятебезнең халыкара бәйләнешләргә актив керә башлавын күрсәтә торган яңа факт бу. Кайберәүләр ерак илләргә барып сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыру күпмегә файдалы булыр икән дип шөбһәләнә. Минемчә, акыл белән эш иткәндә Татарстан һәм Австралия сәүдәсеннән дә дәүләтебез файда күрә алачак. Өстәвенә Австралия белән хезмәттәшлеккә керү ул — шул регионлагы башка илләр белән дә элемтәгә керү өчен ачкыч табу дигән сүз. Чөнки Австралия белән партнер булу ул — Татарстан өчен бәяләп бетергесез зур реклама. Мәсәлән, Австралиядән кайтышлый Малайзиядә туктаган чакта бу илнең тышкы эшләр министрының делегацияне махсус кабул итүе — шуның бер чагылышы. Ниһаять, шуны да өстәп әйтергә кирәк: Австралиядә, Малайзиядә, Таиланд һәм Һиндстанда туктаган чакта да Русия Федерациясе илчеләре делегацияне каршы алып, аны кунак итәргә һәм ярдәм итәргә тырыштылар. Бу да җөмһүриятебезнең абруе үсә баруына бер мисал.

— Австралиянең үзендә кабул итү ничегрәк булды?

— Минемчә, анда да бик әйбәт булды. Бер кечкенә факт: Аделаидада рәсми делегацияне Британия берлегенең андагы махсус вәкиле — генерал-губернатор, ягъни Англия королевасының вәкиле кабул итте һәм Татарстан вәкиллеге оештырган зыяфәткә — банкетка да килде. Рәсмилекне бик нык саклый торган Британия генерал-губернаторы тарафыннан мондый адым ясау күп нәрсә турында сөйли. Шул ук вакытта Австралиядәге диаспораның тырышлыгы, иҗтиһады хакында да әйтергә кирәк. Безнең делегациягә карата булган мондый хөрмәт аларның үзләренең абруе хакында да сөйли. Дөресен әйткәндә, мондый делегациянең ерак Австралиягә баруына һәм бу сәфәрнең тормышка ашуына безнең андагы милләттәшләр, бигрәк тә Садрилар гаиләсе сәбәп булды. Мәсәлән, моннан 3-4 ел элек Казанга килгән Сәгыйть әфәнде Садри шундый хезмәттәшлек хакында хыялы булуын миңа сөйләгән иде. Аның улы Рөстәм Садриның — бүгенге Австралиядәге күренекле бизнесмен-эшмәкәрләрнең берсенең — җөмһүриятебезнең Австралиядәге вәкаләтле вәкиле булып билгеләнүе дә күп нәрсә хакында сөйли.

— Андагы диаспора кайчан оешкан?

— Татар кешесенең Австралиягә беренче барып чыгуы гасырыбызның башына карый диген мәгълүмат бар. Әйтик, Австралиягә тимер юл салыр өчен Русиядән барган эшчеләр арасында татарлар да булган, имеш. Берән-сәрән татар гаиләләре Икенче бөтендөнья сугышы вакытында барып чыкканнар. Ләкин чын-чынлап татар диаспорасы оешу гасырыбызның 70-80 нче елларына карый. Нигездә Кытайдан һәм беркадәре Төркиядән килгән татарлар исәбенә оеша ул. Берән-сәрән БДБ илләреннән киткән татарлар да бар. Җыеп әйткәндә, хәзер Австралиядә 500 гә якын татар кешесе бар. Аларның күпчелеге табигать шартлары безнекенә якын булган Аделаида шәһәрендә яши. Тагын шунысы да характерлы: бу диаспора сан ягыннан әле үсәчәк, чөнки һәр гаиләдә 5-6 шар бала тәрбияләнә.

— Аларның рухи, мәдәни тормышлары хакында ни әйтер идегез?

● Ләйлә Садрига аның Казанда басылып чыккан «Ихлас дога» исемле китабын тапшыргач.

— Гөрчә аралашу бик кыска булса да, минем фикеремчә, аларның милли, рухи яктан сәламәт

Тычкан таяк белән йөргән чак.

Тычкан капчыкны астан тишсә, иген уңар

булуы күзгә бәрелеп торды. Аларда милли горурлык хисе гариплəнмəгəн. Моңа, ихтимал, австралияле кардәшләрнең гаилә тәрбиясенә нык игътибар итүе дә ярдәм итәдер. Шулай ук Австралиядә хөкем сөргән тәртипләрнең чын демократик рухы да сәбәптер. Анда, мәсәлән, һәр кавем, һәр милләт үзе теләгәнчә яши,үзе теләгән иманны тота. Хакимият тарафыннан аларның тормышына тыкшыну юк. Миңа, мәсәлән, очраклы рәвештә, дигәндәй, урыс баптистлары белән дә очрашырга туры килде, һәм алар да монда сөргән тәртипләрдән бик канәгать. Ә элекке Русиядә дә, СССРда да, Кытайда да баптистлар эзәрлекләнгән кавем иде.

Татар диаспорасына килсәк, анда аларның балалары нигездә инглиз мәктәбендә белем алсалар да, өйдә ана телендә сөйләшәләр, һәм аларның дәвамлы рәвештә эшләп килә торган якшәмбе мәктәпләре бар. Мәктәптә аларны туган телгә, әдәби телгә, милли сәнгать нигезләренә һәм дин нигезләренә өйрәтәләр. Шуңа күрә диаспора белән очрашу вакытында да без татарча нормаль сөйләшүне, аларның үзебезчә җырлауларын, биюләрен күрдек.

— Бер әңгәмәгездә Сез, чит илләрдә һәм өлкәләрдә яшәүче татар диаспоралары хакында китаплар чыгарырга ниятлибез, мәсәлән, Австралиядә яшәүче һәвәскәр шагыйрә Ләйлә Садриның шигырьләрен һәм мөнәҗәтләрен аерым китап итеп бастырырга уйлыйбыз, дигән идегез. Ул китапның язмышы ничек булып бетте?

— Әйе, ул китап Казанда «Ихлас дога» дигән исем белән басылып чыкты, һәм рәсми делегация җитәкчесе — Премьер-министр Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның вәкиллеген ачкан көнне Ләйлә апа Садрига ул китапны тапшырды. Китапның тарихы болай: җәен, Австралиядә булган чакта, безнең Президент аппаратының җитәкчесе Хәләф әфәнде Низамов Ләйлә апаның әдәби иҗаты белән таныша һәм, кайберләрен бастырып булмасмы, дигән ният белән Казанга бер кочак кулъязма алып кайта. Шигырьләр арасында тарихи күзлектән, документальлек ягыннан әһәмиятлеләрен аерып алып, «Җыен» фонды аларны үз исәбенә бастырып чыгарды. Шул китапны Австралиядә рәсми делегация тарафыннан авторга тапшыру да нур өстенә нур өстәде.

— Бу сәфәр шәхсән үзегез өчен нәрсә бирде?

— Шушы сәфәр нәтиҗәсендә кырык ел элек аерылышкан дусларымны очраттым. Истәлек хисләре шактый яңарды. Без бик нык картайганбыз икән инде. Чибәр кызларның олы ханымнар булуын, яшь, үсмер егетләрнең чал сакаллы ирләр булуын күрдем. Димәк, үзем хакында да нәтиҗә чыгарырга туры килде. Күңелсез нәтиҗә, әлбәттә... (Көлә).

Мин, гадәттә чит илләрдән диаспоралар хакында төрле тарихи мәгълүматларны, документларны мулрак җыеп кайта идем. Бу юлы исә күп вакыт рәсми очрашуларга китте. Шулай да киләчәктә элемтәләр дәвам итәр дигән өметтә калам. Чөнки дәвамлы хезмәттәшлеккә, мөнәсәбәтләргә нигез салынды.

— Сез кайтканда самолетта шактый ук күңелсез хәл булган дип яздылар...

— Кызганычка, гәзитләрдә безнең самолетның, ярты юлдан кире борылып, Дәһлигә барып утыруын бик күпертеп яздылар. Чынлыкта хәл ул кадәр үк куркыныч түгел иде. Самолет күтәрелеп бер-ике сәгать очкач, аппаратлар тормоз системасының төзек булмавын күрсәтә. Пилот-командир Дэвид, урысча бик әйбәт белә торган америкалы грузин, хәлне безгә бик әйбәтләп аңлатты. План буенча без Алма-Атага төшеп, ягулык



Делегациянең татар диаспорасы белән шәһәр паркында очрашуы; кунаклар өчен шашлык пешерелә.

алырга тиеш булганбыз. Ләкин анда аэродром юлы 2,5 чакрым гына икән, ә тормоз эшләмәгәч, самолет үз көенә төшеп утырсын өчен аэродром юлының озынрак булуы шарт икән. Шуңа күрә безгә Нью-Дәһлигә барып төшәргә туры килде. Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге хәбәрне ишеткәч, бернинди шау-шу, паника булмады, беркадәр сагаеп калу гына сизелде. Берәүләр йоклады, икенчеләре кәрт уйнады. Мондый вакыйгаларны үз башымнан берничә кат кичергән кеше буларак (мәсәлән, 1974 елда, Сәмәркандка барып утырган чакта, тормозы эшләмәү аркасында самолетның тәгәрмәче дөрләп янган иде), мин безнең делегациянең сабырлыгына, түземлелегенә сокландым. Шуның хакында хәтта аларга Нью-Дәһлидә әйтергә дә кирәк таптым. Дәһлидә безне бик яхшы каршы алдылар, урнаштырдылар. Нәтиҗәдә шәһәрнең бер читен күрергә һәм, кем әйтмешли, урамнарда сәйран итеп йөргән һинд сыерлары белән дә танышырга туры килде.

Әңгәмәне
Саимә ИБРАҺИМОВА
үткәрде.
Наил КУРАМШИН
фотолары.

Йолдызларга карап зекер ит...

Яңа елны ничек каршыларга? Ул кичтә нинди кием кияргә һәм нинди кунаклар сайларга? Яңа ел алдыннан күпләребезне шул сораулар борчый.

Халыкара астрология һәм оккультизм җәмгыяте әгъзасы Сергей Буланцев Яңа ел алдыннан мондый киңәшләр бирә:

КӘҖӘМӨГЕЗ (21 декабрь — 19 гыйнвар). Узып баручы елның соңгы көннәрендә алдан уйланмаган тәвәккәллеккә бармагыз. Бурычка акча алмагыз. Мәхәббәт көймәгезгә су үтмәсен. Яңа ел кичендә янәшәгездә Үгезбозау йолдызлыгында туган кеше булсын. Кучкар белән мәхәббәт уенының йөрәгегезгә яра салуы бар. Киемегез куе яшел һәм кара төсләрдән торырга тиеш. Бәйрәм өстәленә кәбестә һәм дөге ярмасыннан пешерелгән ризыклар куярга тырышыгыз.

СУКОЯР (20 гыйнвар — 18 февраль). Иске елны әйбәт сәламәтлек, яхшы кәеф белән озатыгыз. 1996 ел сезнең өчен нигездә уңышлы булыр. Йолдызлар белән фал ачучы сезгә исерткеч эчемлекләрдән тыелырга, Яңа ел кичендә яшел һәм кызыл тукымадан тегелгән киемдә йөрергә киңәш итә. Бәйрәм өстәлендә әфлисун һәм диңгез ризыгы булу шарт.

БАЛЫК (19 февраль — 20 март). Бу йолдызлыкта туган кешеләр 1995 елны киләчәк өчен зур ышаныч белән озаталар. Декабрь ахырында ниятләнгән эшегез уңышлы булачак. Яңа ел алдыннан сезне берничә мәҗлес табыны көтә. Мәхәббәт кыйссагыз Балык йолдызлыгы астында туган кеше белән бәхетле тәгәлләнер. Киемдә яшел һәм зәңгәр төсләр шарт. Ризыгыгыз — сарык ите һәм суган.

КУЧКАР (21 март — 20 апрель). Яңа ел алдыннан, бигрәк тә төүлекнең караңгы сәгатьләрендә, руль артына утырмагыз. Шуннан башка сезгә бернинди куркыныч та янамый. Әгәр йөрәгегезгә мәхәббәт уты салган кешенең фамилиясе К, Р һәм Н хәрефләренә башланса, мәхәббәт тарихыгыз уңышлы тәгәлләнер. Бәйрәм табынына ак яки кызыл киемдә утырыгыз. Өстәлегездә ак ром һәм яшел төмләткечләр булу шарт.

ҮГЕЗБОЗАУ (21 апрель — 20 май). 1995 ел белән сез бик тыныч саубуллашырсыз. Яңа эшлекле тәкъдимнәр өчен акча кызганмагыз. Аеруча кызыктыргыч тәкъдим керсә, бөтен башка эшләрегезне куеп торыгыз — 1996 елның башы сезгә зур уңыш вәгъдә итә. «Үтә җете» мәхәббәт күңел бизүенә китерер. Яңа елны алсу, ак яки кызыл киемдә каршылагыз. Кабымлыклардан өстәлегездә чөгендер салаты һәм кыяр булса әйбәт.

ИГЕЗӘКЛӘР (21 май — 20 июнь). Яңа ел алдыннан эшләрегез уң булыр, әмма күңел бушлыгы сизәрсез. Соңгысы сезне исерткеч эчемлек белән дуслаштырмасын иде. Хәмер эчүдән тыелыгыз, бераздан хәлләр уңайга үзгәрер. Яңа ел кичендә сары яки кирпеч төсендәге кием уңыш китерер. Ир кешегә ак яки зәңгәр костюмда булу шарт. Бәйрәм өстәлендә аракы, җимеш сулары һәм йомырка кушып ясалган салат торсын.

КЫСЛА (21 июнь — 20 июль). Тормышыгызда әйбәт үзгәрешләр көтелә. Биеклеккә ирешерсез. Әмма биектән егылу — һәрвакыт авыр, шунысын да онытмагыз. Бәйрәм кичендә яшел кием кисәгез, табындашларыгызның игътибар үзәгендә булырсыз. Әмма бу кичтә Сукояр белән якын мөнәсәбәткә керә күрмәгез. Ирләргә кызыл галстуктан булу шарт. Өстәлдә балык һәм гөмбәле ашлар торсын.

АРЫСЛАН (21 июль — 21 август). Яңа ел алдыннан бәхәскә кермәгез, тавыш куптармагыз. чөнки дошманнарыгыз көчле. Артык шау-шулы, зур мәҗлесләрдә булмаска тырышыгыз. Туганнарыгыз белән ешрак йөрешегез. Гыйнвар аенда сезне мәхәббәт көтә. Яңа ел табынында кара икмәк һәм ит булу шарт. Киемегез кара яки кызыл тукымадан булсын.

КЫЗ (22 август — 23 сентябрь). Күк җисемнәре сезнең өчен уңай урнашкан, эшләрегез уң булыр. Тәвәккәллек уңыш китерер. Өйләнешү — бәхетле һәм гомерлек булыр. Яңа елны шат күңел белән каршылагыз. Кызыл яки зәңгәр киемдә булу шарт. Бәйрәм өстәлендә ит һәм сыр булу сорала.

ҮЛЧӘҮ (24 сентябрь — 23 октябрь). Уңышларыгыз уңышсызлыктан күбрәк булыр. 28 декабрь тирәсендә зур акча керер. Хезмәтегездә дәрәҗә килер. Яңа фикерләрегез киләчәк уңышларыгызга нигез булыр. Иске мәхәббәтне кысрыклап, яңа елдан соң яңа мәхәббәт килер. Бәйрәмне яшел яки зәңгәр кием киеп, миндаль чикләвеге ашап каршылагыз.

ЧАЯН (24 октябрь — 22 ноябрь). Сез, җитди эшләрне ташлап, күңел ачу диңгезенә чумарсыз. Йөрәк тойгылары тормышыгызның үзәк мәсьәләсенә әйләнүе бар. Чаян йолдызлыгында туган хатын-кыз, ниһаять, үзе теләгән, хыялдагы мәхәббәтен очратыр. Бәлки бу вакыйга җомга көнгә туры килер. Бәйрәм табынына кара яки ак төстәге киемдә утырыгыз. Табынга тавык итеннән әзерләнгән ашамлыклар куегыз.

УКЧЫ (23 ноябрь — 20 декабрь). Бу атнада эшлекле тәкъдимнәрдән баш тартыгыз: нәтиҗәсез эшкә таруыгыз бар. 27-28 декабрьдә эшлекле көгазьләргә кул куюдан тыелып торыгыз. Мәчеткә барыгыз. Яңа мәхәббәт сезне тетрәндерер. Интуициягезгә ышаныгыз, ул сезне алдамас. Киемегез ак, сары, кызыл төстә булсын. Өстәлдә бөреңге торсын.

Тычканга үлем, мәчегә көлкә.

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН

Миңа, дуңгыз малай, димәгез

Сугыш башланганчы, сигез яшькә кадәр, минем малай чагым Стәрлебаш дигән чын татар авылында узды. Өч мәхәлләле, мәдрәсәсендә ике гасырдан артык мәшһүр Тукаевлар мөдәррислек иткән авыл булган ул. Шәкертләр саны 800-1000 кешегә җиткән. Мәчет-мәдрәсәләрнең үз урманнары, үз иген кырлары булган. Авыл тормышы мөселман кануннары буенча гына алып барылган. Революциягә кадәр безнең авылда бер генә урыс та яшәмәгән. Килмәгәннәр түгел, килгәннәр. Аз-маз яшәп тә караганнар. Тик булдыра алмаганнар. Чөнки авылда аракы саттырмаганнар, чучка асратмаганнар. Аракысы белән чучкасы булмагач, урыс урыс була алмый бит инде. Ничек килсәләр, шулай кире китеп тә барганнар. Өстәвенә, алар татар авылы өчен су кебек, һава кебек кирәк булган татар телен өйрәнә алмаганнар. Ни өчен урыс татар телен өйрәнергә теләми? Беренчедән, ул килә-килешкә башка телләрнең хаҗәтен бетерә; икенчедән, аңа «бөек халык» булу да бик комачаулый.

Урыс яшәмәгәч, авылда чучка да булмаган. Чучка дигән нәрсәнең барлыгын мин беренче булып әнидән ишеттем. Кар сулары ага башлагач, язгы урамда «буа ерышлы», җәен чебенле, унике чыбыклы, шаралы уйныйбыз. Шул уеннардан пычракка батып кайтам. Язын кигән чабата-оекларны әни ишек төбеннән уздырмый. Әрли-әрли нотык укый:

— Бу хәтле чучка булырсың икән! Ничекләр генә итеп бүрегең коры кала алган әле! Пычранмаган җирең юк бит! Әллә син ул сазның эченә кереп яттыңмы?

Мин дәшмим. Шулай эшләргә мине әти өйрәтте. Чөнки каршы дәшсәң, яисә сүз көрәштерә башласаң — беттең! Озак иттереп, төмләп әрли белә минем әнием. Бәләкәй генә булсам да, мин әтинең әнидән «акыллырак» икәнен яхшы беләм. Әни бик кызып китсә, әти «киңәш бирә».

— Эндәшмәгәнең хәерлерәк, улым! Шулай итсәң, тиз сүрелә әнием. Ыспурлашма!

Әни мине «чучка» дип әрләгәч, сорыйм тегеңәрдән:

— Нинди була соң ул синең чучка дигәнең? Аяклары бармы аның? Ничәү? Мине гел генә, чучка кебек пычранып кайтасың, дисең! Шул хәтле пычракмыни ул?

Әни, эшен ташлап, миңа аптырап карап торды да, җавап сүзе таба алмады, ахрысы, көлеп җибәрде:

— Тач син инде менә! Охшасаң да охшарсың икән! Бар, әнә, көзгедән кара. Күрерсең сораганыңны!

Барам, карыйм. Көзге эченнән ялтыратып кырылган зур башлы, бите-борыны кара-көрән сипкел белән капланган, күлмәге астыннан түгәрәк корсагы беленеп торган нечкә, озын муенлы, кечкенә гәүдәле, коңгырт күзле бер малай миңа зур кызыксыну белән карап тора. Әни өсти:

— Чучканың аягы дүртәү, кәкре койрыгы бар. Тәне синең кырган башың кебек йонсыз. Ялтырап тора. Үзе «хорк-хорк» иттереп бертуктаусыз мыркылдап йөри. Кайда пычрак күрсә, синең кебек шунда керә дә ята.

— Йоны булмагач, кыш көне ничек өшеп үлми соң ул?

— Симез бит ул. Мае өшетми ди аны. Урыс авылына баргач, күрерсең әле.

Тик миндә чучка күрү теләге юк. Урыс авылына да барасым килми. Чөнки мин ямаулы киндер капчык күтәргән урыс хәерчеләреннән шүрләп яшим. Безнең авылда ул хәерчеләрне «христара» диләр.

Минем әти — янгын сүндерүчеләр нәчәлниге. Авылда ут чыкса, бергә килү торган бабайлар белән атларны пешкәкле насослар куйган бричкаларга парлатып җигә дә, янгын сүндерергә чыгып чаба.

Бер язны (1938 ел язы дип уйлыйм), әти мине җигүле арбага утыртты да каядыр алып китте. Ат Чегән кушаматлы. Ул атны, пашпорты булмаганга күрә, милициялар авыл яныннан узган чегәннәрдән алып калганнар. Исеме дә шуңардан алынган — Чегән. Кырыккан яллы, бик көчле көрән ат иде. Маңгаенда агы да бар иде аның.

Чегән тыркылдап кына юырта. Әти миңа күзе нәрсә күрә, шул турыда сөйләп бара. Авылның тарихын, тирә-як табигатьне бик нык белә торган иде мәрхүм.

— Әнә-ә, улым, уң якта, яр астында Имәнле елгасы ага...

— Ы-ы!

— Ярның теге ягында яшелләнеп урман күренә. Күрәсеңме?

— Күрәм. Өстендә тилгән дә очып йөри.

— Әйе шул. Күзләрең очлы икән.

Әти азрак дәшмичә бара. Ул һавада канатларын җәеп, боҗра ясап очып йөргән тилгәннәрне күзәтә.

— Азык эзли инде алар да. Балаларын ашатырга, дип. Яшәргә кирәк бит кошларга да...

Аннары тагын дәвам итә:

— Менә шул урманның исеме Мәчет урманы инде. Исеңдә калдыр, улым: Мәчет урманы.

— Әти, ә нигә Мәчет урманы? Мәчетләр юк бит!

— Әле мин дә булмаган чакта безнең авыл мәчетенең имамы, чукынудан качып, Казан ягыннан килгән Тукай дигән мулла булган. Шул мулла, шушы урманны башкортлардан сатып алып, мәчеткә биргән. Бөтенләйгә, акча да алмыйча. Мәчет-мәдрәсәләрнең мичләренә ягарга утын кискәннәр шәкертләр шул урманда. Дәресләр, намазлар укыйлар иде җылыда. Авыл халкы үз кирәгенә агач кисми иде ул урманда. Гөнаһысы зур, мәчет-мәдрәсәләр өчен генә иде ул урман...

Әтинең сөйләвендә нәрсәнедер сагыну сизелә. Мин әтине бик яратам. Ул мине ярата. Шунлыктан без озак-озак атка утырып йөрибез. Бүген кая китеп барганыбызны әйтә:

— Без, улым, Барановка дигән авылга барабыз. Аларның пожарныйларын карап кайтырга.

— Нәстәсен карыйбыз аның?

— Пожардагы атларын, арбаларын. Су тутырып куя торган мичкәләрен. Багур-балталарын.

Мин әти белән Йомагуҗа дигән башкорт авылына «Пожарный» тикшерергә барган малай инде. Анда мине мичтән чыккан чуен чүлмәк кебек кара малайлар үртәгәннәр иде. Алар башкорт малайлары булып чыкты. Арбаны уратып алып, урамдагы яшел чирәмдә сикерә-сикерә такмаклыйлар:

— Татар, татар,
Мичкә төбен ватар.

Бу юлы без, килгән авыл нәрсәсе беләндер миңа ошамады. Башкорт авылының читәне, киртәсе яртылаш булса да, кешеләре ямьле, күңелле иделәр. Сары күлмәк, буйлы ыштан кигән бер башкорт бабай коткарды мине.

— Ярамай, оландар, ярамай! Минем дустым Лотфулла малае ләбаһа бу малай кисәге! Үзебезнең татарлаһа ул! Үсеклəшкәнсе, касышлы уйнагызсы!

Күп тә үтми, мин кара башкорт малайлары белән кем узардан йөгерешеп, качышлы уйный башладым. Ә башкортча сөйләшергә өйрәнеп тә торасы юк икән! Башкорт малайлары да нәкъ безнеңчә сөйләшәләр икән дә, тик кайбер сүзләрдә «с» урынына ни өчендер «һ» дип әйтәләр. Өйрәнеп бетмәгәннәр, ахрысы, сөйләргә.

Ә бу Барановка дигән авылның өйләре ни өчендер кап-кара. Нигезләре түбән, тәрәзәләре җиргә якын иттереп тишелгән. Урамнары тулы өрекмән үсеп утыра. Шулар арасыннан узган елгы тигәнәк, өрем сабаклары сузаеп тора. Бакчаларында үсеп утырган бер агач күренми. Капка төпләрендә көнбагыш ярып утырган кешеләр күп. Килешсез иттереп киенгән, сакал-мыеклары ямьсез булып үскән бабайлар, карадан киенгән, капчык кебек салынып торган күлмәкле әбиләр. Урам буйлап сары, җиткән чәчле малайлар йөгерешә. Нәрсәдер кычкыралар, тик телләре таныш түгел. Үзләре ничек аңлыйлардыр инде?! Урамның теге ягындагы бер капка төбендә зур гәүдәле абзый эт кебек дүртаякланган да, турая алмыйча үкерә. Басарга итеп, гәүдәсен турайта башласа, арт ягына егыла да китә. Тагын дүртаяклана, тагын тәгәри...

— Исерек урыс ул! — ди әти, минем теге абзыйга аптырап карап утырганны күреп. — Карама син аңарга, улым.

Минем әти бөтен нәрсәне белә.

— Әти, нигә өйләре ямьсез? Нигә малайларның чәчләре сары? Нигә чәчләре озын? — дим.

Әти җавап бирә. Тик мин аның әйткәнен ул чакта әле аңламыйм. Ә җавабы дөрес булган икән.

— Урыслар бит алар, улым. Шунлыктан шулайлар.

Урамнарында байтак җирләрдә пычрак сулар җыелып ята. Әти атны зур гына бер йорт янына туктата. Арбадан төшә дә дилбегәне читән казыгына бәйли.

— Син арбадан төшми генә тор. Төшсәң, адашырсың. Мин хәзер чыгам.

Урыслар урамында, арба өстендә булса да, минем ялгыз каласым килми. Еларга да ярамый. Әти барда кеше елап тормый бит инде! Әни барда гына еларга ярый! Түзәргә кирәк!

Чыбыркысын палас астына тыга да әти урысларның өенә кереп китә. Тирә-якны караштыргалап, арбада тик кенә утырам. Теге исерек абый да, үкерүеннән туктап, йоклап китә. Тик утырганнан мине дә йокы баса башлый. Әмма урыс авылы булганга күрә, эчке бер шүрләүгә буйсынып, йокламыйм.

Кинәт кенә Чегән пошкырып җибәрде. Нәрсәдәндер курыкты, ахры. Үзе алгы аягы белән җиргә тибә-тибә аны тырнагандай итә. Үзе муенын борып, якындагы җыелып яткан суга карый. Мин дә, арбадан калкына төшеп, Чегән караган якка караган идем, куркуымнан каттым да калдым. Бездән берничә адым гына читтә, урам уртасында җыелган пычрак судан зур, тулы бер капчык кебек нәстә чыгып килә. Пычракка буялган, кап-кара. Үзе хорк-хорк кебегрәк тавыш чыгара. Корсагы зур, түм-түгәрәк. Башы киселгән юан бүрәнә бүкәне кебек. Өстәвенә, алга очланып килгән. Ике колагы ике яктан салынып төшкән. Күзләре кып-кызыл, зурлыгы бер тиен акча хәтлек кенә. Өстеннән шыбыр-шыбыр пычрак су ага. Корсагы салынып төшкән, атлаган саен ике якка селкенеп, чайкалып бара. Муены бөтенләй юк. Колакларыннан соң бөкре аркасы башлана. Иң артта түгәрәкләнеп кәкрәйгән койрыгы бар. Койрык төбе минем беләктән дә юан, ә очы неп-нечкә үзенең. Аяклары дүртәү. Үзләре кып-кыска. Ә бот төпләре юан. Аяк беткән җирдә кечкенә тояклары да бар. Судан чыкканда чап-чоп килеп торалар. Кычкырырга итеп карыйм. Тавыш чыкмый гына бит. Ул нәрсәнең әкиятләрдә сөйләнә торган җен-пәри икәненә минем бер шигем дә калмады. Җен-пәри судан кабаланмый гына чыкты да, суга таба борылып, тагын да ныграк итеп мыркылдый башлады. Үзе китмичә тора. Мыркылдавын ишетеп, су эченнән миңа кечкенә түмгәкләр булып тоелган кечкенә балалары йөгерешеп чыга башлады. Үзләре песидән дә бәләкәйләр. Чопыр-чопыр килеп суда йөгерешәләр. Әниләре янына җыйналалар. Мин әле ул чакта унга хәтле генә саный белә идем. «Җен-пәри балалары»ның саны ун булды. Әниләре хорк-хорк килеп китеп барды. Аңарга балалары иярде.

Әти теге йорттан килеп чыкты. Аңа көн эссе булуга карамастан, өстенә ямаулы тун, башына бер колагы өзелеп төшәргә торган йөнтәс бүрек кигән абзый ияргән. Аның битен бакыр кебек җирән сакал-мыек баскан. Бүреге астыннан шундый ук кызыл, озын, кисәк-кисәк булып укмашкан чәчләре чыгып тора. Әти аны шелтәләп нәрсәдер сөйли. Ә теге абзый:

— Виноват, виноват! — дип тик тора.

Әти аңарга кулын селти дә дилбегәне чишә башлый. Ә теге һаман:

— Виноват, виноват! — ди. Арба янында таптана. Үзеннән әллә нинди ят ис килә. Әти арбага утыра да без кузгалып китәбез. Мин куанычымнан әтинең чыбыркы тоткан зур кулына ике куллап ябышам. Ул, гаҗәпләнеп, иелеп, минем йөземә карый да сорый:

— Син әллә курыккансың инде, улым? Мин барында курыкма бер нәрсәдән дә.

Бездән ике йорт алда гына, балаларын ияртеп, бер ишегалдына кереп барган теге хайванга бармак белән төртеп күрсәтеп, сорыйм:

— Әти, нәрсә ул? Җеннәр анасымы?

Әтием мин күрсәткән якка карый да көлеп җибәрә:

— Нишләп җен булсын ди инде. Җеннәр дә моңардан матурraktыр әле. Әнием әйткән чучка шушы була инде, улым. Ана чучка ул, балалары белән. Шул инде урыс чучкасы. Күрдеңме, нинди пычрак?

— Әти! Ә нәрсәгә кирәк урысларга чучка?

— Урыслар итен ашыйлар аның. Урыс ашы ул чучка.

— Ә без нигә ашамыйбыз?

Әти чыбыркысын алдына куя да зур, йомшак кулы белән минем аркамнан сыя:

— Мөхәммәт пәйгамбәр мөселманнарга чучка ите хәрам дигән. Коръән безгә ашамаска куша чучка итен. Бик әшәке нәстә ул. Ә без — мөселманнарбыз. Әнә, урысларның авыллары нинди шыксыз. Үзләре иртән үк исерекләр.

Әти, дилбегәсен селкеткәләп, Чегәнне юыртуга күчерә.

— Әйдә, улым, ераграк булса да, Ибрай авылына барып кайтыйк әле. Анда минем әтинең сеңлесенең улы Шәрифулла абзыкаең яши. Байтактан бирле күрешкән юк. Хәл-әхвәлләрен белешеп кайтыйк. Укы бисмиллаңны!



— Бәрәч, монда сукыр бер тиен дә калмаган ич!..
Айдар ҮТӘГӘНОВ рәсеме.

Роберт ӘХМӘТҖАН

Тор, күтәрел, шигырем!



Кулга каләм алмас та идем лә, —
Нигә тиккә күзем талдырыйм?
Заманыма бар бер үпкә сүзем,
Ничек аны язмый калдырыйм?..

Ак кәгазьдә көйрәделәр сүзләр,
Бар сүземнән бусы — иң кайнар
Бу үпкәне бездән шәбрәк итеп
Әйтер иде мәшһүр Тукайлар.

Әйтер иде бәгырьләрен көйдереп
Кимсетелгән шәхес хакында;
Сорыкорттай җанга үрмәләгән
Данга туймас нәфес хакында;

Әйтер иде изге минутларны
Артка тарткан сәгать турында;
Үз халкының үги баласыдай
Тибәрелгән сәнгать турында.

Син үзең дә моңа гаеплесең,
Булган, халкым, шундый хаталар:
«Атказанган» аты белән генә
Китеп барган
Зифа апалар...
Бакчы, бүген бар да «халык»ныкы —
Эстрада кайный,
мыж килә!
Күпсенмәгез, яшьли тиешле ул —
Күпләренә, хәер,
буш килә.
Әйтте берәү: әнә, яшь «йолдыз»лар
Җырлап машиналар алганда,
Сиңа, шагыйрь,
шул дүрт тәгәрмәчтән
Бер тәгәрмәч кенә калган ла!

Зур залларда
шаулап кул чаптырган
Ул җырны бит син дә язышкан.
Ил тарихын хәтта язышкан син,
Каләмнәрең булган камыштан.

Әйтә Шагыйрь: Моңа нинди үпкә,
Андый борыкканнар азмы соң?!
Ходай хакына бер
кабат кайтып,
Карагыз сез
Сөйдәш язмышын!

«Академик» кавем үрчегәндә
(Күпләр инкубатор затыннан!)
Тау-тау әнҗе өел,
Нәкый абый
Китеп барды
Ишек катыннан...

«Академик» исеме бөек, әмма
Һәркем үзен күрә бит инде!
Ә Исәнбәт аңа «үсәлмады»,
Бу да үзенә күрә бит инде!..

Түрдә утырганда мөтешагыйрь
(Ул бай, имеш!)
Онытып оятын да,
Ник торасың, Шагыйрь, бусагада,
Ник торасың
Ишек катында?!.

Тор, күтәрел, шигырем, саф башына,
Таян безгә,
Таян халкыңа.
Тор, күтәрел, якла үз-үзеңне
Яктылык вә игелек хакына!

Тор, күтәрел, шигырем,
шундый чор бу —
Изгеләрне изгән вәхшилек...
Бер тиенгә уптым сата сине
Базар фахишәре
Мөш килеп!

Урын өчен илдә ызгыш бара,
Хак сүзләрдән бүген ялган күп.
Неврастеникларга көн юк бүген, —
Тиред булсын калын —
калкан күк!

Тор, күтәрел, шигырем,
җәй канатың,
Җан канатып булсын —
алга бар!
Өмет белән баккан Киләчәккә
Ол Галиләр рухын ялга, бар!

Бирешмә син җыен алыпсатар,
Җанын сатар татар явына;
Йөрәгеңне кабыз чыраг итеп,
Күтәрел син
Олимп тавына!

Син, шигърият, нинди горур идең,
Базарга син «йомшак» кермәдең.
Хөрриялләр ишек төпләрендә
Ипи-чөйлек сорап йөрмәдең.
Нәшриятлар диварында һәрчак
Балкый иде синең үрнәгең!

Яу кырында һәрчак алда булдың,
Үлем көткән чакта
Җәлилчеләр сине җырлады.
Автоматы түтәсенә куеп
Фатих Кәрим шигырь сырлады.
Байрак булды Шагыйрь җырлары!

Поэзия, син ваемсыз, бүген,
Син дистоник бүген, астматик!

И, Шигърият,
Исемең һаман шул да,
Җисемең генә бүген башка тик.

Вак җаннардан өркеп, син, шигырем,
Безне ташлап китмәк шикелле.
Китмә, Иҗат, зинһар, бу тормышта
Син бит безгә
Икмәк шикелле!

Өметсезгә — өмет, күңелләргә
Ачылмаган хикмәт шикелле!
Хыял пыяладай ватылмый да,
Күпә-көндез
йолдыз
атылмый.

Базарлардан кача чын Шигърият,
«Комок»ларда намус сатылмый.
Түрдә утырганда
базар корты
(Ул бай, имеш!)
Онытып оятын да,
Ник торасың, Иҗат, бусагада,
Урыныңмы ишек катында?

Күтәр безне рухи инкыйлабка,
Гүзәллек һәм Хаклык хакына!

9 декабрь, 1995 ел.

5 ЕРЕНЧЕ ГЫЙНВАРДА ТУГАННАР

ЮЛЫГЫЗНЫ КАРА МӘЧЕ КИСМӘСЕН

Бабаларыбызның елле кайчан әйткән сүзләре, аларның тамгалары бүгенге көндә дә дөрескә чыгып бара. Ягъни борынгылар безгә караганда акыллырак булган. Алар әйтеп калдырган маймыл елы маймылга, ат елы атка, дуңгыз елы дуңгызга охшаш. Тычкан елына кереп барабыз. Иншалла, ул бик яшәүчән, ничек кенә булса да, үзен-үзе туйдыра торган җәнлек. Яңа ел өметлерәк булыр дигәнгә ишарә түгелме соң бу?! Ә бу елга кергәндә 1 гыйнварда туган зыялыларыбыз ни уйлый икән?

Әнвәр ШӘРӘФИ, композитор:

— Минем тычкан буласым килми иде. Шуның өчен дә күптән түгел генә паспортымны алыштырдым. Хәзер мин дуңгыз инде. Һәм ялгыштым, ахрысы. Алар икесе дә кимерүчеләр рәтенә керә бит. Коллегаларыма киләсе елда уңышлар теләп калам. Кимерегез рәхәтләнеп! Тешләрегез сәламәт булсын!

Техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире **Әхмәт МӘЗҺӘРОВ** өчен аның хәләл җефете Әлфия ханым җавап бирде:

— Өйдә юк шул Әхмәткәем. Казакъстанга китеп барды әле. Бик акыллы, бик зиһенле, бик тәүфыйклы минем тычканым. Үзем юлбарыс булгангадыр инде. Мин бит мәчеләр семьялыгыннан. Киләсе елда аңа уңышлар теләп калам.

Ринат ТАҖЕТДИН, Камал театры артисты:

— Киләсе елда сәхнәдә заманга лаеклы яңа образлар тудыра алсам, үземне бик бәхетле санар идем. Тычкан елы Дуңгыз елына караганда начар булмасын иде. Юлыгызны кара мәче кисмәсен.

Адлер ТИМЕРГАЛИН, язучы:

— Мин Шәрекъ календарена күбрәк ышанам. Аның буенча мин — куй. Хәер, тычкан дип атасагыз да, үпкәләмәм. Алар бит икесе дә Русия дигән зур абзарда яшәүче җан ияләре. Ул абзарның ишеге кайчан ачылыр икән? Көтәбез инде, уңай үзгәрешләр буласына өметләнәбез.

Фәрит ХАТИПОВ, композитор:

— Алдагы ел тынычрак, мулрак булсын иде. Бәйсезлегебезне тагын да ныгытырга язсын. Милләтебез мәнфәгатьләрен тормышка ашыру юлында мөмкинлекләр артсын иде.

Владимир ФЕДОТОВ, физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире.

— Тычкан әллә ни сөйкемле хайван түгел инде. Аңа һәрвакыт капкын куялар, агулыйлар. Киләсе ел дөньядагы барча үтерү коралларын да юк итү елына әверелсен иде.

Әсхәт ХИСМӘТОВ, Камал театры артисты:

— Дөньялар тыныч булсын. Тычкан елы һәр йортка, һәр гаиләгә бәхет китерсен.

Мансур ВӘЛИ, тәнкыйтьче:

— Бигрәк тә безнең җитәкчеләребез халыкка гуманлылык, кешелеклелек үрнәге күрсәтсеннәр иде. Әдәбиятка мөнәсәбәт тә әнә шуңа керә. Әдәбият-сәнгать вәкилләре санга сугылмаган республикада юньле кешеләр үстереп булмаячак. Анда төрле кыяфәттәге, төрле дәрәҗәдәге җинаятьчеләр торган саен һаман күбәя генә барачак.

Безнең Татарстанда кешелекле кешеләр тәрбияләү мәсьәләсе көн тәртибеннән төшмәсен иде!

Шамил МАННАП, шагыйрь:

— Адәм баласына Ходай алдагы көн өчен өмет-ышанычны да, сабырлыкны да мул итеп биргән. Аны әнә шул өч таяныч яшәтә. Нык булыгыз!

Әхәт ГАФФАР, язучы:

— Яңа елны мин ниятем, өметем, хыялым гавамында каршылыйм. Гавамның дәвасында. Гавамның дәвасы бар аның.

* * *

ЛАСТОВКА Галина Трофимовна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты, Татарстанның халык артисты.

ГАТОВА Ирна Хафиз кызы — Татарстан Театр әһелләре берлегенең җаваплы сәркатибе, Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе.

БАКИРОВ Шамил Шаһиәвли улы — КТУ профессоры, физика-математика фәннәре докторы, Татарстан фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире.

ГЫЙЛЬМАНОВ Галимҗан Хәмитҗан улы — язучы, Татарстан китап нәшриятының бүлек мөдире.

КОРБАНОВ Рафис Харис улы — шагыйрь, «Мәгариф» нәшриятының бүлек мөхәррире.

НИЗАМОВА Рушания Минабетдин кызы — язучы.

Айдар ХӘЛИМ (Хәлимов Борис Нәҗметдин улы) — шагыйрь, публицист, милләтпәрвәр.

ӘКӘМӘТ

Нуриевның алтын башмагы

Нуриевның киелгән балет башмагын Лондондагы «Кристи» аукционында сатып җибәргәннәр. Баштагы бәясе 500 фунт итеп куелган булса да, аны бик кыйммәт хакка — 12075 фунт стерлингка сатканнар. Бу «истәлек»не алырга бик тырышып йөргән бер ханым, үзенә эләкмәгәч, хәтта җылап та җибәргән. Бер караганда, бу гаҗәп тә түгел: ул башмакны киеп XX гасырның бөекләрдән-бөек биючесе Рудольф Нуриев чыккан бит сәхнәгә!

Аукционны оештыручылар, Нуриевның Париждагы фатирындагы әйберләрен сатып, ике көн эчендә 2 миллион фунт стерлинг чамасы акча эшләгәннәр. Аукцион бик уңышлы булып чыккан — тәкъдим ителгән 649 әйбердән 20се генә сатылмый калган. Ә менә Нуриевның «Йокыга талган гүзәл» һәм «Шәһрезадә» спектакльләрендә киеп биегән костюмнарын ни өчендер бик сораучы булмаган.

Нуриев үзенең хәтта тузып беткән балет башмакларыннан да аерылмый торган булган һәм аларны еш кына Лондондагы «Гамба» фирмасыннан сатып алган. Бу фирма заманында Лондонда яшәгән Анна Павловага ярдәм итеп торган.

Бөекбританиядә Нуриевны бигрәк тә мәшһүр инглиз биючесе Марго Фонтейн белән бергә 60-70 нче елларда «Ковент-Гарден»да биюе аша беләләр.

«Культура».

Яңа ел кайчан килә?

Без инде тәмам ияләшкәнбез — Яңа ел безгә яшел чыршылары, кар шыгырдавы, тәрәзәләрдә җемелдәгән төрледән-төрле утлары белән килә кебек. Әйтерсең, бөтен дөнья бу көнне яңа туасы ел, Яңа ел белән бәйле. Чынлыкта исә — киресенчә: декабрьнең соңгы көннәре әле һәркем өчен дә иске елны озату түгел. Хәер, ата-бабаларыбызның яңа елны Нәүрүз бәйрәме буларак каршылаганнарын без инде беләбез... Әйдәгез, башка кайбер халыклар гадәтенә дә күз салыйк.

Урман учаклары

Урман аланында зур учак яна. Коры агач ботаклары, очкыннар чәчеп, шартлап-шатырдап кабыналар Әмма учак тирәсендә биегән кешеләрне ялкыннан бөркелгән эссе дә куркытмый: алар учакка якынрак булырга тырыша кебек.

Ап-ак киемнәр кигән, йөзләрен-битләрен акка буяган бу кешеләр кулында — таякка беркетелгән, каурыйлардан ясалган түгәрәк шарлар Шундый шарларның берәрсе учак эссесеннән кабынып китүгә, тирә-юньдәгеләр шатлыклы-аһәңле авазлар чыгара.

Менә арадан иң көчле уналты ир кеше уртага чыга. Зур бер кәрзингә салып, алар ачык кызыл төстәге шарны учакка таба алып киләләр. Әлеге шарны бауга тагып, биек бер колга башына күтәрәләр. Шарга ут кабуга, «Яңа кояш туды! Яңа ел туды!» дигән куанычлы авазлар яңгырый.

Бәйрәм аланын яшел чыршыдан корылган койма уратып алган. Әлеге коймада бер генә аралык — көнчыгыш яктан ачык бер капка калдырылган. Әмма, кояш чыгуга, койманың көнбатыш, көньяк һәм төньяк якларында да капка ачалар: кояш та дөньяның барлык тарафларын яктырта бит. Навахо индеецлары яңа елны әнә шулай каршы ала Ә Яңа ел аларда 22 декабрьгә туры килә.

Чәчәкләр уртасында

Вьетнам шәһәрләре Яңа ел алдыннан гөлләр бакчасына әверелә. Туфраклы савытларга утыртылган җимеш агачлары урамга чыгарыла. Бер генә гаилә дә Яңа ел табынына чәчәк бәйләменнән башка утырмый.

Вьетнамлыларның Яңа елы аерым бер көнгә туры килми, ә бәлки Ай календаре буенча гыйнвар ахырында яки февраль башында — крәстияннәрнең дөге утыртуы тәмамланган бер вакытта үткәрелә.

Яңа елның беренче көнендә кунакка йөрешү һәм дә бер-береңә әфлисуннар бүләк итү гадәткә кергән. Төрле битлекләр киеп урам уртасында җырлап-биюләр, төрле уеннар. бамбуктан ясалган таганнарда атыну — болар барысы да төн уртасына кадәр дәвам итә.

Ай буена бәйрәм

Японнарның Яңа елы гыйнвар аена туры килә һәм ай буе дәвам итә Өйләрне-йортларны шау чәчәктә утырган слива, нарат, бамбук ботаклары белән бизиләр Ишек өсләренә абага белән үрелгән салам учламнарын эләләр Бу күренешләрнең һәркайсына мәгънә салынган бамбук кешеләргә озын гомер юрый, ә абага — тормышта уңыш-олгереш тудыра дип ышана японнар.

Яңа ел табынына әзерләнгән ризыкларга да мәгънә төсмере өретелгән. Һәрбер өстәлдә — дөгедән пешерелгән печеньелар һәм карп балыгы. Беренчесе муллык билгесе булып саналса, икенчесе — риваятьләр сөйләвенчә, кешегә көч-дәрман өсти. Һәм, әлбәттә, табын өчен борчак та зарури ризык — сәламәтлек символы Нәкъ төн уртасында чаң тавышлары яңгырый.

Дөге баганалары

Индонезиядә календарь елы ике йөз ун көн Шунлыктан Яңа ел бәйрәме дә төрле айларда үткәрелә һәм ун көн буена дәвам итә.

Бәйрәмгә алдан ук әзерләнә башлыйлар. Буялган дөге бөртекләрен өеп, ике атна дәвамында ике метр биеклектәге дөге баганалары ясау — мондагы бәйрәмнең мәҗбүри бер төсмере Әлеге ризык баганалары аллаларга бәйрәм күчтәнәче итеп әзерләнә Бәйрәм тәмамлангач, дөге баганаларын һәр гаилә яңадан үз өенә алып кайта. Ә аллалар исә әлеге ризыкны күреп калу белән канәгатьләнә.

КЫШ БАБАЙ, КАР КЫЗЫ ҺӘМ «МӘДӘНИ ҖОМГА»

Яңа ел алдыннан гына олпат язучы-шагыйрьләребезгә һәм, әлбәттә инде, Кыш бабайдан телеграмма килде. «Сез тычкан елын кайда каршыларга уйлыйсыз?» — дип сораган ул.

Чыннан да, ничек каршыларга уйлыйлар икән алар Кыш бабай белән Кар кызын?!

Гариф АХУНОВ, Татарстанның халык язучысы:

— Яңа елны мин өемдә, гаиләм белән каршылыйм... Бу ел да шулай булыр. Илебезгә иминлек, «Мәдәни җомга»га күп тираж, хезмәткәрләренә бәхет телим.

Марсель ГАЛИ, шагыйрь һәм язучы:

— Әйдә! Сезгә уңышлар юлдаш булсын!

Рәдиф ГАТАШ, шагыйрь:

— Мин Яңа елны ялгыз каршыларга яратам. «Мәдәни җомга» бик һәйбәт чыга, киләчәктә дә шулай дәвам итегез.

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ, Татарстанның халык язучысы:

— Төрле уйлар, моңнар белән каршы алам мин Яңа елны. Менә 68 нче Яңа елны да шулай каршылармын, ахры. «Мәдәни җомга»ның укучысы ишәйсен. Кыска гына вакытта бу гәзит үз юлын, үз йөзен тапты, шөкер.

Рәис ДАУТОВ, язучы:

— Элек Яңа ел каршыларга каядыр бара идек, хәзер өйдә утырабыз. «Мәдәни җомга» мәдәниятне күзәтеп-күрсәтеп торсын. Тиражы артсын!

Шәриф ХӘСӘЕНОВ, драматург:

— «Мәдәни җомга»гыз өстәгеләр белән ара өзмәслек мәкаләләр генә бастыра. Сан саен милли йола, әдәбиятыбыз бай булган дип язасыз. Кайда соң ул байлык? Дүрт йөз ел басылып-изелеп яткан халыкка каян килсен ул байлык? Татар белән Аурупа арасында исерек Русия ятмаса, безнең мәдәният, әлбәттә, болай имгәнгән булмас иде. Киләчәктә «Мәдәни җомга»да югары белемле шәхесләр дә йотлыгып укый алырлык шәп әсәрләр бастырыгыз. Гәзитегез бер татар белән генә чикләнмәсен, дөньякүләм мәсьәләләр күтәрсен!

Равил ШӘРӘФИ өйдә булмады, телефоннан аның улы Вил җавап бирде:

— Вил, Равил Шәрәфи Яңа елда чыршы сатып алмый, чыршы урынына кактуска уенчыклар элеп бәйрәм итә, диләр, шул дөресме?

— Хәтерләмим. Бер елны пальманы уенчыклар белән бизәп, бик күңелле Яңа ел ясаган идек. Чыннан да ул беркайчан да чыршы сатып алмый. Чыршыны аңа китереп бирәләр.

КӘҖӘМӘГЕЗ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

КОТЛЫЙБЫЗ!

29 декабрь

Туишева Зәкия Хафиз кызы — Әлмәт Татар дәүләт драма театры артисты, Татарстанның халык артисты.

© И.Хәйруллин.

30 декабрь

Йосыпов Данислав Васильевич — сынчы.

31 декабрь

Иванов Борис Евгеньевич — Казан физика-химия институтының лаборатория мөдире, химия фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең өгъза-мөхбире, Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе.

1996 ел 2 гыйнвар

Хәйруллин Илгиз Кәлимулла улы — Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары.

Таишев Марсель Мәзһәр улы — Татарстан Республикасы мәдәният министры.

Австралиядә яшәүче татарлар алдында М.Таишев халкыбызның «Карурман»ын җырлый.

Антонов Дмитрий Константинович — Татарстанның атказанган артисты.

Яппарова Роза Сәетнур кызы — Казан дәүләт курчак театры директоры.

3 гыйнвар

Вәлиуллин Разим Нәгыйм улы — шагыйрь, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе.

Гарифуллин Нариман Габдрахман улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

Хәйретдинова Рауза Котдус кызы — Татарстанның һәм Русия Федерациясенең атказанган артисты.

Хәмидуллин Филзә Гариф улы — Татарстан Республикасы Президентының икътисад мәсьәләләре буенча дәүләт киңәшчесе, икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең өгъза-мөхбире.

Юзеев Илдар Гафур улы — Татарстанның халык шагыйре.

4 гыйнвар

Вәлиев Разил Исмәгыйль улы — язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Милли китапханәсе директоры, Татарстанның халык депутаты.

Зөлфәт (Маликов Дөлфәт Госман улы) — шагыйрь.

Гыйниятова Хәдичә Гыйният кызы — Татарстанның атказанган артисты.

Хәсәнов Фәннүр Сәхыйп улы — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты.

Хәйруллина Фирдәвес Хәбибулла кызы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе

(Гыйнвар)

6-7. Санкт-Петербургта симфоник оркестр концерты.

17, 21, 28. УНИКСта симфоник оркестр концертлары (Бетховен, Шостакович, Гайдн әсәрләре)

26. К.Тинчурин театрында халык уен кораллары оркестры концерты. (С.Сәйдәшнең 95 еллыгына багышлана).

Х.Тимергалиева Лениногорски районында, «Заман» төркеме Кукмара районында, З.Сафин Казан мәктәпләрендә, Н.Мөхәммәтҗанов төркеме Әтнә районында, «Музыкаль балаган» Ульяновски өлкәсендә чыгышлар ясаячак.

Мәче юкта тычкан баш.

Тычкан башы ярылырлык.

Кыш бабай иленә сәяхәт

Балаларыбыз: «Кыш бабай кайда яши?» дип сорасалар, без, гадәттә, «Төньяк котыпта» яки «Төньяк полюста», дип җавап бирәбез. Төньяк котыпка бару да, аннан кайту да ай-һай авыр. Бөтен җир тоташ бозлык. Ул ярылса, тирән упкын. Туктаусыз буран котыра. Быел сәяхәтче Михаил Малахов кеше ышанмаслык батырлык күрсәтте. Ул, Канадада яшәүче дусты Ричард Вебер белән бергәләп, читтән бернинди ярдәм алмыйча, Төньяк полюска барып җитте һәм аннан исән-имин әйләнеп кайтты.

Кыш бабай «өен» барып күрүче бу кеше — галим, фәннәр докторы, тәвәккәл һәм көчле рухлы булуы белән аерылып тора. Рязаньда яшәүче әлеге галимгә күптән түгел Русия герое исеме бирелде. Яңа елда аңа яңа сәяхәтләр һәм уңышлар телик.

Хатын-кыздан уңмаса да...

1996 елда бихисап юбилейлар булачак. Шуларның берсе — Нобель премиясе булдырылуга 100 ел тула. Әйе, нәкъ менә 1896 елны Альфред Нобель үзенең тарихи васыятен яза, анда үз акчасына биш халыкара премия булдырырга карар итүен әйтә. Һәм ул моны Париждагы Швед-Норвегия клубында шаһитлар алдында игълан итә.

Әлеге швед промышленнигы һәм уйлап табучысы гаҗәеп бай кеше була. Хәзерге бәяләргә күчергәндә, аның байлыгы миллиардларча крон яки йөзләрчә миллион доллар белән исәпләнер иде. Мондый байлык белән ул чорларда бик сирәк кешеләр генә мактана алган.

Альфред Нобель шушы васыятьне рәсмиләштергән елны ук үлә. Аның мирасыннан үзенә өлеш алырга омтылучылар да аз булмый. Шулай да Нобельнең ярдәмчеләре аның васыятен яклап калалар. Бу очракта Нобельнең турыдан-туры нәселен дәвам иттерүче варислары булмау да зур роль уйный.

Альфред хатын-кызлардан уңмый. Ни өчен? Әллә үзен тулысынча хезмәткә һәм ачышлар ясауга багышлагангамы? Башта Нобель аптекада эшләүче яшь швед кызына гашыйк була. Тик аның көтелмәгән үлеме галимне тетрәндерә. Шуннан соң ул 20 ел буена беркемне дә ярата алмый.

Хәер, соңрак үзеннән 20 яшькә яшьрәк Софи белән ниндидер мөнәсәбәтләр була. Альфред аңа да еллык табышыннан ярты миллион швед кроны (хәзерге бәядә) васыять итә. Софи шул акчага кызын тәрбияләп үстерә.

(«Известия»).

Күселәр азына бара

1995 ел күсе елы булмаса да, Тулада күселәр шул кадәр күп үрчегән ки, хәтта һөҗүм итеп, Мария исемле бер хатын-кызны яралаганнар. Аңа тиз генә котыруга каршы укол ясалган, әлбәттә.

Әммә күсенең фатирда кешегә һөҗүм итүе беренче генә очрак түгел икән. Моннан 15 еллар элек күселәр подвалда, чүплек камераларында гына яшиләр иде. Хәзер алар, бик нык үрчегәнлектән, фатирларга да үтеп керә башлаганнар. Алдагы күсе елында алар тагын нинди генә хикмәтләр эшләмәсләр инде!

Яшел песи

Моны сез иске ел мәзәге дип кабул итә күрмәгез. Андый төстәге песи баласы Даниядәге бер фермада туа. Җирле ветеринарның әйтүенә караганда, ул һәрьяктан сау-сәламәт, бары тик төсе генә үзгә. Төсе өчен Копенгаген ветеринария академиясе хезмәткәрләре ул песи баласын үзләренә соратып алганнар.

(«Российская газета»).

Бу авылны нишләтмиләр генә!

Демократлар колхозларны таратырга дигән максат куйганнар иде. Ләкин күмәк хуҗалыкларда эшләүчеләр үзләре һич тә аларның таркалуын теләмәде. Шуннан соң аларның исемен крәстиән әйтә алмаслык сүз белән «ассоциация» дип үзгәртергә булдылар. Ниһаять, менә Яңа елга аяк басканда «Авыл хуҗалыгы корпорациясе турында» федераль закон игълан ителде («Российская газета», № 242). Монысы инде һәркемгә аңлаешлы. Хәтта колхозлар төшенчәсе дә сакланган анда. Әлеге кооперативларга Яңа елда яңа уңышлар телик. Табыннар мул булсын, игенче һәм терлекчеләргә эш хакы вакытында түләнеп барсын.

Яшел, сары, кызыл

Шәһәр урамнарында машинага тапталып күпме бала һәлак була. Республикада быелның 9 аенда гына да аларның саны 44кә җитте. Яңа елда мондый фаҗигаләрне киметү өчен мәктәпләрдә 1-5 сыйныф укучыларына юл иминлеге кагыйдәләрен өйрәтү өчен махсус дәреслек чыгарылды. Русиядә әле мондый басманың чыкканы юк иде. Китап «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» дигән курсны укытучыларга ярдәмлек булып тора.

(«Милиция, законность, правопорядок»).

Шерлок Холмс буласың килсә...

Чаллыда инде икенче ел «Калкан» исемле милиция лицее эшли. Анда үсмерләрне конкурс аша сайлап алалар. Укучылар биредә ныклы сугышчан чынығу ала, спортның күп төрләре белән шөгыльләнә. Әлбәттә, киләчәктә Шерлок Холмс булу серләрен дә үзләштерәләр.

(«Челнинские известия»).

Оныклары түләячәк

Яңа ел кичендә бер ресторан: «Бүгенге клиентларның ашаганы-эчкәне өчен оныклары түләячәк» дигән белдерү элгән. Тумаган оныклары хисабына кәефләнеп алырга теләүче дә табылган бит. Лыкынганчы шәраб эчкән, әйбәтләп ашаган. Ахырда булачак оныгының адресын калдырып таярга уйлаган. Официант аңа түгәрәк кенә сумма түләргә тәкъдим иткәч, ул: «Ә белдерү нәрсә аңлата?» дигән. «Белдерү үз көчендә кала, сез бабагыз өчен түлисез», дигән официант.

(«Челнинка»).

Сыйлаганда... су эч

Сез Яңа елны каршыларга кунаклар чакырдыгыз ди. Өстәлгә байтак кына аракы шешәләре дә тезеп куйдыгыз. Менә Яңа елга изге теләкләр, матур сүзләр әйтеп, бокаллар күтәрәсез. Хуҗа тәкъдим иткәч, кунаклар ничек эчмәсеннәр инде! Тик... эчкәч, йөзләренә аңлаешсыз сәер бер төс керә. Һәм, әлбәттә инде, сез аптырыйсыз. Моның серен дә соңгы кеше булып кулыгыздагы хәмерне авыз иткәч кенә аңлыйсыз. Аракы түгел, су бит бу! Югыйсә, кибеттән сатып алынган эчемлек ләбаса! Ничек аңлатырга инде кунакларга бу хәлне...

Казанда күп кенә кешеләр чак кына шундый хәлгә дучар булмый калды. Ничек дисезмә? Бер төнне, шәһәр йокыга талгач, Фрунзе урамындагы Зеленодол «Чулпан» фирмасы кибетеннән сигнал килә. Патруль автомобиле кибет янына бик тиз килеп җитә. Ләкин анда берни дә юк. Ишекләрдә пломба.Шулай да экипаж күзәтә торгач, «Сок» бүлегендә ут сүнгәнен күрә. Кибет директорын алып килеп, эчкә үтәләр. Анда кибет экспедиторы Соколов шешәдәге аракының күп өлешен алдан әзерләнгән канистрга бушата да, шешәгә су тутырып, заводтагыча бөкәләп куя икән. Ул 60 литр шундый «аракы» әзерләп өлгергән иде. Ярый әле фаш ителде, аракы урынына салынган су табыннарга барып җитмәде.

(«Казанские ведомости»).

Гасыр уены булырмы?

Озакламый Татарстан һәм Русия Президентлары теннис мәйданчыгында очрашачак дигән сүз дөрес микән?

Мондый матчның булуы турындагы имеш-мимешләр бик нык арттырылган сыман. Русия Президентының теннис уйнау буенча стажы шактый зур, ә Татарстан Президентының әлегә хәтле спортның бу төре белән шөгыльләнүе мәгълүм түгел иде. Хәер, якын арада көчләрнең урнаштырылу тәртибе үзгәрергә дә мөмкин. Кайбер чыганаклардан билгеле булганча, Минтимер Шәймиев актив рәвештә теннис белән шөгыльләнә башлаган, диләр...

Бәхетсез «кошлар»

Урыс һәм совет армияләрендә кош фамилияле гаскәр башлыклары күп иде (Соколовский В.Д., Воронов Н.Н., Курочкин П.А., Чибисов Н.Е., Кулик Г.И., Гусаковский И.И., Жаворонков С.Ф. һәм башкалар). Нигездә алар барысы да «үз урыннарында» иде, күбесе шәп иттереп сугышты һәм, әлбәттә инде, берсе дә антына хыянәт итмәде. Ә менә шундый фамилияле хәрби министрларның берсенең дә эше пешмәде.

Куропаткин А.Н. — 1898-1904 еллардагы хәрби министр. Маньчжурия армиясенең командующие һәм Ерак Көнчыгыштагы кораллы көчләрнең баш командующие буларак, Япония белән сугышта оттыра. Ә үзе менә дигән администратор һәм инсафлы кеше була. Төрле илләрнең чакыруына карамастан, советлар Русиясеннән бер җиргә дә китми, ләкин үзе акларны да, кызылларны да якламый. Кыскасы, аның «кош фамилиясе» Ляоян һәм Мукден янындагы сугышта җиңелү белән мәңгегә бәйле булып калды.

Соколов С.Л. — СССРның 1984-1987 еллардагы оборона министры. Германиядән очып килеп Мәскәүнең Кызыл мәйданына төшеп утырган алман егете һәркемнең хәтерендәдер әле. Гәзитләрдә оборона министрының фуражкасына чит ил самолеты төшеп утырганын сурәтләгән карикатуралар да басылып чыкты.

Аннан соңгы оборона министры — **П.С.Грачев.** Менә шундадыр ул топ хикмәт! Күптән генә түгел армиянең акча капчыгы — генерал Воробьевны шытырдатып эшеннән алдылар.

В.Черных,
отставкадагы полковник.

P.S. Яңа оборона министры постына отставкадагы генерал А.И.Лебедьне тәгаенләү юккадыр ул. Монда уйланырлык нәрсәләр шактый әле.

«А и Ф».

Алхәбәр

Муллагали ни күргән?

Сон буендагы авылларның берсендә яшәүче Муллагали исемле кеше тау тишегендә ниндидер җан иясен күреп кайта. Галәмәт тә озын буйлы, бөтен тәнен йон каплаган, кеше кыяфәтендәге бу «нәмә» турында ишеткәч, бөтен авыл аякка баса. Берәүләр ышанса да, икенчеләре Муллагалине алдакчы дип саный. Шик белдерүчеләр арасында Тәкә Сабиры да бар.

Гәзитебезнең 16 нчы санында чыккан язмасында И.Сирматов Муллагали күргән шул «нәмә» турында хәбәр иткән иде.

«Муллагалинекеләр белән Тәкәләр элек-электән үк спор яшәгәннәр, — дип дәвам итә автор. — Бабаларының бабаларыннан ук. Ут өстенә чүмәлә, дигәндәй, учакка бензин сипкән кебегрәк була инде бу. Әй, талашалар болар, әй,талашалар. Сугышуга барып җитәләр. Халыкка кызык ул боларның сугышканын карап торуы. Берсе-бер килеп араламый. Әгәр дә мәгәр шунда участковый Фәнил килеп чыкмаган булса, йә Тәкә Муллагалине буып ыргытадырые, йә Муллагали арба кендеге белән Тәкәнең башын ярадырые».

Бу язманың дәвамын киләсе елның 1 нче санында укырсыз.

Таш елатырлык сүз

Казан урамнары буйлап
Үтәселәр бар икән.
Күзгә төтен җибәрәләр...
Төтен түгел, пар икән.

Ышандык Коммунасына,
Ышандык — Думасына.
Пар булып очканмы әллә
Париж коммунасы да?..

Бусы күңелдәгечә булды

«Мәдәни җомга» гәзитен һәр атнада сөенеп кулыма алам һәм рәхәтләнеп укыйм. «Мәдәни җомга» үзенең бай эчтәлеге һәм күләме белән журналга тиң.

Республикабызның иҗат кешеләре, зыялылары үзләренең мәгънәле язмалары белән меңләгән укучыларга рухи азык өләшәләр. «Әдәби җомга» гәзите дөньяга чыгар-чыкмас хәлдә туктап калган иде. Менә сез нәшер итә торган «Мәдәни җомга» күңелдәгечә булды, басма киләчәктә дә үз кыйбласына тугры хәлдә калыр дип ышаныч белдерәбез.

Гәзиттә үзләренең язмалары белән бик күп яңа авторлар да катнаша һәм бу — күңелле күренеш. Сезнең гәзиткә язып торучыларга карата игътибарлы карашыгыз да хөрмәткә лаек!

Сәлах ШӘРИПОВ.
Бөгелмә шәһәре.

Мәчеткә дә алып барам

«Мәдәни җомга» гәзитен аның чыга башлаган көннәреннән бирле яратып укып барам. Гәзит миңа тирән һәм бай эчтәлекле булуы белән ошый. «Мәдәни җомга» битләрендә дин темасына да материаллар еш бирелә. Аларны мәчеткә дә алып барам, килүчеләргә кычкырып укыйм.

Хәбиб ИСМӘГЫЙЛЕВ.
Лениногорск шәһәре.

Тузга язган сүзләр

Өем җылы, мендәрләрем йомшак,
Җылы җәйләр керә төшемә.
Тән җылысы гына җитеп бетми,
Җан җылысы кирәк кешегә.

Кышкы озын кичләр... Без инде ул
Шул кичләрдә чыра яндырган.
Җомгаларның изге икенлеген
Пәйгамбәрләр әйтеп калдырган.

Тузга язган сүзләр генә укыйм,
Күңелемдә уйлар куерса.
И «Мәдәни җомга»! Тузга язган
Гамәлләр кыл, Алла боерса...

Өкрам **ШӘФИГУЛЛИН** фотосурәте.

Үкы да уйла!

Шундый җинаятьләр теркәлгән...

Һәр яңа ел яңа туган сабый бала кебек. Аның беренче таңында җемелдәгән ап-ак кары да, төрле тарафлардан яңгырап торган шатлыклы авазлары да күңелгә аклык-пакьлек булып сеңә, өметләндерә, ашкындыра. Яңа ел — сабый бала. Ул әле бернинди гөнаһларга да, аһ-зарларга да, кайгы-хәсрәтләргә дә тармаган. Шулай булып кала алырмы ул? Без аны үз күңелебездә шул килеш чиста итеп, гөнаһсыз итеп, керсез итеп, ак һәм пакь итеп саклый алырбызмы? Ышанасы, өметләнәсе килә.

1994 елның 31 декабрендә һәм 1995 елның 1 гыйнварында булган кайбер фаҗигаләр турында искәртү әнә шул теләктән — Яңа елны чиста итеп саклау теләгеннән.

Җөмһүриятебездә Яңа елны фәкать авыл җирендә генә матур каршылый беләләр кебек. Ә шәһәр кешеләре исә бу кичтә дә иске елда кылган кырын эшләрен дәвам иттерәләр. Һәрхәлдә, милиция көндәлегенә теркәлгән фактлар моны ачык дәлилли. Әйдәгез, шуларга күз салыйк.

КАЗАН. Кол Гали урамында яшәүче 1964 елгы С.Степкин иске елны озату, ә яңасын каршылау төнендә күршесе Симашкин белән бергә утыра. Шактый гына сәрхушләнеп алгач, ике арада канга батып «дөнья бүлешү» башлана. Һәм бүлешәләр дә: Симошкинга теге дөнья тәти.

Зур Кызыл урамында Ширкин дигән берәү бәйрәм «фейерверкы» ясый. Урамдагы узгынчылардан, утлы корал белән янап, акча җыеп йөри. Милиция хезмәткәрләре тоткарлау максатында аңа якынлашкач, аларга каршы да ут ача. Әмма, җавап итеп, автоматтан залп бирелгәннән соң, коралын җиргә ташлап, кулларын өскә күтәрергә мәҗбүр була.

Гадел Кутуй урамында торучы Гарипов подъезд яныннан үтеп баручы билгесез ханымга барып ябырыла һәм аны дөмбәсләп кыйный башлый. Күңеле булгач (ә бәлки Яңа ел кичәсендә артык мавыгасы килмәгәнгәдер), мескен ханымны чишендерә дә, киемнәрен алып китеп бара, оятсыз! Әмма койрыгына тиз басалар аның.

Ямашев проспектында яшәүче абыйлы-энеле Колосовлар Яңа елның беренче таңын урамда, Химиклар сарае каршындагы чыршы янында каршыларга чыгалар. Шулчак ошбу ике сәрхушнең каршысында участок инспекторы пәйда була. Туганнарның өлкәне, озак уйлап тормыйча, аны Яңа ел белән тәбрикли һәм яңак төбенә «чын күңелдән» берне... томыра. Нәтиҗәсе — үзләре өчен аянычлырак була...

Островский урамында яшәүче пенсионер Логиновага өч яшүсмер сюрприз ясый. Ул, күчтәнәчләр алып, үзе яшәгән йортның подъездына кергән чагында аның колак төбендә шампан шешәсен шартлаталар. Шушы тавышка бичара ханым һушын җуеп идәнгә егыла. Ә әлеге өч егет аның күчтәнәчләрен һәм кесәсендәге акча янчыгын әләктереп чыгып элдерәләр.

Болардан тыш, өч гаиләдә ызгыш-талаш чыга. Һәммәсендә дә берәр кеше, авыр тән җәрәхәте алып, хастаханәгә озатыла.

ЧАЛЛЫ. Монда нибары ике җинаять теркәлгән. Икесе дә гаилә низагы аркасында, ир белән хатын арасында килеп чыккан.

ТҮБӘН КАМА. Шәһәрнең һөнәр училищесында укучы Чазов һәм Вафин 15 яшьлек Гарипованы үзе яшәгән йортның подъездына алып кереп көчлиләр. Бичара кыз Яңа елны күз яшьләренә батып каршылый.

Яшьлек урамында яшәүче Терентьев «Айгөл» кафесыннан чыгып килүче бер сәрхуш аганың чәшкә бүреген салдырып кача. Әмма каракны бик тиз әләктерәләр. Таланучы җинаятьче белән бергә шин заводында эшләүче кеше булып чыга.

ЗЕЛЕНОДОЛ. Шәһәрнең бәйрәм тынычлыгын бирергә килгән Казан кунагы боза. Мәҗлеснең иң күркәм вакытында ул, тыйнаклыгын җуеп, фатир хуҗасына пычак белән кадый.

Шундый ук бер очрак **БӨГЕЛМӘ** шәһәрендә теркәлгән.

Без монда «теркәлгән» дигән сүзне еш кабатладык. Ә теркәлмәгән җинаятьләр кайда күпме? Яңа елны тыныч, матур каршылый беләбезме? Без моны телибезме? Алга таба бирелгән киңәшләр — Яңа елны матур, тыныч һәм исән-имин каршыларга теләүчеләр игътибарына.

— Берүк үзегез эчеп исермәгез һәм исерекләр яныннан ераграк булырга тырышыгыз.

— Урамга ялгыз чыгып йөрмәгез. Иң яхшысы — телевизор янында президентларыбызның һәм сәясәтчеләрнең изге теләкләрен тыңлап, аларның нурлы йөзләренә карап утырыгыз. Телевизорның тавышын бар куәтенә ачыгыз. Монысы күршеләрдәге гауга тавышын ишетмәмешкә салышу өчен кирәк. Юкса, изге ният белән араларга чыгып, «кайнар нокта»дан күз төпләрегезнең чыршы тәтиләре кебек аллы-гөлле төсләргә керүе ихтимал.

— Үзегез кунакка баргач та, табын янында «фатирыбызны талап чыкмагайлары» дип борчылып утырмагыз. Мондый бәйрәмнәрдә фатир каракларының активлыгы бер елны да күзәтелмәгән. Чөнки алар бу көнне ел буена фатир басудан кергән табышка ихлас күңелдән типтерергә яраталар.

— Кыш бабай һәм Кар кызы чакырып алдана күрмәгез. Кар кызының «коралланган һәм аеруча куркыныч» булып чыгуы ихтимал.

— Кар бөртекләренә сокланып, хисләр дөньясына чумып, урамда иртә-таңнан йөрмәгез. Онытмагыз: «ач бүреләр»нең махмырдан интегеп ауга чыга башлаган сәгатьләре якынлаша.

— Аулак урыннарга керергә тырышмагыз: күләгәдә төлке була. Мөхтәрәм җинаятьчеләребезгә, урамның вак-төяк хулиганнарына да гозеребез бар. Кырын эшләр кылып, милиция тарафыннан кулга алынганчы, үз-үзегезне кулга алыгыз. Милиционерларның «Җинаятьләр бетте, ахрысы, бу Яңа елда штат кыскартулар башланмагае», — дип котлары очсын!

Язманы **Рамил ВӘЛИЕВ** әзерләде.

Тычканның әҗәле җитсә, мәченең ботын тешли, ди.

Дүшәмбе

1 гыйнвар

«ТАТАРСТАН»

17 30 Мультфильм 17 40 Балалар өчен «Тамычы» 18.05 Ә Зарипов Телевизион спектакль. «Үзеңнеке үзәктә» 18.50 «Сандугач-95» Җыр фестивале (Тәнәфестә (20 15) — «Әлли-бәлли-бәү» 21.55 Нәфис фильм премьерасы «Победа любви» 4 нче серия 23.25 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

9.00 Музыкаль программа 10.00 Тамаша залы. 10.45 Өлкәннәр өчен мультфильмнар 11.25 «Леонид Лейкин белән «Хәерле иртә» 12.00 Водевиль. «Крепостная актриса» 13.45 Суперхоккей 20 ел узгач «Монреаль Канадиенс — ЦСКА» 16 10 Динле кешенең тантаналы тавышы 16.40 «Кешеләр дөньясында» 17.00 «Яңа ел йолдызлыгы» (Бәйрәм программасы) 19 40 Эфирда — музыка. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.20 «Җирле вакыт» Информацион программа 20.50 Видеомода. 21 10 Нәфис фильм «Отель «У погибшего альпиниста» 22.40 Өлкәннәр өчен мультфильмнар «Аббот и Костелло» 0.10 Телесериал «Особое подразделение» «Искушение»

1 НЧЕ КАНАЛ

Яңа ел бәйрәме!

4.30 «Иртә» Бәйрәм чыгарылышы. 9.00, 15.00, 18.00, 0.50 «Яңалыклар» 9.15 «Мультитроллия»да кунакта. Төлке баласы һәм аның дуслары. 10.00 Фильм-әкият «Снежная королева» 11.25 «Тәмле» 11 45 «Уйна, гармун!» 12.15 «Йолдызлар сәгате» 13.00 «Освободите Вилли» фильмында кит маҗаралары. 15.20 «Җыр-95» Яңа ел чыгарылышы. 1 нче кисәк 18.20 Премьера! «Ералаш» журналының кызыклы хәлләре 19.00 Телеуен «Бу көйне беләсеңме?» 19 45 Г Хазановның юбилей кичәсе 20.50 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21 45 Г Хазановның юбилей кичәсе (дәвамы) 22.50 Мэл Гибсон «Птичка на проводе» комедиясендә. 1.00 «Ралли: Париж—Гранада—Дакар» 1 10, 3.45 Телефильм: «Криминальный талант» 1 нче һәм 2 нче серияләр.

«РУСИЯ»

9.05 «Йолдызнамә» 9 10 «Теремкөй» 9.25 Сериал: «Одиссея» 26 нчы һәм 27 нче серияләр..10.10 Нәфис фильм «В поисках капитана Гранта» 11 15 «Беренче дубль» 11 45 Документаль фильм. «Жил-был Лис» («Ника-94» премиясе) 12.40 «Клип-антракт» В.Меладзе 12.45 «Өч баһадир» 13.30 «Ретро-шлягер» 14.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 14.25 Нәфис фильм «Начало» (1970) 15.55 «Де-факто» 16.10 «Хайваннар дөньясында» 17.05 «Кипрас Мажейка» «Янәшәләр» 17 20 «Сабый авызыннан» 18.05 Юмористик программа. «Аракы турында» 19.05, 20.05 Стивен Кинг сценарийе буенча. Фәнни-фантастик триллер премьерасы «Золотые годы» (АКШ) 5 нче һәм 6 нчы серияләр 21.25 Өлкәннәр өчен мультфильм «Капитан Пронин — внук майора Пронина» 21.35 М.Дунаевский мюзиклы премьерасы: «Бәхеттән һәм мәхәббәттән үләргә» 23.30 Лос-Анджелестан юбилей концерты Фрэнк Синатраның бәрхет тавышы 0.55 «Вакыт елгасы» 1.00 Нәфис фильм: «Новый одеон» 2.15, 20.20 «Автомизгел»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10.05 «Яшәү стиле» 10.20 «Мәхәббәт турында» Нәфис фильм «Красивая, но опасная» (Италия) 12.05 «Музыка мизгеле» 12 10 Нәфис фильм «Сердца трех» 13.55 «Классика-5» Е.Максимованың Петербургтагы бенефисы 15.30 Эрмитажның ювелир җәүһәрләре 16.00 «Исемсез»

16.25 Балалар телевидениесе Телеспектакль премьерасы «Тайна мерцающих огоньков» 1 нче кисәк «Странный дом напротив» 17 10 Яңа ел бәйрәме 17 40 «Кино йорты»нда кино һәм эстрада йолдызлары 22.00 ТВ мәгълүматлары 22.20 «Туган көн» Цикл премьерасы 22.30 Нәфис фильм премьерасы «Психоавантюра» (АКШ) 0.00 Музыкаль-шоу «Телекомпакт» 0 40 Музыкаль телефильм «Карамболина-карамболетта»

Сишәмбе

2 гыйнвар

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы (31 декабрь тапшыруын кабатлау) 18.20 Телесериал премьерасы «Пострелята» 3 нче һәм 4 нче серияләр 19.05 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 10 «Гашыйклар телеканалы» 19.50 «Әлли-бәлли-бәү» 20.05 «Йолдызлар чакыра» Яңа ел кичәсе 21 45 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 30 «Эфирда — музыка» 8.00 «Юл патруле» 8 15 Мультфильм «Царевна-лягушка» 9.00 Нәфис фильм «Королевство кривых зеркал» 10.20 «Яңа ел «Зәңгәр ут» сәхифәләре буенча» 11 00 Нәфис фильм «Балерина» 12.30 Сериал «Спасатели Малибу» 13.30 Музыка һәм матбугат «Каләм осталары» — Сергей Минаев 14.30 Мультфильм «В некотором царстве» 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 Нәфис фильмнар «Фантомас» «Фантомас разбушевался» 19.00 Сериал «Лови удачу на лету» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.20, 23.55 «Шәһәр» Информацион программа 20.45 «Коммерция өйләнмәсе» 21 05 «Мәктәп комедияләре» 21 15 Телеэкспресс 21.35 Документаль сериал премьерасы «Великие марки автомобилей» «Роллс-Ройс» 1 нче серия 22.00 Русия киносы көне Нәфис фильм «Военно-полевой роман» 0.00 Өлкәннәр өчен мультфильм «Аббот и Костелло» 2 нче кисәк

1 НЧЕ КАНАЛ

Яңа ел бәйрәме!

7.30 «Иртә» 9.00, 15.00, 18.00, 0.05 «Яңалыклар» 9.15 «Мультитроллия»дә кунакта Бичура Кузька һәм башкалар, башкалар 9.55 Мэл Гибсон «Птичка на проводе» комедиясендә 11.50 «Ералаш» журналының кызыклы хәлләре 12.30 А.Калягин, С.Юрский, Г.Хазанов, Л.Филатов «Игроки-XXI» спектаклендә 14.30 Мультфильм «Серый волк энд Красная шапочка» 15.20 «Җыр-95» 2 нче кисәк 18.20 «Ыгы-зыгылы сәгать» 18.50 «КВН-95» Финал Харьков авиация институты һәм Русия Федерациясенең Кораллы Көчләре командалары 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21 45 Комедия «Солдат Иван Чонкин» 23.35 «Яңа обывательләр» 0.15 «Ралли Париж—Гранада—Дакар» 0.25, 1.20 Сериал «Яңалыкларның телевизион хезмәте»

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызнамә» 8.30 Нәфис фильм «В поисках капитана Гранта» 10.40 «Алтын ачкыч» музыкаль конкурс финалы 11 40 НБАның иң яхшы уеннары 12.40 «Чакыру билеты» «Оперетта. Оперетта. » 13.25 Информацион-нәфис программа «Фаэтон» 14.20 «Зур хоккей» 15.00 «Кайнар уңлык» 15 15 «Бию марафоны» 15.45 «Аншлаг һәм К°» 16.40 Юмористик программа «Борын» 17 10 Мультфильм «Снежная королева» 18.15 «L» клубы 19.00, 20.25 Стивен Кинг сценарийе буенча Фәнни-фантастик триллер премьерасы «Золотые годы» (АКШ) 7 нче һәм 8 нче серияләр 21 15 Күңел ачу программасы «Шәһәрчек» 21.50 «Шигърият» Б Тышкевич 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 В Тодоровский фильмы «Подмосковные вечера» 1 15, 1.20 «Автомизгел»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10.05 «Яшәү стиле» 10.20 Музыкаль телефильм «Летучая мышь» 1 нче һәм 2 нче серияләр 12.25, 19.05 «Музыка мизгеле» 12.30 Нәфис фильм «Сердца трех-2» 1 нче һәм 2 нче серияләр 14 40 Музыкаль телефильм премьерасы «Планета Богуэ» (Франция) 16.20 Мультфильм «Дорожная сказка»

16.35 «Балалар телевидениесе» Телеспектакль премьерасы «Тайна мерцающих огоньков» 2 нче кисәк «Загадка старой книги» 17 10 «Хыялпан» студиясе 17 25 Нәфис фильм «Белый клык» (АКШ)

21 20 И Аллегровада кунакта 22 05 «Туган көн» 22 15 Нәфис фильм «Жизнь Брайана по Монти Пайтон» (АКШ)

Чәршәмбе

3 гыйнвар

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 17 30 Мультфильм 17 50 Н.Исәнбәт Балалар өчен телеспектакль «Мырау батыр» 19 00 «Татарстан» 19 30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 35 «Турыдан-туры элемтә» Телевизор караучылар сорауларына Казан шәһәре һәм районнары хакимият башлыклары җавап бирә 20 35 «Әлли-бәлли-бәү» 20 45 «Татарча сөйләшәбез» 20.55 Нәфис фильм «Невероятное пари» Рольләрдә Ирина Муравьева. Михаил Козаков 22.05 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка» 7 30 20.20 23.50 «Шәһәр» Информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (2 гыйнвар тапшыруын кабатлау) 8 15, 11 05, 17 05 «Юл патруле» 8.30, 14 45 «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12 50 «90х60х90» 9.40 Диск-канал 9.55 Яңа ел ток-шоуы «Минем кино» 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 «Атна низаглары» 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Телеуен «Акчалар, акчалар акчалар » 13 05 Нәфис фильм «Приключения Электроника» 1 нче серия 14.20 Мультфильмнар 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 «Атна һәлакәтләре» 16.00, 17 20 «А.Пугачева Раштуа очрашулары» 1 нче һәм 2 нче кисәкләр 18.20 «Кино музыкасы» А.Пугачева. 18.30 Мультфильм «Аленький цветочек» 19 10 «Мәктәп комедияләре» 19.20 «Поза» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Без гено» 21 15 Телеэкспресс 21 35 Документаль сериал «Великие марки автомобилей» «Роллс-Ройс» 2 нче серия 22.00 Нәфис фильм «Прокол» (триллер) 0.15 Нәфис фильм «Календарь» (Канада) 1.25 Нәфис фильм «Гипотеза»

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә» 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 «Яңалыклар» 9 15 Сериал премьерасы «Секрет тропиканки» 10.05 «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» Финал 11.20 Мультфильм «Снегопад из холодильника» 11.30 Телеуен «Бу көйне беләсеңме?» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары Бәйләнеш — бердәмлек илләренең эшлекле хезмәттәшлеге 12.50 Телесериал «Капитан Немо» 14 05 Мультфильм «Зимняя сказка» 14 15 Сериал «30 случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 «Кактус һәм К°» 15 50 «Күңелле ноталар» 16 10 «Джунглилар чакыруы» 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» (Франция) 17 00 «Тет-а-тет» 17 30 «Спортның җиде көне» 18.20 Сериал премьерасы «Секрет тропиканки» 19 10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 Телеуен «Бу көйне беләсеңме?» 20.00 «Тема» 20 45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 45 И.Купченко һәм А.Збруев «Одинокая женщина желает познакомиться» фильмында 23.20 Бию марафоны «Станция» 0.10 «Ралли Париж—Гранада—Дакар» 0.20, 1 15 Сериал «Яңалыкларның телевизион хезмәте»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк Кирәк. » 8.30 «Йолдызнамә» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 Мульти-пульти «Ну погоди!» 11 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Кайсы як?» 17 20 «Яңа тармак» «Ерак Көнчыгыш» 17.50 «Ай тотучы» 18.00 «Видеошигърият» Н.Рубцов 18 10 Кипрас Мажейка «Янәшәләр» 18.25 «Үз уены» 18.55 Дәвамлы кино «Петербургские тайны» 1 нче серия 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20 35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 30 «Фортедан пьянога кадәр» 22 10 «Гадәттән тыш канал» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.50, 0.40 Балетмейстер триумфы Б.Эйфман

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

13.00, 16.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары 13 10 Телефильм «Мануэла» 14 00 «Тотылу» 1 нче тапшыру 14.30 «Бакчачыларга киңәшләр» 14 45 Нәфис фильм «Жизнь Брайана по Монти Пайтон» 16 15 «Яшәү стиле» 16 40 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 16.55, 18.00, 22 00 «Музыка мизгеле»

17 00 «Балалар телевидениесе» Телеспектакль премьерасы «Тайна мерцающих огоньков» 17 50 «Бөтен Русия буйлап» 18.10 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә 22 10 «Блеф-клуб» 23.00 «Спорт спорт спорт » 23 10 «Туган көн» 23.20 Нәфис фильм «Американская любовь» 1 нче серия

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

Пәнҗешәмбе

4 гыйнвар

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18 15 Н Исәнбәт Балалар өчен спектакль «Мырау батыр» 19 00 «Татарстан» 19 30 «Без нинди?» Психотерапевт Рамил Гарифуллин алып бара 19 35 «Авыл» Балтач районында очрашулар 20 05 «Әлли-бәлли-бәү» 20 15 «Татарча сөйләшәбез» 20 25 «Консерватория сәхнәсендә» Композитор Рафаэль Билялов 21 05 Нәфис фильм «Маскарад» 1 нче серия Рольләрдә — Т Макарова. Н Мордвинов 22 05 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10, 19 10 «Эфирда музыка» 7 30, 20 20 23 55 «Шәһәр» Информацион программа 7 55 Телеэкспресс (3 гыйнвар тапшыруын кабатлау) 8 15, 11 05 «Юл патруле» 8.30, 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» 9.20, 12 50 «90х60х90» 9 40 Диск-канал 10 25 «Ресторан рейтингы» 10.40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 «Нью-Йорк Нью-Йорк» 11 50 «Валюта бәясе» 12 00 Сериал «Ночная жара» 13 05 Нәфис фильм «Приключения Электроника» 2 нче серия 14 15 Мультфильмнар 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 «Тегеләр, кемнәр » 15 50 «Ток-шоу «Мин үзем» «Ирем белән бергә бала таптым» 16.50 Нәфис фильм «Ночь вопросов» 18.35 «CNN стиль» 18 55 «ПОСТ — музыка яңалыклары 19.20 «Ушуайя» 19 40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Коммерция өйләнмәсе» 21 05 «Мәктәп комедияләре» 21 15 «Телеэкспресс» 21 35 Документаль сериал «Великие марки автомобилей» «Роллс-Ройс» 3 нче серия 22 10 Нәфис фильм «Детектив Кид» (АКШ) 0 10 RED WAVE тәкъдим итә Джон Уэстли Хардинг

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә 8.33 «Ел буе яшелчә бакчасы» 9.00, 12 00, 15.00, 18 00, 0 20 «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Секрет тропиканки» 10 05 «Тема» 10 50 «Сәяхәтчеләр клубы» 11 40 «Тәмле» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Кышкы каникуллар! «Капитан Немо» 2 нче серия 14 00 Мультфильм «Новогоднее приключение» 14 15 Сериал «30 случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 «Лего-го» 16 10 «Тин-тоник» 16 35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» 17 00 «Рок-дәрес» 17 30, 1 35 «Спортның җиде көне» 18 20 Телесериал «Секрет тропиканки» 19 10 «Ыгы-зыгылы вакыт» 19 35 «Лотто-миллион» 20 00 «Күзгә-күз» Тапшыруны А Любимов алып бара 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21 45 Орнелла Мути һәм Микеле Плачидо «Народный роман» фильмында 23 35 «Музыка күзәтүе» 0 30 Ралли, Париж — Гранада — Дакар 0 40 Сериал «Яңалыкларның телевизион хезмәте» 1 05 «Музыка күзәтүе» 2.20 Музыкаль программа

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8 00, 11 00, 14 00, 17 00, 20 00, 23 00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк кирәк » 8 30 «Йолдызнамә» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 40 «Телегазета» 9 45 «Крестьян мәсьәләсе» 10 05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 Мульти-пульти «Ну погоди!» 11 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14 20 «Эшлекле Русия» 16 05 «Шау-шулы яңалыклар» 16 20 «Көн дә бәйрәм» 16 30 «Яңа тармак» «Игелек кыл» 17 20 Мульти-пульти «Новогодний ветер» 17.35 Клип-антракт «На-На» төркеме 17 40 «Амика веритас» Юристлар телеконкурсы 18 10 «Сезнең партнер» «Русиянең гимер юллары» 18 25 «Алтынчы тойгы» 18 55 Дәвамлы кино «Петербургские тайны» 2 нче серия 20 25 «Бәйнә-бәйнә» 20 35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 30 «Битлек-шоу» 22 10 «Үтә яшерен» 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23 50 «Музыкаль Флоренция»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

15 15 Телесериал «Мануэла» 212 нче серия 16 05 «Бакчачыларга киңәшләр» 16 15 «Яшәү стиле» 16 30 22 45 ТВ мәгълүматлары 16 40 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 16 55 «Музыка мизгеле» 17 00 Балалар телевидениесе Телеспектакль премьерасы «Тайна мерцающих огоньков» 4 нче кисәк «Старая и ужасная колдунья Ядвига Карловна» 17 55 «Бөтен Русия буйлап»

21 00 Мариинскийда триумф Майя Плисецкая 21 25 «Урыслар Германиядә» 21 55 «Золотой телец» Күңел ачу программасы 23 00 «Спорт спорт спорт » 23 10 «Туган көн» 23.20 Цикл премьерасы «Старое танго» 23 40 Нәфис фильм «Американская любовь» 2 нче серия

ҖОМГА
5 ГЫЙНВАР

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 17 50 Н.Исәнбәт Балалар өчен спектакль «Мырау батыр» 4 нче һәм 5 нче бүлекләр 19 00 «Татарстан» 19.30 «Видеоспорт» 19 45 «Әлли-бәлли-бәү» 20.00 «Татарча сөйләшәбез» 20 15 «Җомга көн кич белән» Альманах 21 00 Нәфис фильм «Маскарад» 2 нче серия 21 55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30, 20.20, 23.25 «Шәһәр» Информацион программа 7 55 «Телеэкспресс» (4 гыйнвар тапшыруын кабатлау) 8 15, 11 05 «Юл патруле» 8.30, 11 45 «Дарухәнә» 8.40 «Суп аяктан!» 9.20, 12.20 «90х60х90» 9.40 Диск-канал 10.00 «Чәй клубы» 10.40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11.20, 16.25 «Спорт атнасы» 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Детектив сериал «Ночная жара» 13.05 Нәфис фильм «Приключения Электроника» 14 15 Мультфильм «Золотая антилопа» 15.00 «Динле кешенең тантаналы тавышы» 15.30 «Тегеләр, кемнәр...» 15.50 Сериал: «Мелочи жизни» 16.55 А.Челентано «Блеф» фильмында 18.40 «Видеогид» 19.00 Нәфис фильм «Корабль любви» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 20.55 «Автомобильдән саклан» 21 00 «Мәктәп комедияләре» 21 15 Телеэкспресс 21 35 Нәфис фильм: «Парфюм» 23.50 Джентльмен-шоу 0.20 Нәфис фильм: «Судьбы кровавые черты» 1 нче серия 1.45 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 8.45 «Детальләр» 9.00, 12.00, 18.00, 23.05 «Яңалыклар» 9.15 Сериал. «Секрет тропиканки» 10.05 «Күзгә күз» Тапшыруны А.Любимов алып бара. 10.45 «Хайваннар дөньясында» 11.25 «Бар да өйдә чакта» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Кышкы каникуллар! «Капитан Немо» 3 нче серия 14.00 Мультфильм: «Снегурята» 14.10 Сериал «30 случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Яңа чынбарлык». 16.15 Мультфильм-әкият «Легенда о Большой лапе» 17.30, 1.20 «Спортның җиде көне» 18.20 Сериал. «Секрет тропиканки» 19.10 «Кыргый кыр» 19.25 «Кеше һәм закон» 19.55 «Могҗизалар кыры» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 45 Сериал: «Детективное агентство «Лунный свет» 22.45 «Трасса» 23 15 Ралли Париж — Гранада — Дакар 23.25 Төнге кинозал Детектив комедия «Все напрасно»

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк..» 8.30 «Йолдызнамә» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9.40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11.30 Мульти-пульти «Ну, погоди!» 11 50 Балалар өчен телесериал Нәфис фильм «Одиссея» (Канада) 28 нче серия 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Озынайтылган көн» 16.50 «Ай тотучы» 17 20 «Яңа тармак» 17 50 Нәфис фильм «Зорро» 47 нче һәм 48 нче серияләр 18.50 «Беркем дә онытылмаган» 18.55 «Барлык кешеләр өчен музыка» 19.25 «Вертикаль» «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21 30 «Атна йомгаклары» 22 10 «К-2» тәкъдим итә Роман Карцев, Фазиль Искәндәр һәм Марк Розовский «Фрак народа» программасында 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 Төнге сеанс Нәфис фильм «Горькая луна» (Франция)

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

13.00, 16.30, 22 45 ТВ мәгълүматлары 13.05 Телесериал. «Мануэла» 213 нче серия 13.55 «Кояш тотылу» 2 нче тапшыру 14.25 «Бакчачыларга киңәшләр» 14.35 Балалар өчен нәфис фильм «Щенок» 16.15 «Яшәү стиле» 16.40 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 16.55 «Музыка мизгеле» 17 00 Балалар телевидениесе «Кеше саен бер иман» 17.20 «Паутиныч яшәгән җирдә» 17.35 ТВ мәгълүматлары Европа калейдоскобы, 18.10 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә

21.00 Л Толстой хикәясе буенча нәфис фильм. «Дом на песке» 22.20 Телефильм-концерт «Песни памяти моей» 23.00 «Спорт спорт. спорт..» 23 10 «Туган көн» 23.20 «Парадлар парады» Музыкаль шоу 0.00 Нәфис фильм «Чужестранец» (АКШ)

ШИМБӘ
6 ГЫЙНВАР

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.25 Мультфильм 18 35 Н.Исәнбәт Балалар өчен телеспектакль «Мырау батыр» 6 нчы бүлек 19 00 «Татарстан» 19.30 «Гадәти шимбә» (30 декабрь тапшыруын кабатлау) 20.20 Р Мөхәммәдиев. Телефильм «Истәлек өчен, Гыйлемханга» 1 нче бүлек 21 15 «Джаз вакыты килде» 21 50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7 00 «Бүген Мэрилин белән» 7 30, 20.20, 0.00 «Шәһәр» Информацион программа 7 55 Телеэкспресс (5 гыйнвар тапшыруын кабатлау) Узган атна тапшырулары 8 15 «Коммерция әйләнмәсе» (2 гыйнвар көнендәге тапшыруны кабатлау) 8.35 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 8.45 «Видеомода» 9.05 «Поза» 9.35 Мультфильм: «Синяя птица» 10.30 «Атнага бер тапкыр» 11.05 Сериал: «Подводная Одиссея команды Кусто» 12.00 Юмористик сериал: «Один к десяти». 12.30 «Сез — шаһит» 12.55 Сериал. «Мелочи жизни» 13.30 Нәфис фильм: «По семейным обстоятельствам» 15.55 Игорь Крутойның иҗат кичәсе. 16 45 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 17 00 «Эфирда — музыка. 17 10 Мультсериал «Город собак» (Канада). 17 35 «Яшерен йомыш». 18.00 «Исәнмесез!» 20.45 «Мәктәп комедияләре» 20.55 «Йозак тишеге» 21 15 Телесериал: «Тропическая жара» 22.10 «Музыкага чикләр юк» 23.10 Сериал: «Строго на Юг» 0.25 Нәфис фильм: «Судьбы кровавые черты» 2 нче серия. 1.55 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

7 45, 9 10 «Уяныгыз» телеканалы. 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 18.00 Яңалыклар. 10.30 «Оттырма» 11.00 «Иртәнге почта» 11.35 «Төмле». 11.55 Сериал: «Живопись. Великие имена. Эдуард Мане». 12.15 «Бомонд» 12.55 «Цветной бульвардагы циркта Яңа ел елкасы» 2 нче тапшыру. 13.00 Мультфильм: «Тимошкина елка». 13.15 Е. Савинова, А.Папанов, А.Ширвиндт «Приходите завтра» комедиясендә. 15.20 «Автомобиль һәм мин» 15.50 «Хайваннар дөньясында» 16.30 «Америка М.Таратута белән» 17.00 Мультфильм: «Кто сказал мяу?» 17 10 «Бәхетле очрак» 18.20 «Шулай бервакыт...» 18.30 Раштуа сәхифәләре. Юрий Норштейн мультфильмы: «Сказка сказок» 19.05 Алтын серия. 1971 ел. «Джентльмены удачи» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21 00 «Вакыт» 21 45 «Изге Җирдә» 22.00 Раштуа. Мәскәүнең Богоявление кафедраль соборыннан трансляция 2.00 Ралли: Париж — Гранада — Дакар

«РУСИЯ»

8.00, 11.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызнамә» 8.30 Балалар өчен телесериал: «Вовкулакия, или Загадка доктора Никодима» 8.45 «Раштуа алдыннан коляда килде» 9.00 Ура, каникуллар! Нәфис фильм. «В поисках капитана Гранта» 7 нче серия 10 15 «Синең мөмкинлекләрең, кешә» 10.45 Гыйнварда кино. 11 00 «Зур хоккей 11 40 «299-00-00» хезмәтә 11.55 «Ватандашлар» 12.25 «Тайны животных» (Бөекбритания) телесериалыннан документаль фильм: «Морские убийцы». 13.20 «Амика веритас» Юристлар телеконкурсы. 13.50 «Беренче нөсхә» 14.20 «Де факто» 14.35 «Урысча караоке» 14.55 Пилигрим. Русиянең сәяхәтләр бюросы 15.40 «Җәберләү империясе» 16.30 Документаль фильм премьерасы: «Русская идея» 17 30 «Футболга чикләр юк» 18.15 «Рухият музыкасы» Г Свиридов. 18.55 Дәвамлы кино. «Петербургские тайны» 3 нче серия 20.25 Телеэкран премьерасы. Нәфис фильм: «Прекрасная незнакомка» (Польша — Русия) 22.00 «Ике катлы портрет» 23.30 «299-00-00» хезмәтә. 23.45 «Вакыт елгасы» 23.50 «Автомизгел» 23.55 Кинотавр һәр елны Раштуа алдыннан.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

10.00 «Яшәү стиле» 10.15 Нәфис фильм: «Остров сокровищ» 1 нче серия. 11.20 «Яшә, «Терем»! 11 45 «Туган көн» 11.50 Цикл премьерасы «. Барлык узганнар» «. Беренче йолдыз кабынганчы» 12.30 «Наобум» Л.Нарусова и А.Собчак. 13.00 «Йолдыз» белән рандеву» Л.Успенская. 13.30 Нәфис фильм. «Чужестранец» (АКШ). 15.20 Балалар телевидениесе. «Алтын ачкыч» 15.45 «Ыргыт өйдә» 16.30 ТВ мәгълүматлары 16.40 «Объектив» Документаль фильм премьерасы «С Астафьевым за Царь-рыбой» 17 10 Документаль фильм. «Арагон» (Франция) 1 нче кисәк «Изменить жизнь» 18 10 Зур фестиваль.

22.00 ТВ мәгълүматлары-репортер 22.20 «Оранж-ТВ» тәкъдим итә. 23.20 Нәфис фильм «Высшая черта» (Италия) 0.45 Төнге күңел ачу программасы «Музыка оҗмахы»

ЯКШӘМБЕ
7 ГЫЙНВАР

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 Н.Исәнбәт Балалар өчен телеспектакль. «Мырау батыр» 7 нче һәм 8 нче бүлекләр 19.50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары. 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 «Мизгел» 20.55 Р Мөхәммәдиев. Телефильм: «Истәлек өчен, Гыйлемханга» 22.10 «Сәдә» вокаль квартеты җырлый. 22.25 Документаль сериал: «Суперзвезды Голливуда» (Дастин Хофман) 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7 00 «Рик Реннер белән яхшы хәбәр». 7 30 «Телеэкспресс». Атналык кабатлау 9.00 «Шәһәр» Информацион программа. Узган атна тапшырулары. 9.20 «Коммерция әйләнмәсе» (4 гыйнвар тапшыруын кабатлау). 9.40 «Автомобильдән саклан». 9.50 «Видеогид» 10.10 «Ушуайя». 10.30 «Йозак тишеге» 10.45 Мультфильм: «Антарктида». 11 05 «Барысын да беләсе килә». 11 30 «Леонид Лейкин белән «Хәерле иртә» 12.00 «Атна фаразлары» 12.30 Телесериал «Подводная Одиссея команды Кусто». 13.20 Нәфис фильм: «Свадьба с приданым» 15.25 Өлкәннәр өчен мультфильмнар. 15.55 Нәфис фильм: «Покровские ворота». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 18.25 «Җирле вакыт» Информацион программа. 18.55 Мультсериал: «Город собак» (Канада). 19.20 Сериал. «Спасатели Малибу» 20.20 «Республика» Информацион программа. 20.50 «Тамаша залы» 21.20 Нәфис фильм: «Равноденствие» 23.20 Сериал: «Строго на Юг» 0.10 «Исәнмесез!» (6 гыйнвар тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

РАШТУА БӘЙРӘМЕ

7.50 «Спортлото» тиражы. 8.00, 9.10 «Уяныгыз!» телеканалы 9.00, 15.00, 18.00, 0.00 Яңалыклар. 10.25 «Бар да өйдә чакта». 11.00 «Таң йолдызы». 11.50 «Беренче кыллардан» 12.00 Русиягә хезмәт итәм. Хәрби йомышчы. 12.30 «Уйна, гармун!» 12.55 Провинция сәхифәләре. Кострома. 13.20 «Ап-ачык — акылга сыймаслык» 13.45 Эмиграция тормышыннан. Күргәзмәдән рәсемнәр 1 нче кисәк. 14.30 Көлкеле манзара. Тапшыруны Е.Петросян алып бара. 15.20 Мультфильм: «Волчище — серый хвостище» 15.30 «Аида» Дж. Верди «Опера тарихлары» циклында. 16.25 Сәяхәтчеләр клубы. 17 15 Мультфейерверк. «Легенды острова сокровищ». «Погонщики динозавров» 18.20 «Футбол күзәтүе» 18.50 «Триумф» премиясе» Русия сәнгать йолдызлары 19.20 Раштуа сәхифәләре Владимир Меньшов фильмы: «Москва слезам не верит» 22.00 «Якшәмбе» 23.00 Сериал: «Детективное агентство «Лунный свет» 0.10 Ралли: Париж — Гранада — Дакар. 0.20 «Бер күрүдә ярату» 0.55 Телефильм: «Отпуск за свой счет» 1 нче һәм 2 нче серияләр.

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызнамә» 8.30 «Мазай бабайда Раштуа бәйрәме» 9.20 Мульти-пульти: «Добро пожаловать!» 9.30 Хроно. Авто һәм мотоспорт дөньясында. 10.00 «Хәерле иртә, Европа!» 10.30 «Аты-баты...» 11 00 «Сәгать 11 дәге хәбәрләр» 11 15 «Урыс лотосы» 11 55 «299-00-00» хезмәтә. 12.05 «Китап киштәсе» 12.35 «Раштуа белән!» Мәскәү һәм Бөек Русь Изге Патриархы Алексий IIнең русияледәргә бәйрәм мөрәҗәгате 12.45 Музыкаль видеофильм: «Святая Русь» 13.45 «Кайнар Унлык» 14.25 «Кисеп бетерә алмаслык...» 14.40 Григорий Кусочкин «Юлерпеклерә». 15.25 НБАның иң яхшы уеннары 16.25 «Камыш» шаулады. 18.00 Мультфильмнар: «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха». 18.55 Клип-антракт Валерия. 19.00 «Тарих көпчәге» 20.25 Яраткан комедияләребез Нәфис фильм: «Праздник Нептуна» 21 10 «Көлеп яшәгәч, дөнья исән калды» «12 стульев» клубына 30 ел. 22.10 «Телекросс» 22.25 «Ксюшада кунакта» 23.30 «299-00-00» хезмәте 23.45 «Вакыт елгасы» 23.50 «Автомизгел» 23.55 «А» программасы.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9.00 «Сезнең көнегез». 9.25 «Шифалы сүз» 10.00 «Яшәү стиле» 10.15 Нәфис телефильм: «Остров сокровищ» 2 нче серия. 11.20 «Мәрхәмәтле дөнья» Ирина Архипова җырлый. 11.35 «Депутатларга сүз бирәбез» 11.45 «Туган көн» 11.50 «Гыйбадәтханә» 12.20 Документаль фильм: «Путь горний» 13.15 Нәфис телефильм: «Остров сокровищ» 3 нче серия 14.25 «Музыка мизгеле» 14.50 «Классика-5» «Раштуа җырлары» 15.15 «Антре» 15.35 «Хыялланы» студиясе 15.50 «. Мәхәббәт тигезләнә» 16.25 Футбол буенча Италия чемпионаты. Турыдан-туры трансляция 18.20 Цикл премьерасы: «Телешаблон» 22.00 ТВ мәгълүматлары. 22.25 «Адәм алмасы» «Ноу смокинг» 23.10 Телеэкранда детектив. Нәфис фильм: «Пять углов» (АКШ)

Һәркөнне 8.00 (якшәмбедән тыш), 19.00, 9.00 (шимбә), 10.00 (шимбә, якшәмбе) сәгатьләрдә — Мәскәүдән информацион һәм аналитик программалар трансляцияләнә.

ДҮШӘМБЕ, 1 ГЫЙНВАР

6.00 Иртәнге дулкында. 6.48 Татарча өйрәнәбез. 6.58, 7 58, 13 10 Һава торышы. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 13 10 Тапшырулар программасы. 7 50 Белдерүләр. 8.10 «Урман әкияте». Балалар өчен. 12.10 «Хуш килдең, Яңа ел!» Әдәби-музыкаль композиция 13.15 К.Тинчурин, С.Сәйдәшев «Зәңгәр шәл». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле.

СИШӘМБЕ, 2 ГЫЙНВАР

6.00 «Иртәнге дулкында» 6.53, 13.50 Татарча өйрәнәбез. 6.58, 7.58, 13.55 Һава торышы. 7.00 Концерт. 7.45, 13.55 Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр. 8.10 Балалар өчен тапшыру. 12.10 «Сандугач» җыр фестиваленең йомгаклау концерты. 14.00 «Яшьлек» студиясе. 14.30 Ш.Камал. «Хаҗи әфәнде өйләнә». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле.

ЧӘРШӘМБЕ, 3 ГЫЙНВАР

6.00 «Татарстан дулкынында». 6.53, 20.50 Татарча өйрәнәбез. 6.58, 7.58, 20.55 Һава торышы. 7.00 Концерт. 7.45, 20.55 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 19.10 Соңгы хәбәрләр. 19.40 Радиотыңлаучыларның сораулары буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 4 ГЫЙНВАР

6.00, 7.00, 12.45, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.48, 20.35 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.05, 20.40 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.15 Разил Вәлиев шигырьләренә язылган җырлар. 7.45, 12.10, 20.40 Тапшырулар программасы. 12.10—13.10 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.15 «Балалар җырлый». 12.50 Республика газеталарына күзәтү. 18.20 «Сәламәтлек» 19.40 Композитор Ф.Яруллин әсәрләреннән концерт

ҖОМГА, 5 ГЫЙНВАР

6.00 «Балкыш». 6.48, 20.35 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 12.55, 20.40 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7.00, 12.45, 19.10 «Соңгы хәбәрләр» 7 15 Концерт 7.45, 12.10, 20.40 Тапшырулар программасы 12.10—13.00 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.15 Концерт. 12.50 Республика газеталарына күзәтү. 18.20 «Чишмәләр» (чуваш телендә) 19.40 «Кичкә моңнар»

ШИМБӘ, 6 ГЫЙНВАР

6.00, 7.00 Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт 6.58, 7.58, 13.55 Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7 45, 13.55 Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8.10 «Сезнең хатларыгыз» 8.30 «Көмеш кыңгырау» 9.00 Г Бәширов. «Туган ягым — яшел бишек» Язучының 95 еллыгына багышланган тапшыру. 9.30 «Кардәшлеккә чикләр юк». 10.20 Г Бәширов «И, нарасый бала». Радиопостановка 11.20 «Пар канатлар» 12.10 Татар халык көйләре. 13.05 Яңалыклар эстафетасы. 13.25 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Көзге».

ЯКШӘМБЕ, 7 ГЫЙНВАР

6.00 «Иртәнге дулкында» 6.58, 7.58, 13.05 Һава торышы. 7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 13.05 Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.10 Ш.Җиһангирова. «Ачы бал». Хикәя. 11.10 «Тылсымлы каләм». Балалар өчен тапшыру 11.40 Җ.Фәйзи. Музыкаль әкият. 12.15 Ял концерты. 13.15 «Татарстан дулкынында» 14.00 Р.Батулла. «Сират күпере» К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле.

Батулла баганасы

Маймылдан яралганчы...

— Батулла абый, син Аллага ышанасыңмы?
— Ышанам.
— Ха-ха-ха.
— Нигә көләсең?
— Көлкә булганга! Кеше бит маймылдан яралган, моны сабый да белә.
— Син, бәлки, маймылдан яралгансыңдыр, әмма мин Аллаһы Тәгалә колы. Маймыл булуга караганда, Аллаһы Тәгалә колы булу мең өлеш артык түгелмени?

Җирләнмәгән мәет

Финляндиядән килгән татар Абдулла Гали Батулладан сораган:
— Аңламыйм мин, ни өчен илегездә тәртип юк? Үзегез бай җирдә яшисез?
— Мәет җир куенына үз вакытында тапшырылмаган. Күмелмәгән мәет бар җир өстендә!
— Кем ул?
— Ленин! Ленинны күмми торып монда һичкайчан да тәртип-әхлак булмаячак!

Өйләнмәү сәбәбе

— Батулла, син марҗаңнан аерылгач, ун еллап өйләнми йөрдең, сәбәбе ни иде соң?
— Торгынлык елларында тормаганлык чоры булып алган иде...

Гүрбашчев

— Батулла! Сөен! КПСС үлде!
— Коммунистлар исән!
— Горбачев маладис!
— Горбачев түгел!
— Кем?
— КПССны күмгәндә ул гүр башчысы булып алдан кабер казытып йөрде. Гүрбашчев! Нәселе татардан килә булыр.

Озын гомерле әсәр

Батулланың «Сөйгән ярым ятка кала» исемле җырлы-биюле комедиясе Камал театрында куела. Халык бу тамашаны бик алкышлап каршылый. Спектакльне карарга Илһам Шакир да килә. Батулла белән сөйләшкәндә Илһам әйтә:
— И, җанкөм, «Diләфрүз» кебек озын гомерле булачак бу әсәрең! Безнең халыкка шундый җыен шырдый-бырдый нәрсә ошый инде ул!

Бәхет

— Батулла, син озын чәчле хатыннарны сөясең икән. Хикмәте нидә?
— Чибәр хатынның озын толымына асылынып үлү мөмкинлеге булганга!

Кайгыртучанлык бәласе

— Нихәл, Батулла! — дигән Рәдиф Гаташ.
— Хәлләр шәп түгел! — дигән Батулла.
— Кыяфәтең әйбәт күренә!
— Үзем турында әйтүем түгел лә. Шигърият өчен борчылам әле.
— Ни, нәрсә булган шигъриятькә?
— Сез, шагыйрьләр, шигърият таҗы өчен талашасыз, нидер бүлешәсез. Әгәр дә ул таҗ ахак, алтын-көмеш-мәрҗәннәр белән бизәлгән булса, сүзем юк. Әмма татар шигыренең таҗы күгәргән калай түгелме соң?
— Син үзеңнең прозаңны кара! — дигән Гаташ.

Мәдәни җомга

Иҗтиһат

Җанга-тәнгә җылы өләшә ул...

Зөфәр абзый, өй артында үскән биек каенга күз төшереп, кулындагы тактасын йорт диварына сөяп куйды да, бер мәлгә уйга чумды. Аннары исенә килгәндәй, басынкы тавыш белән әйтә куйды:

— Зәмһәрир салкыннарга чаклы йортны өлгертәсе иде. Тизрәк мичне чыгарып, бала-чагамны җылы куышыма кертеп утыртсам, җаным тынычланыр, ниһаять, морадыма ирештем, дияр идем.

Шундый уйлар белән Зөфәр абзый әнисе өенә юл тотты. Нияте Маргилан шәһәрендә яшәүче, шушы көннәрдә генә кунакка кайткан энесе Сафуанны күреп, аның белән мич чыгару хакында сөйләшү иде. Бәхеткә, энекәше нәкъ кирәк чакта кайтты.

Бирәм, дигән колына чыгарып куяр юлына, дип, картлар тикмәгә генә әйтмәгән икән. Зөфәр абзый белән дә шулай килеп чыкты: мичченә өллә кайлардан эзләп йөрисе булмады, һавадан кинәт иңгәндәй, авылда Сафуан энекәше пәйда булды. Ә ул Маргиланда, тирә-як кышлыкларда мич чыгарып йөреп, үзбәкләрне, татарларны күп шатландырган. Шулай итеп, Сафуан рәссам-бизәүче генә түгел, оста мичче дә булып киткән.

Зөфәр абзый мичлек кирпечләрен җылы, коры җөйдә елга буенда суккан иде. Ә бүген ул, иртә таңнан торып, калдырчадагы тиен шикелле бөтерелә: мич утырасы урын тирәсенә кирпечләр ташый, зур тазда измә изә, кай ара Сафуанның йөгерек, эшкә ятып торган кулларына күз төшереп ала.

Сәгать уннарга мич нигезе — казнасы өзер иде инде. Чәй эчеп, җиңелчә тамак ялгап алганнан соң, Сафуан мич көймәсен кую турында уйлана башлады. Чөнки аның моңа кадәр аш-су пешерә торган авыл мичләре чыгарганы булмады. Үзбәкстанда аңа галанка һәм калай белән тышланган түгәрәк мичләр (контрамарка) кебекләрен генә чыгарырга туры килгән.

Ләкин Сафуан аптырап калмады. Алар төшкә мич алды, авызы һәм башын өлгерттеләр. Мичне зур итеп салганга күрә аның башы да иркен булды. Кышкы салкын төннәрдә ике бөртек малайга шундый мич башында тәгәрәшеп йокларга мөмкин.

— Бу эштә иң четереклесе — мичнең төтен һәм ялкын юллыгын дөрес һәм ипле итеп сузу, — диде Сафуан абыйсына.

Алар бер көндә мичне юшкәгә чаклы күтәрергә өлгерделәр.

— Иртәгә иртүк килермен, мичне төшкә чыгарып бетерәчәкбез, — диде мичче.

Икенче көнне дә эш кызу барды.

Сафуан сүзендә торды. Төштән соң мич морҗасы зәңгәр күкне күзли иде. Мичне карарга, дип, олы улының өенә Дилсрур абыстай да килде. Ул мичнең һәр җирен җентекләп күздән кичерде. Иреннән бик яшьли тол калган Дилсрур карчык мич чыгаруның нәрсә икәнен бик яхшы белә. Авылда шундый һөнәр иясе булмаганлыктан, хатын-кыз башы белән өендә үзе мич чыгарган кеше ул. Миче ун елдан артык хезмәт итте. Йорты янмаса, миче тагын күпме еллар игелек күрсәткән булыр иде әле.

Ярты сәгать үтмәгәндер, морҗадан сыек төтен күтәрелде. Сафуан эшеннән канәгать иде.

— Зөфәр, мичкә утын оста!

— Айн момент, син дигәнчә булыр, — дип, йорт хуҗасы өйгә кереп китте.

Ике-өч минуттан ул ишегалдына чыкты, энесе янына барып басты. Аннары Сафуанның иңбашыннан кагып:

— Булдырасың, кулларың алтын икән, энекәш, — диде. — Иртәгә мич кибәр, дип уйлыйм. Алла боерса, безгә коймак һәм бәлештән авыз итәргә кил. Әни белән!

Дилсрур абыстай, килене Җәүһәр апа, Зөфәр абзый, Сафуан һәм балачага, мич каршына тезелешеп утырып, пүләннәрдән үрләгән ялкын телләренә күзләрен төбәп, күңелле өңгәмә корып җибәрделәр...

Тагын көн туды. Яңа йортның мичennән һавага куе төтен бөркелде. Бертәрзаман борынны кытыклап, урамга тәмле коймак исе таралды. Зөфәр абзый йорты каршысыннан үткән һәрбер кешенең авызында бер сүз иде:

— Галәветдиннекеләрдә бәйрәм бүген. Йортларында иминлек булсын, мичләреннән тәмле ризыклар өзелмәсен.

Сафуан Галәветдин улы Муллагалиев Ырынбур өлкәсенең Абдуллин районындагы Чаганлы авылында крәстиән гаиләсендә туа. Доньяга килүенә ярты ел булганда, ул әтисез кала — Галәветдин абзый, хатынын һәм ике улын калдырып, фани доньядан китә. Дилсрур абыстай, ятим балалар авыр тормыш кичерәләр.

Тәпчек Сафуан мәктәптә укыган елларында шигърияттә каләмен сынап карый. Билгеле, аның шигырьләре (әгәр шулай, дип әйтергә яраса) кечкенә Сафуанның балачак хисләре, табигать күренешләре — манзаралары белән сугарылган була. Ләкин нечкә күңелле баланың рифмалы-рифмасыз шигырьләрендәге самимилекне сабакташлары һәм укытучылар яратып кабул итәләр.

Бөек Ватан сугышы башланганда җиде сыйныфны тәмамлаган Сафуан, яшь кенә булуына карамастан, колхоз эшенә җигелә. 1944 елның декабрендә армиягә китә, 1945 елның ахырында демобилизацияләнеп туган авылына

кайта. Бер елдан артыграк вакыт үткәннән соң, ул Үзбәкстанның Маргилан шәһәренә килә, анда штукатурчы-маляр һәм рәссам-бизәүче булып эшли. Сафуан, элекке шигырьләрен бергә җыйнап, төргәктә саклый. Әмма бер көнне аның иҗат җимешләре юкка чыга. Күңелсез хәлнең сәбәбе тиз ачыклана. Фатирда бергә яшәгән урыс егете Сафуанга якташының — укытучы Муксинның аның шигырьләрен утлы мичкә тондыруы хакында җиткерә.

Егетнең төзүчеләргә багышланган «Беренче кирпеч» исемле поэмасы да Казанда шундый хәлгә дучар була. Монысын сатучы Мортазина мичкә олактыра. Сафуан поэмасын шагыйрь Гали Хуҗига да күрсәткән була. Шагыйрь әсәргә әйбәт бәя биреп, аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында бастырып чыгарырга тәкъдим итә.

— Шушы хәлләрдән соң өч дистә ел буена кулыма каләм алмадым, — ди Сафуан.

Ул, төзүче буларак, баштанаяк маляр-штукатур эшенә чума, клуб-мәдәният сарайларының эчен һәм тышын бизәү белән шөгыльләнә. Тынгысыз җан мичче һөнәрен дә үзләштерә. Аның һәр коне кешеләргә игелекле хезмәт күрсәтү белән үтә.

— Син, Сафуан, Үзбәкстанда яшәгәндә бихисап мич чыгардым, дисең. Шигырьләрең янганнан соң, синең мич чыгаруга мөнәсәбәтең дә үзгәрергә тиеш иде кебек. Ә син һәркемнең үтенечен җиренә җиткереп үтәргә омтылгансың.

— Беренче карашка шулай кебек. Әмма тирәнрәк уйлап карасаң, беткә ачу итеп, туныңны утка ягу кебегрәк килеп чыга. Монда мичнең гаебе юк. Мәгънәсез, сай карашлы бәндәләр нахарлык кылды миңа. Билгеле, миндә аларга карата нәфрәт хисләре уянды. Алай гынамы соң, мин дистәләрчә еллар шигырь яза алмый йөрдем. Дөрес, мин, рәссам-бизәүче буларак биналарга орнаментлар төшерү, гипс һәм алибастрдан эшләнгән бизәкләрне ябыштырып беркетү кебек гамәли сәнгатьтә үземә җан юанычы рухи азык таптым. Ләкин йөрәгем тынычлык күрмәде — гел сыкрады, гел сызлап типте. Күңелемдә бер чакта да шигырь язу теләге сүнмәде.

Илле яшем тулгач, мин яңадан кулыма каләм алырга, шигърият доньясына керергә җөрьәт иттем. Үзбәкстан якларында каңгырып йөрүләрем, татар иленә сагынуларым бәлкем шулай гына басылыр дип уйладым. Тора-бара гелактәшләремне дә таптым. Алар — Маргиланда яшәүче татар зыялылары үзбәк телендә иҗат итүчеләр — Әстерхан педагогия институтында Мөнир Мазунов белән бергә укыган укытучы, шагыйрь Сәет Яфасов, Фирганә өлкәсе гәзитендә журналист булып эшләүче, язучы Вәгыйз Мозаффаров. Бу каләмдәшләремнең ярдәме зур булды. Аларның төпле киңәшләре һәм дустанә җылы сүзләре миңа канат куйдылар.

Үзбәк әдәбиятының аксакалы, Ташкентта яшәүче олы әдип Әсгат Мохтар да (ул үзе татар) миңа ярдәм кулын сузды. Ул, хәтта «Фидаилар» дигән шигыремне үзбәкчәгә тәрҗемә итеп, «Гулистан» журналында да бастырып чыгарды.

Озын сүзнең кыскасы, Сафуан төзелешләрдә үзен менә дигән һөнәр иясе итеп таныта. Шул ук вакытта мич чыгарудан да туктамый. Мич дигәннән, аның шул елларда язылган «Мич чыгарган чагым» исемле шигыре дә бар:

> Кешеләргә һаман җылы эзләп
> Йөргән чагым минем, яшь чагым.
> Дусларыма мич чыгарып йөрим,
> Иркенрәк ясыйм учагын...
>
> Мичем, димен, төтен кайтармасын,
> Төтен сеңә үпкә, канына...
> Сөрем сулап рухы сүнгән кеше
> Җитә аламы якты таңына?
> ....
> Мич суырсын... Мич чыгарган чагым —
> Йөрәк кебек янсын учагым...

— Мичче булып китүем дә кызыклы бер хатирә булып күңелемдә саклана. Шулай берчак прораб Науменко мине очратты да, әйтә куйды: «Синең, Сафуан, башкармаган, белмәгән эшең юк. Татарның кулыннан барысы да килә. Мамык заводы пунктларындагы өйләр мичсез утыралар бит. Әйдә әле, шуларга җылы иңдер — мичле ит үзләрен!» Мин беренче галанканы шул йортларның берсендә чыгардым. Китте шуннан... Хәзер дә бу шөгылемнән аерыла алмыйм.

— Сафуан, мич салуның кайбер серләрен укучыларга да җиткерсәң иде.

— Билгеле, мич чыгаруның да үзенә күрә серләре байтак. Беренче нәүбәттә, кызыл балчыктан ясалган измә комлырак булырга һәм артык куе булмаска тиеш. Мич нигезен кирпечтән, таш яки бетоннан салырга кирәк. Мич утырасы урын дымлы булган очракта нигезне толь яки рубероид белән изоляцияләү сорала. Шулай эшләгәндә нигез кирпечләре дым тартмаячак. Мичкә кирпеч тезгәндә, измәне калын итеп салмагыз. Ул калын булса, мичнең штукатуры ярылачак.

Галанканың (плитәнең) төтен юллыгын өч өйләнешле итеп ясасагыз, мич нык җылыныр һәм төтенне дә яхшы суырыр. Мин, мәсәлән, мич юллыгы өйләнешләрен һәрвакыт вертикаль ясыйм. Тагын шунысын да игътибарда тотыгыз: мичне өеп түшәмгә җиткәч, морҗа кирпечләре арасын әйбәтләп, читкә ут-ялкын чыкмаслык итеп измә белән сылагыз.

Сафуан Муллагалиев 55 яшендә гаиләсен Маргиланда калдырып (якын арада аны да бирегә күчерүне истә тотып), кулына бер чемодан тоткан килеш мәркәзебезгә кайтып төшә. Аны күптән инде башкаладагы каләмдәшләре бирегә яшәргә чакыралар. Чөнки алар Сафуанның өметле каләм иясе булуын күрәләр. Шулай булмыйни, авторның республика гәзит-журналларында күп шигырьләре доньяя күрә. Аларны шигърият сөючеләр җылы кабул итә. Хәзер ул — дүрт китап авторы. Дүртенче китабы «Биздерсәләр туган җиреңнән» дип атала. Анда авторның бары бер әсәре — шигъри повестенең беренче бүлеге урын алган. Тиздән аның икенче бүлеге дә китап булып басылып чыгар, иншалла.

Шагыйрьнең бу әсәрендә туган илендә фикер хөрлеге һәм җан тынычлыгын таба алмаган татар кешесенең катлаулы һәм авыр язмышы гәүдәләнә. Тоталитар системаның афәтләрен әсәр каһарманы чит-ят җирләрдә дә татый. Шулай итеп ул беркайда да җан тынычлыгы бәхет таба алмый.

Шагыйрь хәзер Казанда яши. Өч кызы да югары белемгә ия. Өлкәне — Гүзәл Сәмәркандтагы сәүдә институтын, ә Илдария белән Илмира Казан дәүләт университетын тәмамлаганнар. Һәркайсы үзләренең язмышларыннан һәм башкара торган эшләреннән канәгать. Каләм иясе үзе дә иҗат юлыннан нык адымнар белән бара. Ул — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шулай итеп, аның күп кенә уй-хыяллары тормышка ашты. Казанда да мичләр чыгарып, дусларын куандырып яши ул.

Касыйм ТӨХАУ.

Акыллы тычкан бер тишеккә ышанмас.

Кибәнгә тычкан керде.

Бәхетегез шампан шәрабедәй ташып торсын!

Шампан шешәсеннән башка Яңа ел бәйрәмен без инде күз алдына да китерә алмыйбыз. Уйлап карыйк әле: без бу затлы эчемлек турында нәрсә беләбез соң?

Французларның иң танылган шампан шәрабләре белгече Пьер Лоранның шушы темага бик кызыклы язмасы бар. Ул болай дип яза:

«Әгәр сезнең яктылык төшми һәм үтәли җил керми торган, җылылыгы даими рәвештә 15 градустан да югары булмаган махсус подвалыгыз юк икән, шампан шәрабен ясау һәм саклау белән шөгыльләнеп тә тормагыз».

Шампан шешәсен яткырып саклыйлар. Шампан шәрабенең яше 3-4 елдан алып 7-8 елга кадәр — артык тотарга ярамый: аның тәме югала, ул баллы ликерга әйләнә.

Шампан шәрабен суыткычта тотарга ярамый, берничә минутка куеп алганда да ул үзенең беренчел сыйфатларын җуярга мөмкин. Бәйрәм өстәленә аны көмеш чиләккә, бозлы суга салып китерәләр. Әгәр көмеш чиләгегез булмаса, мельхиор яки җиз чиләккә салыгыз, әмма пластмасса савытка сала күрмәгез!

Һәм менә шампан шешәсенең бөкесе түшәмгә оча, төмле, кайнап торган хуш исле шәраб бәллүр касәләргә коела. Нәкъ менә шулай эчәләр бу шарәбне, башкача ярамый да! Шешәдән ялтыравык көгазен һәм тимерчыбыкны алып ташлыйлар, йөзем суы һәм кояштан ясалган татлы шәраб түшәмгә атылмасын яисә кунакларны коендырмасын өчен бөкене әкрен-әкрен генә борып ачалар, касәләргә коялар. Шәраб тиз җылынучан, шуңа күрә касәне нечкә биленнән генә тотарга киңәш ителә.

Шампан шәрабенә иң кулай кабымлык — зәйтүн җимеше яки кара уылдык. Бу кабымлыклар шәрабнең тәмен бозмый. Иң яхшысы — шампан шәрабен эчкәндә берминди кабымлык та кулланмау.

Шампан шәрабе — Көнбатыштан кергән эчемлек, Русиядә дә аны еш кулланганнар. Дөрес, урыслар араКы ярата, әмма йортта һәрвакыт шампан шәрабләре дә сакланган — кем килмәс, дөнья хәлен белеп булмый. Шампан — затлы эчемлек.

Яңа ел белән, дуслар! Өстәлләрегезне бәйрәм кичендә шампан шәрабләре бизәсен! Бәхетле булыгыз!

Халыкара күргәзмә. Оскар Петцольдның сыра ясау заводы павильоны. Казан, 1909 ел.

Абдулла ДУБИН тупламасыннан.

Марсель ГАЛИ

Алхәбәр

Кошлар очканда югала...

Гомеренең соңгы елларында Мөхәммәт ага «Алланың кашка тәкәләре» яшәячәк йортка күченү уе белән янып, бөтен нервысын талкып, тәмам «чирләп» йөрде. Шул дәвердә мин аңа: «Алтмыштан узгач, урын алыштырмау хәерле, ой иясен рәнҗетүең бар...» — дигән идем. Ишетте дә, ишетмәде дә кебек. Күк катлары белән хәбәргә кергән җаны каядыр алгысыткандыр аны, йөрәгеннән түгелгән мөкаддәс иҗатын калдырып, үзенең дә бу дөньялыктан узып барышы булган икән.

Аны соңгы юлга озаткан кояшлы көнне, өйдә ялгызым гына калгач, тәрәзә каршындагы каен белән күзгә-күз карашып торганда бәхилләшү сүзләрен әллә мин, әллә яфраклар пышылдады.

Аның дөнья читлеген тарсынып, күккә ашкан җаны нәкъ менә Тукайлар, Мәрҗанилар катына менеп җиткәндер дә, энциклопедик акыл иясен алар үз араларына алганнардыр да.

— Кичер безне, ашыктырдык син монда — Күк тәхетенә кирәгрәк, — дияләрдер кебек. Мөхәммәт ага анда да югалып калмагандыр. Мәртәбәле җаннар каршында башын игәндер дә, гарәп хәлифәседәй кыяфәтенә нур иңдереп, бер дога кылгандыр.

Ә җирдә хакыйкать пышылдый: Кеше китә, җыры кала...

«Боегебез» Марсель Галинең каләмдәшләре турында гаҗәеп мавыктыргыч итеп язылган хатирәсе гәзитебезнең гыйнвар аенда чыгачак.

Дуңгыз елының изге гамәле

Хөрмәтле укучыларыбыз! Игътибар иткәнсездер: менә сез «Мәдәни җомга» гәзитенең быелгы соңгы санын кулыгызга алдыгыз. Соңгы, дигәч тә, күңелегезне моңсулык биләмәсен, чөнки нәкъ бер атнадан без әле тагын күрешәчәкбез. Монысы инде Яңа елның беренче атнасында булыр. Ышанабыз, моңарчы безнең басманы өйләренә алдырып укыган абунәчеләребез белән киләчәктә дә аерылышмабыз. Үзегез ничек уйлыйсыздыр, ә без исә Яңа елны, гомумән, алдагы гомерне элекке дуслардан башка күз алдына китерә алмыйбыз. Өметебез зур ки, киләсе елда гаиләбезгә яңадан-яңа дусларыбыз да өстәлер. Бу җәһәттән, кадерле милләттәшләребез, һәммәгезгә дә олы рәхмәтебезне белдерәбез. Иншалла, киләчәктә дә ышанычыгызны акларбыз, гәзитебез сезне һәрьяктан да канәгатьләндерер дип уйлыйбыз.

Ә инде теге яки бу сәбәп аркасында «Мәдәни җомга»га язылырга өлгермәгәннәргә шуны искәртәбез: атналык гәзитебезгә элемтә ел дәвамында барачак. Моның өчен, һәр айның 10ысына кадәр элемтә бүлекләренә барып, абонемент кәгазен тутырырга гына кирәк, һәм «Мәдәни җомга» алдагы айның беренче көненнән өегезгә килә башлар. Басманың бәясен исегезгә төшерәбез: ***5 айга — 15 мең сум; 11 айга — 33 мең сум; редакциягә килеп алучылар өчен — 23 мең 276 сум (11 айга).***

Үтеп баручы 1995 елга без бик тә рәхмәтле, чөнки татар зыялыларының күптәнге хыялын гәүдәләндергән «Мәдәни җомга» атналык гәзите нәкъ менә шушы елның 21 июлендә туды һәм алты ай эчендә 24 сан — рухи тормышыбызның 576 сәхифәдән торган үзенчәлекле елъязмасын дөньяга чыгарырга өлгерде. Шөкер, Дуңгыз елының изге гамәле булган яңа басма инде алгына басып килә, «Мәдәни җомга» үзенең алты айлык гомерендә Яңа елны беренче мәртәбә каршылый, елъязма дәвам итә.

Якынлашып килүче Яңа ел белән сезне, мөхтәрәм дуслар! Хушлашмыйк. Алдагы җомга иртәсендә исән-аман күрешеп, һәрвакыт бергә булырга язсын. Амин!..

Мәдәни җомга

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-?7-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4472